

ФАҖИГА
РӘМЗИ ВӘЛИЕВ
РӘМЗИ
ВӘЛИЕВ
ФАҖИГА
АБДРАХИМОВ ГАЛЕЙ ШАКИРОВИЧ.


Многоуважаемая Ш. Г.!
Я, в период с 1940 по 1942 г.г. был близким другом
и приятелем Вашего покойного отца Гильми
абы; он скончался 5.I-1942г. в Красноярском крае,
на лагерном пункте, находящемся в 12 км. от
ст. Решоты и похоронен на кладбище для заклю
ченных; смерть наступила на пятый день с
начала болезни наименование болезни — пеллагра,
рая сопровождалась резким поносом.
Мархум Гильми абы пользовался
среди всех заключенных, работу он выпол
сильную в соответствии с здоровьем
не голодал.
Что же еще Вам рассказать о нем,
ни задолго до смерти он получил пис
семьи, т.е. от Вашего брата
Я свое
Гильми абы
тельно
бодости
о себе:
семьи
Бур


маленькое послание. Пишу по просьбе
, который в жизни мне говорил:
если сохранишь жизнь, то обяза-
обо мне, ... Я чувствую
своей кончины ——— ".
так, разрешите Вам сообщить в двух словах.
Я сел 13.V-37 г. и освободился 13.IV-55 г.
заключения я жил в Казани, хорошо знал
Булатовых и братьев Шараф (Галимджан и
С получением сего письма прошу вас
уведомить о получении; на интересующие вас
вопросы могу ответить.
С приветом! Халиф.
4.VI-56 г.

РӘМЗИ ВӘЛИЕВ

ФАҖИГА

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1996

ББК 63.3 (Р-Тат.)
В97

Китап «Ак барс» банкының матди ярдәме белән
нәшер ителде

Вәлиев Р. К.

В97 Фаҗига.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.— 191 бит.
ISBN 5—298—00650—7

Шәрәфләр — милли тарихыбызда якты эз калдырган гали нәсел. Аның күренекле вәкилләре бертуганнар Шиһап, Шәһер, Борһан, Гыйльметдин һәм Галимҗан Шәрәфләр татар халкының азатлыгы һәм якты киләчәге өчен үзләрен аямыйча көрәштеләр. Фидаилар йолдызлыгында аларның лаеклы үз урыннары бар. Китапта әлеге каһарманнарның сокландыргыч батырлыклары һәм фаҗигале язмышлары хакында бәян ителә.

Киң катлау укучыларга, дәүләтчелегебез һәм мәдәниятебез тарихы белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

В $\frac{0503000000-056}{М\ 132(03)-96}$ 97—96 ББК 63.3 (Р-Тат.)

ISBN 5—298—00650—7

© Татарстан китап нәшрияты, 1996

Репрессияләр корбаннарының, нахакка рәнҗетелгәннәрнең якты истәлегенә багышлыйм.

Автор

КЕРЕШ СҮЗ

Тарих, тормыш укытучысы буларак, безнең яшәү рәвешебезгә тәэсир итә, яңадан-яңа ялгышулардан саклый. Үткәннәребезне яхшы белү, тирәнтен өйрәнү — үзаңыбызны үстерү, дәүләтчелегебезне ныгыту өчен зарури чара. Татар халкы — төрле тарихи сикәлтәләр узган бөек халык. Аның үз дәүләте булган. Соңрак 500 елга якын дәүләтсез, изелгән, кыерсытылган хәлдә яшәп тә, ул үзенең телен, милли аңын, әхлакый пакьлеген югалтмаган. Явыз Иван, патша хөкүмәте, тоталитар режим милләтебезнең асыл сыйфатларын, затлылыгын юкка чыгару өчен мәкерле сәясәт үткәрделәр, ут һәм кылыч белән канлы гамәлләр кылдылар. Гаделлек соң булса да өскә чыкты. Хәзерге вакытта, халкыбыз бәйсезлек баскычларыннан тагын да югарырак күтәрелгәндә, СССР таркалды, Русия үзе дә авыр хәлдә.

Тарихны кешеләр ясыйлар. Алар тормыш кыенлыкларын үз җилкәләрендә күтәреп, алдагы киртәләрне җимереп, канкойгыч сугышларны кичеп, алга баралар. Әлбәттә, алар төрле юл үтәләр, тарихка төрлечә кереп калалар. Безнең бай мирасыбыз бар. Әмма әлеге хәзинәнең шактый зур өлеше тоталитар режим чорында бөтенләй диярлек юкка чыгарылды. Сталин һәм аның яраннары башлап Мирсәет Солтангалиевкә ябырылдылар, чөнки ул беренчеләрдән булып гаделсезлек белән көрәш юлына басты, тиранның йөзенә карап аны тәнкыйть итте, изелгән халыкларны яклады. Тоталитар режим сәясәтенең нинди нәтиҗәләргә китерәчәген шулай ук беренчеләрдән булып абайлаган бертуганнар Шиһап, Шәһер, Борһан, Гыйльметдин һәм Галимҗан Шәрәфләр татар халкының азатлыгы һәм бәхете өчен үзләрен аямыйча көрәштеләр. Фидаилар йолдызлыгында аларның үз урыннары бар. Исем-фамилияләре, хезмәтләре дистәләрчә еллар дәвамында яшерелеп сакланса да, бу фидакяр шәхесләрнең фаҗигале язмышлары, сокландыргыч батырлыклары турындагы хакыйкать, ниһаять, халыкка килеп ирешә.

Аларга карата Сталин режимы аеруча рәхимсезлек күрсәтте. Партиянең өлкә комитеты 20—30 нчы елларда ук матбугатта «шәрәфизм», «шәрәфчелек» белән көрәш кампаниясен киң җәелдерде. Аның нәтиҗәсе — кулга алынулар, төрмәләргә ябылулар, эштән куылу, хәтта аларның балалары өчен дә юллар ябылу. 30 нчы еллар ахырында тоталитар режим зинданында исемнәре югарыда аталган фидаилар гына түгел, башка бик күп галимнәребез, язучыларыбыз, алдынгы эшчеләребез, инженерларыбыз һәм крестьяннарыбыз газап чиктеләр, югалдылар... Аларның язмышлары бүген безгә хәтер булып кайта.

1939 елның 1 гыйнварендa лагерьларда 1317195 тоткын булган. Шулардан руслар — 830491, украиннар — 181905, белоруслар — 44785, татарлар — 24894, үзбәкләр — 24499, яһүдләр — 19758, немецлар — 18572, казахлар — 17123, поляклар — 16860, грузиннар — 11723, әрмәннәр — 11604, төрекмәннәр — 9352, башкортлар — 4874, таҗиклар — 4347, башка милләт вәкилләре 96948 кеше исәпләнгән[1]. Алар арасында 70 яшьлек әби-бабайлар да, ир-егетләр дә, сылу кызлар да, балалар да бар иде...

Язучыларыбыз һәм галимнәребез бертуган Шәрәфләр хакында мөмкин булган дәрәҗәдә 60 нчы елларда яза башладылар. Аларның исем-фамилияләре Г. Тукайның остазлары, дуслары һәм киңәшчеләре буларак искә алына иде. Шәрәфләр Тукайның беренче шигырьләрен нәшер иткәннәр, бергә аралашып яшәгәннәр һәм шагыйрьне соңгы юлга озатучылар да булганнар. Зариф Бәшири, Сәгыйть Исәнбәт, Ибраһим Нуруллин, Әбрар Кәримуллин, Энҗе Сәгыйтова һәм Җәвад Тәрҗеманов алар турында беренчеләрдән булып матбугатта җылы сүз әйттеләр.

80—90 нчы елларда Шәрәфләрнең эшчәнлеге һәм язмышы белән кызыксыну арта барды. Үзгәртеп кору чоры башланганда яңа мөмкинлекләр ачылды. Соңгы елларда Равил Әлтәф, Булат Солтанбеков, Индус Таһиров, Марсель Әхмәтҗанов, Дамир Шәрәфетдинов, Алексей Литвин, Риф Хәйретдинов, Дамир Гарифуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Булат Галиев һәм башкаларның мәкаләләре дөнья күрде. Безнең аз гына булса да күзләребез ачыла башлады. Шәрәфләр нәселенә, аларның балаларына һәм оныкларына тынычлык килде.

Шәрәфләр язмышы — милләт язмышы. Башта аларны әлифбасыз, телсез, җирсез, эшсез, гаиләсез, туган илсез кал-

---

[1] Кара: Аргументы и факты, 1990, № 35.

дырырга теләделәр; барып чыкмагач, изделәр, үтерделәр. Бу тарихны без әле өйрәнә генә башладык. Күпкырлы эшчәнлек җәелдергән әлеге шәхесләрнең хезмәтләрен өйрәнү — безнең бурычыбыз. Мәсәлән, Галимҗан Шәрәф, Тукай әйтмешли, коеп куйган профессор-педагог кына түгел, тарихчы-этнограф, филолог һәм картограф та, дәүләт эшлеклесе һәм шагыйрь дә. Аның 300 дән артык шигырьләре бар. «Зодчий» дип аталган поэмасы гына да ни тора! Анда урын алган фикерләрдә ачыктан-ачык Сталинга һәм аның гамәлләренә киная сизелә. (Кара: Советская Татария, 1991, 28 декабря.) Г. Шәрәф балалар өчен дә күп язган, үзенең язмаларын «Гаенша бабай» исеменнән чыгарган. Моннан башка ул татар мәктәпләре өчен язылган күп кенә дәреслекләр, методик кулланмалар авторы да. Аның этнография, тарих, география өлкәләрендәге хезмәтләре дә махсус өйрәнүне таләп итәләр.

Вакытлы матбугатта очеркларыбыз дөнья күргәннән соң укучылардан һәм Шәрәфләрнең туганнарыннан (Санкт-Петербургтан профессор Шәфика Шәрәфтән, фәннәр кандидаты Энҗе Сәгыйтовадан, Мәскәүдән Нажия Булатовадан, Казаннан Әсма Шәрәфтән, Сания Шәрәф-Акҗитовадан, Җәвад Тәрҗемановтан, Воронеждан Габбас Шәрәфтән һәм башкалардан) күп кенә хатлар алдык. Казанда яшәүче профессор Булат Галиевны һәм доцент Эльмира Әминованы күреп белә идек. Аларның Шәрәфләр нәселеннән икәнлекләрен соңыннан гына ачыкладык. Муса Җәлилнең көрәштәше Фуад Булатов — Зифа Шәрәфнең бердәнбер улы.

Яңа материаллар эзләү дәвам итә. Әлеге китапны дөньяга чыгару — каһарман Шәрәфләр алдындагы бурычыбызны башкаруда бер адым. Аны әзерләүдәге булышлыклары өчен Сания ханым Шәрәф-Акҗитовага (Шәһер Шәрәфнең кызы), Энҗе ханым Сәгыйтовага (Халисә Шәрәф-Сәгыйтованың кызы), Шәфика ханым Шәрәфкә (Гыйльметдин Шәрәфнең кызы), Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты хезмәткәрләре Владимир Крыловка һәм Ровел Кашаповка, китапны нәшер итүгә матди ярдәм күрсәтүләре өчен «Ак барс» банкы җитәкчесе Тәлгать әфәнде Абдуллинга һәм әлеге банк хезмәткәре Альберт әфәнде Харрасовка тирән ихтирамыбызны һәм рәхмәтләребезне белдерәбез. Китапның барлыкка килүендә хәзер инде арабыздан китеп барган язучы Җәвад Тәрҗемановның һәм Галимҗан Шәрәфнең хатыны Әсма Шәрәфнең дә өлеше зур.

ФАҖИГА

ТАРИХ ЧОҢГЫЛЛАРЫ

Җан Шәрәф (лагерьдаш иптәшләре аны шулай атыйлар иде) кулына бөгәрләнгән кәгазь кисәге алды. Күп гомер нервларының соңгы чиккәчә киеренкелеге сәбәпле барлыкка килгән склероз, экзема авырулары һәм гомуми талчыгу нәтиҗәсендә ул шул дәрәҗәдә хәлсезләнде ки, куллары калтырый, күз аллары әлҗе-мөлҗе килә иде. Шунлыктан алдындагы кәгазь кисәгенә һәр хәрефне мең газап белән генә яза алды. «Минем үлемемдә беркемне дә гаепләмәгез,— дип язды ул.— Моңа бары тик төрмәләр, лагерьлар, эзәрлекләүләр нәтиҗәсендә сәламәтлегемнән, бердәнбер кызымнан, абыйларымнан, гаиләмнән һәм йорт-җиремнән мәхрүм иткән ежовщина гаепле...» Шушы юлларны язу Шәрәфнең бар хәлен алды. Аның карашлары билгесезлеккә төбәлде, ул бу җәһәннәм афәтенә ничек эләгүе турындагы әрнүле уйларга талды, еракта калган гомер юлларын күз алдына китерде.

...Тәтеш өязендәге Аксу авылы. Галимҗан (әтисе, укымышлы бала булсын дип, улына әлеге исемне кушкан) шунда яңа ел туар алдыннан — 1896 елның 29 декабрендә дөньяга килгән. Әтисе Шәрәфетдин Хөснетдин улы һәм әнисе Гайнелнәвал Нигъмәтулла кызы үзләре дә һәрвакыт аң-белемгә омтылучан, укырга яратучан кешеләр булалар, шуңа күрә алар улларында да белемгә омтылыш тәрбияләргә тырышалар. Галимҗан хәтерли: әтисе аны көн саен диярлек Әхмәтгәрәй абыйларына газета алып кайтырга җибәрә иде. Әхмәтгәрәй — авылда мөхтәрәм кеше, ул «Шура», «Йолдыз», «Кояш», «Вакыт», «Тәрҗеман» кебек журнал-газеталар алдыра һәм үзе укыганнан соң аларны теләгән кешегә биреп тора иде. Ун бала әтисе Шәрәфетдин, бик теләсә дә, ул кадәр газета-журналны үзенә яздыра алмагандыр. Шулай да ул матбугатта чыккан хәбәрләр белән шул рәвешле танышып барды. Әхмәтгәрәй абыйсыннан алып кайткан газеталарны әнисе дә укый, кайчакта бергәләп кычкырып укыйлар иде. Әлбәттә, бу шөгыль гаилә

тәрбиясенә үзенең уңай йогынтысын ясамый калмый. Ихтимал, Галимҗанның да белемгә хирыслыгы, кулына төшкән һәр басманы укырга һәвәслеге нәкъ шуннан башлангандыр.

Галимҗанның белем тавына беренче баскычлары әнә шулай өйдә, гаиләдә башлана. Инде укуның чын тәмен аңлый башлагач, әтисе аны Казандагы абыйлары укып яткан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә илтә. Үз заманы өчен алдынгылардан саналган әлеге уку йортында төрле-төрле дөньяви фәннәр, Шәрекъ халыклары мәдәнияте, татар, гарәп, фарсы, госманлы төрек телләре укытыла. Галимҗанга уку (бигрәк тә телләрне өйрәнү) җиңел бирелә. Аның лингвистикага һәм тарихны өйрәнүгә сәләте нәкъ шунда ачыла. Мәдрәсәнең икенче баскычын тәмамлагач, үзлегеннән әзерләнеп, Галимҗан Казанның икенче реаль училищесына укырга керә. Шул вакытларда ул Габдулла Тукай белән якыннан аралаша башлый һәм аның җитәкчелегендә татар әдәбиятыннан беренче хрестоматия булган «Мәктәптә әдәбият дәресләре» дигән китап өстендә эшли. Китап 1912 елда басылып чыга. Реаль училище укытучысы шагыйрь П. Радимов белән берлектә Г. Тукай әсәрләрен («Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык әкияте» һ. б.) урысчага тәрҗемә итеп бастыруда катнаша.

1915 елда реаль училищены тәмамлагач, Галимҗан Петроград тимер юл инженерлары институтына керә һәм анда 1917 елга кадәр укый. Әмма инженер белгечлеге аның күңелен канәгатьләндерә алмый, шуңа күрә дә ул биредә укыганда университет профессорлары һәм академиклары, Шәрекъ тарихы белгечләре Бартольд, Тураев, Смирнов, Щерба, Платонов, Владимиров, Жуковский, Самойлович, Крачковский һәм башкаларның лекцияләренә йөри. Ихтимал, әлеге галимнәрнең йогынтысы белән, ул «Чыңгыз хан дәвере, татар һәм башка халыкларның тарихы» дигән кульязма өстендә эшли башлый.

Шул ук вакытта Г. Шәрәф төрле залларда уза торган шигърият кичәләренә йөрергә дә өлгерә, анда Сергей Есенин, Александр Блок, Николай Клюев, Сергей Городецкий, Федор Салогуб, Анна Ахматова, Осип Мандельштам, Павел Радимовларның чыгышларын тыңлый. Ул Сергей Есенин белән танышып китә, алар Тукайның иҗаты турында әңгәмәләр коралар. Бу хакта Г. Шәрәфнең туганы, күренекле галим һәм танылган язучы Җәвад Тәрҗеманов түбәндәгеләрне хәбәр итә:

«Ул мине (Галимҗан Шәрәфне.— *Р. В.*) үзенең фатирына чакырды. Мин аңа Тукайның 1914 елда безнең Шәрәфләр

нәшриятында дөнья күргән «Мәҗмугаи әсрары»н (тәүге «Сайланма әсәрләр»ен) алып бардым һәм кайбер шигырьләрен үзем тәрҗемә итеп күрсәттем. Ул бик дулкынланып: «Олуг шагыйрь!»—диде, үлчәмен, ритм рифмасын билгеләп, подстрочниклар әзерләп китерергә кушты.

Атна-ун көн уздымы, Есенин әйткәннәрнең һәммәсен үтәп аның фатирына барсам, анда эчү мәҗлесе: дуслары Сергейны армиягә, дөресрәге... фронтка озаталар. Мин дә кушылдым. Есенин Тукайны олылап сөйләде, аның шигырьләрен рус халкы белергә тиеш, диде. Соңыннан ул мине озата чыкты. Шактый ук исерек иде, шулай да подстрочниклар өчен рәхмәт әйтергә онытмады.

Безгә башка очрашырга туры килмәде. Есенин, ишетүемчә, Россиядә үзенә урын таба алмыйча арлы-бирле сугылган, чит илләргә дә барып чыккан, эчүгә сабышкан һәм хатын-кызлар белән чуалган. Тукайны оныткан булса кирәк.

Есенинга калдырган подстрочникларым эзсез югалгач та Тукай шигырьләрен русча яңгырату теләгем сүнмәде. 1919 елның көзендә якташыбыз шагыйрь һәм рәссам Павел Радимов Казанга әйләнеп кайтты һәм Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатының сәнгать бүлеге мөдире булып эшли башлады. Без бер-беребезне күреп белә идек, инде якыннан таныштык. Беренче күмәк эшебез — 1920 елда Габдулла Тукаевның рус телендә «Узюльган умид» (Разбитая надежда) исемле сайланма шигырьләрен бастырып чыгару булды. Аннан соң «Коза и баран» һәм «Шурале» дөнья күрде...»[1]

Тукайның үзе белән бәйләнешне ни дәрәҗәдә, дигән сорауга да җавап бар: «Ул миннән ун елга өлкәнрәк булуга карамастан яшьтәшләр кебек чөкердәшә идек: кызлар, гыйшык-мәхәббәт, мода, театр, музыка, шигърият, җыр, дөнья яңалыклары—берсе дә калмый... Мин аның Шәрекъ һәм Европа мәдәниятен шулкадәр киң һәм тирәнтен белүенә, илаһи зиһененә соклана идем»[2].

Инженерлар институтында уку дәверендә Галимҗан «Татар учагы» дип аталган студентлар оешмасы төзи. Бу оешманың эшчәнлеге турында әлегә бик аз билгеле, әмма анда катнашучыларның исем-фамилияләрен санап чыгу гына да татарларның Русиянең башка мөселман халыкларының милли-азатлык хәрәкәтендәге урыны, роле турында күзалларга мөмкинлек бирә. Галимҗан Шәрәфнең үз сүзләренә караганда, оешма әгъзалары арасында Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар, Солтанбәк Мәмлиев, Кәрим Сәгыйтов, Габдулла белән Гани Абызовлар һәм башкалар була. Алар түгәрәк утырышларында Явыз Иванның колониаль

сәясәте нәтиҗәсендә дәүләтчелекләрен югалткан Русия мөселманнарының милли-мәдәни үсеше мәсьәләләрен тикшерәләр, кайбер татар зыялыларының пантюркизм һәм панисламизм белән мавыгуларын тәнкыйтьлиләр, мөселман халыклары мәдәниятенә кагылышлы башка мәсьәләләр буенча фикер алышалар. «Татар учагы» әгъзалары Казан, Саратов, Киев, Ростов (Дон буендагы) һәм башка шәһәрләрдәге фикердәшләре белән элемтәләр булдыралар. Аерым алганда, 1917 елның августында Дон өлкәсендә үткәрелгән мөселман эшчеләре съездында «Татар учагы» әгъзасы Гани Абызов та катнаша, анда Екатеринослав, Лозовая, Павловкадан килгән татар шахтерлары һәм аларның җитәкчесе Зәйнул Булушов белән аралаша. Ул Казандагы мөселманнар съездында катнашкан делегат Нурулла Бикашов докладын тыңлый. Гани Абызов Петроград студентлары исеменнән Киевтагы мөселман студентлары янында да була. «Татар учагы»ның икенче әгъзасы Солтанбәк Мәмлиев Уфа белән тыгыз элемтәдә тора.

Февраль һәм Октябрь инкыйлаблары бик күпләр белән бергә Г. Шәрәфнең язмышын да кискен үзгәртеп җибәрә. Ул укуын ташларга мәҗбүр була һәм аны яңа вакыйгалар дулкыны үз эченә бөтереп ала.

Мәгълүм булганча, 1917 елның май аенда Мәскәүдә Бөтенрусия мөселманнарының беренче корылтае җыела. Анда 900 чамасы делегат катнаша. Делегатлар арасында мөселман зыялылары, хәрбиләр һәм руханилар була. Съездда Ә. Цаликов, Г. Ибраһимов, Г. Терегулов, Ф. Туктаров, Ә. Мөхетдинова, Г. Шәрәф, Б. Шәрәф, М. Бигиев, Г. Исхакый, А. Рәсүл-задә, З. Вәлиди һ. б. катнаша. Корылтайда эшчеләр, крестьяннар, хатын-кызлар тормышы, милли мәдәният мәсьәләләре карала һәм алар буенча тиешле карарлар кабул ителә. Әлеге мәсьәләләрне тикшергәндә Галимҗан Шәрәф тә ялкынлы чыгышлар ясый. Корылтайда игътибар үзәгендә торган һәм күп бәхәсләр тудырган проблема — Русиядәге дәүләт төзелешенең нинди булырга тиешлеге хакындагы мәсьәлә. Чөнки делегатлар милли төбәкләрдә миллият мәсьәләләренең ничек хәл ителәчәгенең бу проблеманың Русиядә ничек хәл ителүенә бәйле булуын яхшы аңлыйлар. Корылтай күпчелек тавыш белән Русиянең демократиягә нигезләнгән Федератив республика булырга тиешлеге турында карар кабул итә. Бу исә мөселман сәясәтчеләренең милли мәсьәләнең нәзари һәм гамәли нигезләрен үзәктәге шовинист тарафдарларга караганда тирәнрәк аңлауларын күрсәтә, чөнки бу вакытта большевиклар партиясе һәм В. И. Ленин үзе дә бөтен тырышлык-

ларын унитар дәүләтне саклап калуга юнәлтәләр. Галимҗан Шәрәф корылтайдагы докладында татарлар өчен «туфраклы мохтарият» (территориальная автономия) кулай булачагына басым ясый. Аның бу фикерен Ф. Кәримов белән Ф. Туктаровлар да хуплыйлар. Корылтай соңыннан мөселман халыкларының иҗтимагый-сәяси эшчәнлекләре белән идарә итү һәм Вакытлы хөкүмәт белән элемтәдә тору өчен башкарма орган сайлый. Ул Бөтенрусия Мөселман комитеты дип атала.

Июль аенда Казанда да сәяси тормыш кайный: бер үк вакытта диярлек өч съезд — Русия мөселман хәрбиләре, татар укытучылары һәм мөселман руханилары корылтайлары үткәрелә. Аларның һәркайсының игътибар үзәгендә мөселман халыкларының милли-дәүләтчелек төзелешләре мәсьәләсе тора. Галимҗан Шәрәф, Татарстанның мөстәкыйль дәүләтчелеге тарафдары булса да, милли-мәдәни мохтарият (әгәр дә ул территориаль булса) ихтималыннан да баш тартмый. Шуңа күрә дә аны милли-мәдәни мохтариятьне гамәлгә ашырырга тиешле һәйәт составына сайлыйлар. Бу һәйәтнең әгъзалары итеп шулай ук И. Әхтәмов, Ә. Мөхетдинова, Ф. Кәримов, К. Кәрим һәм Н. Хәлфин дә сайлана.

1917 елның 22 ноябрендә Уфада Милли мәҗлес сессиясе ачыла. Анда килгән 96 депутат арасында Г. Шәрәф тә була. Сессия президиумының рәисе итеп Дәүләт думасы әгъзасы Садри Максуди, сәркатибе итеп Габдрахман Фәхретдин раслана. Милли мәҗлес 1918 елның 11 гыйнварена кадәр эшли. Аның эшчәнлегенең бөекмәмләкәтчеләр теләмәгән юлга кереп китү ихтималын абайлаган Русия Халык Комиссарлары Советы (Совнарком) ул көннәрдә «Бөтен Шәрекъ һәм Русиянең мөселман хезмәт ияләренә мөрәҗәгать» кабул итә. «Мөрәҗәгать»тә «Мөселман хезмәт ияләре үз тормышларын бернинди ирексезләүләрсез, үзләре теләгәнчә төзи алалар, үз диннәрен тотарга хокуклылар, аларның бу хокуклары инкыйлабның, Советларның бөтен көче белән сакланачак», диелә. Әлбәттә, документның Милли мәҗлес депутатларына тәэсире зур була. Һәр милләткә үз тормышын үзе теләгәнчә корырга ирек бирү вәгъдә ителгәч, Мәҗлес депутатлары арасында милли-дәүләтчел төзелеш мәсьәләсенең беренче урынга чыгуы һич тә гаҗәпләнерлек хәл түгел. Бу юнәлештә тәүге адым буларак «Идел-Урал штатлары»н төзү игълан ителә. Моңа ирешү өчен «туфракчылар» фракциясе әгъзасы Г. Шәрәф тә шактый көч куя. Ул фракция исеменнән «туфраклы мохтарият» хакында махсус доклад белән чыгыш ясый, булачак җөмһүриятнең атама-

сын «Идел-Урал» дип расларга тәкъдим итә, җөмһүрият мәйданының картасын төзи. Әлбәттә, бу мәсьәлә шома гына узмый, ике фракция — «төрекчеләр» һәм «туфракчылар» арасында кискен көрәш бара. Шунысын да әйтү кирәктер: большевиклар, сул эсерлар, гомумән, суллар фракциясе «туфракчылар» ягыннан чыгыш ясыйлар. Ниһаять, алар тәкъдиме өстенлек ала. «Идел-Урал штатлары»н гамәлгә ашыру буенча Галимҗан Шәрәф рәислегендә махсус һәйәт төзелә, аның составына Галимҗан Ибраһимов, Ильяс Алкин, Сәлах Атнагулов, Фатыйх Сәйфи, Сәет Енгалычев, Нәҗип Хәлфин һәм Фатих Мөхәммәдьяров керә. Аларның барысы да җәмгыяви бертигезлек буенча сайлаучы Советлар нигезендә мөстәкыйль җөмһүрият төзү тарафдарлары булалар.

«Идел-Урал штатлары»н төзү һәйәте Казанга күчкәч, аның рәисе итеп И. Алкин, ә урынбасары итеп Г. Шәрәф раслана. Г. Шәрәфнең милли дәүләтчелек төзелеше турындагы фикерләре Милли Мәҗлестә ясаган докладындагыга караганда соңгы айларда беркадәр үзгәрәләр. Беренчедән, ул «Идел-Урал штатлары»н федерация составындагы мохтариятьле җөмһүрият итеп төзергә тәкъдим итә. Икенчедән, хакимият органнары Советлар системасы буенча сайланырга тиешләр, ди. Өченчедән, һәр Совет халыкның милли нисбәтен искә алып сайлануын яклый.

Кызу бәхәсләрдән соң күпчелек тавыш белән Г. Шәрәфнең тәкъдиме кабул ителә. Әмма аның элекке тарафдарлары Г. Шәрәфнең фикерләре үзгәрүне кабул итмиләр һәм Казан белән Уфа матбугатында аңа «гомумхалык сайлаган җыелыш карарларын бозганы өчен» шелтә белдерелү турында хәбәрләр басыла. Шулай да бу вакыйганы Г. Шәрәфнең «Идел-Урал штатлары»ннан ваз кичүе дип бәяләү дөрес булмас иде. Ул, зирәк сәясәтче буларак, мәҗлестә кабул ителгән карарга вәзгыятьнең үзгәрүенә бәйле кайбер үзгәрешләр кертү зарурилыгын аңлап эш иткән булса кирәк.

«Идел-Урал штатлары»ның барлыкка килү ихтималы Русия җитәкчеләренең планнарына һич тә сыеша алмый. 1918 елның 22 мартында Русиянең Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты «Татар-Башкорт Республикасы төзү турында декрет» кабул итә. Комиссариат җитәкчесе И. Сталин бу очракта мөгаен түбәндәге максатны күздә тоткандыр, ягъни: «буржуаз милләтчеләр»гә һәм гомумән «суллык» тарафдарларына, ягъни «туфракчылар» төркеменә һушсызландырырлык сугып алу, аларның милли эшләрне ның үзәкләштерүгә каршы юнәлтелгән уй-фикерләреннән

ваз кичтерү. Тиздән Г. Ибраһимов белән Г. Шәрәфнең һәм аларның тарафдарларының «буржуаз милләтчеләр» дип игълан ителүләре бу фаразны тулысынча раслый кебек. Моның шулай булуына ышандырырлык тагын бер дәлил бар.

Татар-Башкорт Республикасы турындагы декрет игълан ителү алдыннан И. Сталин Г. Шәрәфне телеграфка чакыра һәм «Идел-Урал штатлары» мәсьәләсе белән кызыксына. Г. Шәрәф телеграф аша «Идел-Урал штатлары», аның мәйданы һәм чикләре турында тәфсилле аңлатма бирә. Менә шушы сөйләшүдән соң ике көн үтүгә комиссариатның «Татар-Башкорт Совет Республикасы» турындагы декреты игълан ителә. Шуннан соң «Идел-Урал штатлары» һәйәтенең эше туктатыла, ә апрель ае башларында Г. Шәрәфне Мәскәүгә чакырып алалар. Чакырылучылар арасында З. Вәлиди, С. Покровский һәм башкалар була.

Бу махсус киңәшмәгә М. Вахитов белән М. Солтангалиев җитәкчелек итәләр. Киңәшмә эшендә алда искә алынган һәйәт әгъзаларыннан һәм Г. Шәрәфтән тыш, С. Атнагулов, Башкортстанның Вакытлы революцион Совет вәкиле Ф. Солтанбеков һ. б. катнашалар. Анда Г. Шәрәф «Идел-Урал штатлары» турында зур доклад белән чыгыш ясый. Ул үз фикерләрен дәлилләү өчен бик күп фактлар, статистик мәгълүматлар китерә. Киңәшмәдә аның төп фикерләрен хуплагандай булалар, әмма озакламый, үзәктәге бөекмәмләкәтчел шовинистларның басымы астында, башкорт, чуваш, мари, мордва вәкилләре үзләренең фикерләрен капма-каршы якка үзгәртәләр: «Идел-Урал штатлары»на гына түгел, «Татар-Башкорт Совет Республикасы»на да каршы чыгалар. Имеш, бу милләтләрнең бертигезлегенә хилафлык китерәчәк.

Г. Шәрәф үз фикерләрен никадәр якларга тырышса да, уңышка ирешә алмый. Әйтерсең лә, әле күптән түгел генә охшаш фикерләре булган кешеләрне үзгәртеп куйганнар. Әлбәттә, бу «үзгәреш»тә Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты җитәкчеләренең (беренче чиратта И. Сталинның) һәм В. Ленинның да турыдан-туры катнашулары бәхәссез дип фаразлауга нигез бар.

Татарстан җөмһүрияте әнә шулай озак тартышулардан, сәяси алдашулардан соң гына оеша алды. Татарның төрле губерналарда чәчелеп яшәве дә эшне кыенлаштырды, чөнки аларның берсендә дә диярлек татарлар күпчелекне тәшкил итмиләр һәм шунлыктан мохтарият төзүгә нигез була алмый кебек иде. Бу мәсьәләне гадел хәл итү өчен губерналар чикләрен генә түгел, ә бәлки өяз һәм волость

чикләрен дә аларда яшәүче халыкның милли составына нисбәтле рәвештә үзгәртү таләп ителде. Әлеге очракта җирле идарә тәшкилатләрендәге һәм Мәскәүдәге архив документларын һәм материалларын өйрәнеп эш итү кирәк иде. Бөекмәмләкәтчел үзәк исә бу мәшәкатьләргә баруны артык һәм кирәкмәс эш итеп санады.

Булачак Татарстан җөмһүриятенең мәйданын һәм чикләрен билгеләү мәсьәләсендә Г. Шәрәфкә Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты җитәкчесе И. Сталин белән еш очрашырга туры килә. Ул үзе бу хакта болай искә ала: «В. И. Ленин һәм М. И. Калинин имзасы белән декрет (ТАССРны төзү турында.— *Р. В.*) игълан ителгәнгә кадәр Сталин комиссия эшендә башыннан алып ахырына кадәр бик актив катнашты. Безнең тарафтан якынча сузылган чикләр, аерым җентекләп эшләнгән кисәкләр, сәнагатьне, авыл хуҗалыгын өйрәнү материаллары, теге йә бу төбәкнең халык составы, теге яки бу үзәккә тартымлык, административ төзелеш һәм шуларга охшаш башка әзерлек материаллары — барысы да Сталинга җиткерелә, ә ул аларны үзендә калдыра да икенче утырышта үз төзәтмәләре белән кире кайтара иде»[3].

Нәтиҗәдә, «Идел-Урал штатлары» төзеләсе төбәктә 1920 ел урталарына өч административ берәмлек — Кече Башкортстан җөмһүрияте, Татарстан җөмһүрияте һәм Уфа губернасы барлыкка килә. Беренче төзелгән план буенча Уфа, Бирск шәһәрләре һәм Бәләбәй өязе Татарстанга кертелергә тиеш була. Ул вакытта моңа Зәки Вәлиди дә каршы килмәгән. Әмма Татарстанның болай «зураюы» үзәкнең максатларына һич тә туры килми. Аларның нияте — Уфа белән Казанны Татарстан җөмһүриятенә кертмәскә. «Саллы» дәлилләре дә бар: Казанны Татарстанга кертсәң, аның фән үзәге буларак әһәмияте калмаячак, янәсе. Мондый каршылыкны университетка оялаган шовинистлар аеруча хуплыйлар. Бөтенрусия Үзәк Башкарма Комитеты аларны «тынычландырыр» өчен Казан университетының үзәккә буйсынулы булуы хакында махсус карар чыгара.

Казан губернасы башкарма комитетының бер төркем бөекмәмләкәтчел шовинист тарафдарлары, Татарстан җөмһүриятен төзүнең урынсызлыгын дәгъвалап, хәтта Сталин белән Ленинга кадәр барып җитәләр. Бу ачыктан-ачык шовинистик гамәл хәтта ВКП(б) Үзәк Комитетында һәм Халык Комиссарлары Советында да яклау тапмый: Татарстан җөмһүрияте төзелә һәм Казан аның башкаласы итеп тәсдыйклана. Уфа губернасының язмышы референдум юлы белән хәл ителергә тиеш була. Ләкин соңыннан, 1922 елда,

Уфа губернасы Үзәкнең астыртын декреты белән «Кече Башкортстан»га кушыла. Нәтиҗәдә, шундый юл белән барлыкка килгән «Олы Башкортстан»да, анда яшәүче халыкның күпчелеге булган татарларның мәнфәгатьләрен искә алмау сәбәпле, киләчәктә ике тугандаш халык арасында милли киеренкелек тудыру өчен нигез салына. Ике игезәк халыкны бүлгәләү юлы белән шулай дошманлаштыру, әлбәттә, шовинистлар тарафыннан нык уйлап гамәлгә ашырылган хәйләкәр сәясәт иде. Әмма тарихның кире кагылгысыз үз кануннары бар. Тугандаш ике халык һичшиксез үзара аңлашырлар.

Югарыда әйтелгәннәрдән аңлашылганча, И. Сталин милли мәсьәләләрне хәл итүдә үзенең патша заманнарыннан калган «Бүлгәлә дә хакимлек ит!» шигаренә нигезләнгән бөекмәмләкәтчел сәясәтен үҗәтлек белән гамәлгә ашыра. Ул Идел-Урал төбәгендә элек-электән бергә гомер иткән, дустанә яшәгән тугандаш халыкларны «социалистик җөмһүриятләр»гә бүлгәләп, киләчәктә алар арасында дошманлык хисләре уяту җирлеген әзерләү өлкәсендә бик тырышып эшли.

Азатлык һәм бәйсезлек вәгъдә ителгән халыкларның ирекләре җепкә тагылган курчаклар мөстәкыйльлеге дәрәҗәсенә төшерелде: җөмһүриятләр һәм мохтәриятьләр вак кына мәсьәләләр буенча да бары тик үзәктән генә дә идарә ителә башладылар; ягъни Сталинның «автономияләштерү» проекты үзенең әшәке вариантында гамәлгә ашырылды. Сталин һәм аның кул астында калган большевиклар партиясе җитәкчелеге бу гамәлләрнең гаделсезлеген, ә гаделсезлек нигезендә корылган СССРның барыбер җимереләчәген үзләре аңлаганнармы, юкмы, әмма СССР таркалу сәбәпләренең иң мөһиме нәкъ менә шушы бөекмәмләкәтчелек сәясәте нигезендә ятканлыгы бөтен фаҗигасе белән ачыкланды инде. Әйтик, ул елларда халыкларга үзләре теләгән мөстәкыйльлек тәэмин ителеп, аерым алганда, Идел-Урал төбәгендә элек уйланылган җөмһүрият төзелгән булса, бүген сәяси хәлләр дә, икътисади тормыш та башкачарак юл белән барыр иде; мөгаен, «Идел-Урал штатлары» яки «Татар-Башкорт җөмһүрияте» мөшкел хәлдә калган Русиягә, һичшиксез, ярдәм кулы да суза алыр иде. Хәзер дә бөекмәмләкәтчел көчләр тарихтан сабак алырга теләмиләр. Хәерчеләнгән Русия һаман да «бердәм һәм бүленмәс» империя дип лаф ора, тырыша-тырыша үзе утырган ботакны кисүен дәвам иттерә. Әмма тарих бернигә дә, беркемгә дә карамый үз юлыннан бара бирә, бу очракта да гаделсезлектән гарык булганын күрсәтми калмас. Борын-

гы хакимнәр дөрес әйткәннәр: бөркетләр күк киңлекләрен иңли, сукыр тычканнар кояштан кача-кача җир астында туфрак казый. Моны күрмәү-аңламау — сукырлык, хәтта тинтәклек. Аңларга күптән вакыт: гаделсезлек булган җирдә тынычлык юк, тынычлыгы булмаган җәмгыятьнең киләчәге юк.

Татар халкының күп гасырлар дәвамында өметләнгән дәүләтчелеген торгызу теләге җимерелә барганын күреп-белеп изаланган Г. Шәрәфнең башына да шундый уйлар килгәндер, мөгаен. Моны әлегә төп-төгәл генә раслау мөмкинлеге булмаса да, аның үзәк тарафыннан әмәлләнгән Татарстан автономиясе белән риза була алмавына шикләнмәскә мөмкин. Моның өчен Г. Шәрәфнең «Идел-Урал штатлары»н, ә аннан «Татар-Башкорт җөмһүрияте»н төзүне гамәлгә ашыруга куйган тырышлыкларын, бу эш белән җитәкчелек итү өчен төзелгән һәйәтнең рәисе буларак башкарган эшләрен генә искә төшерү дә җитә.

Әлегә кадәр 1918 ел башында Казанда «Болак арты республикасы» барлыкка килү сәбәпләрен ачыклауда да берьяклылык хөкем сөрде, аның бар гаебе «Идел-Урал штатлары» һәйәтенә һәм аның «милләтче» җитәкчеләренә кайтарып калдырылды. Чынбарлыкта исә хәл башкачарак иде. Мәгълүм булганча, ул вакытта Хәрби Шураны Ильяс Алкин җитәкли. Шактый бәхәсләрдән соң «Идел-Урал штатлары» һәйәте, полковник Биглов җитәкчелегендәге Хәрби коллегия Казан Советы башкарма комитеты белән бәйләнешкә кереп, «Идел-Урал штатлары» буенча сөйләшүләр алып бара. Шәрәфнең үз сүзләренә караганда, һәйәт «Болак арты республикасы» белән Совет хакимияте арасында канлы бәрелешкә юл куймау өчен зур тырышлык куя, алар арасында арадашчылык вазифасын Г. Шәрәф үзе башкара. Әлбәттә, алып барылган сөйләшүләр нәтиҗәсез калмыйлар, мөселман полкларындагы солдатлар һәм офицерлар 25 көн буена сабырлык күрсәтәләр. Бүгенгә кадәр бу хәл большевикларның тырышлыгы нәтиҗәсе дип бәяләнде. Ә безнең инануыбызча, ул көннәрдә ике арадагы киеренкелекнең кан коюларга барып җитмәвендә, беренче чиратта, һәйәт җитәкчеләренең, бигрәк тә Г. Шәрәфнең тырышлыгы зур булган. Хәрби Һәйәт һәм аның җитәкчесе полковник Биглов та бу киеренке вазгыятьтә сабырлык саклауда үз өлешләрен керткәннәрдер. Югыйсә биш меңнән артык мөселман офицерының бер өлеше генә Казан Советына каршы күтәрелсә һәм үз артыннан мөселман солдатларын ияртсә дә, кан коюның котылгысыз булачагы бәхәссез иде. Ул гына да түгел, Советларның бу көннәрдә таянычы бик ышанычсыз икәнлеген истә тотканда, «Болак арты республикасы»ның

җиңүгә ирешәчәге дә ихтимал иде. Шунысы кызык, Казан Советы башкарма комитеты, «Идел-Урал штатлары» һәйәте белән сөйләшүләр алып барганда, «Болак арты республикасы»на каршы буларак, «Казан республикасы»н төзү мәсьәләсен күтәрә. Моны Советларның милли мәнфәгатьләр өчен көрәшүчеләрнең гамәленә каршы икенче бер гамәл кылырга омтылулары белән генә аңлатырга мөмкин. Ә бит мондый тактика сәяси вәзгыятьне киеренкеләндерүгә генә хезмәт итә. Димәк, «Болак арты республикасы» барлыкка килүнең асыл сәбәпләрен дә «милләтчеләр»нең үҗәтлегеннән генә түгел, ә бәлки күпчелеге бөекмәмләкәтчел шовинистлардан һәм алар җырын җырлаучылардан торган Совет җитәкчелегенең милли мәнфәгатьләрне исәпкә алырга теләмәүләреннән, шуңа күрә милләтпәрвәрләрнең һәр адымын сыйнфый дошманлык гамәлләре дип кенә бәяләүләреннән дә эзләргә кирәктер. Югыйсә бик сәер хәл туа: имеш, большевиклар партиясе, Совет хөкүмәте һәрвакыт дөрес юлдан гына барганнар да, бары тик гаделлек гамәлләре генә кылганнар, ә теге йә бу очракта килеп туган сәяси бәрелешләр барысы да «милләтчеләр»нең сыйнфый казынулары аркасында гына икән. Әмма чынбарлыкта киресенчә булган очраклар да бик күп. Тарихчылар безнең үткән юлыбызны мондый берьяклы бәяләмәләрдән арындырырга, һәр сәяси вакыйганы объектив мәгълүматлар нигезендә яңача, гадел аңлатырга бурычлылар. Бары тик шулчакта гына тарихи гаделлек өстенлек алыр.

«Контрреволюцион фетнә» дип бәяләнгән 1918 елгы февраль вакыйгаларын гына искә төшерик. Бу очракта да бит киеренкелек тудыручылар «милләтчеләр» түгел, ә бәлки Казан Советы җитәкчелеге... Мәгълүм булганча, 1918 елның 28 февраленә каршы төндә Казанда, гомумән, татар-башкорт дөньясында фаҗигале вакыйгалар башлана: мөселман хәрбиләренең II Бөтенрусия корылтае җитәкчеләре Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар. Госман Токымбетов һәм Йосыф Мозаффаров кулга алыналар.

Бу тарихи эпизодка тукталып үтик.

ИЛЬЯСКА БЕР СТАКАН СӨТ

Ул инде күптән Мәскәүдә яши, әмма Казанга кайтып килгәләргә ярата иде. Ул дигәнебез — Якуб Җиһангир улы Чанышев. Күренекле хәрби. Ветеран, орден-медальләре бар. Кадер-хөрмәт иясе һәм... «Болак арты республикасы»н юк итүгә өлеш керткән шәхес. Казан яшьләре, студентлар ал-

дында бик теләп чыгышлар ясый, үзенең сугышчан юлы хакында тәэсирләнеп сөйли...

Бервакыт без аннан: «28 февральдәге кулга алулар ничегрәк булды, кулга алганда башлыклар үзләрен ничек тоттылар, каршылык күрсәттеләрме?»—дип сорап куйдык. Генерал рәхәтләнеп елмайды: «Юк, кая ул: без төнлә барып кердек, ә алар өй халатыннан иделәр»,—диде.

...Төнге тынлыкны каты итеп ишек шаку бүлә. Хезмәтче хатын сискәнеп-куркып, ишеккә килә:

— Кем ул анда?

— Ильяс Алкин, аңа пакет!—дип җавап бирәләр һәм, үрелеп, ишекнең өске, пыяла өлеше аша кәгазь күрсәтәләр.

Бикне ычкындыруга ялт итеп башта солдат, аның артыннан, ишекне каерып ачып, егермеләп кораллы кешеләр килеп керә.

— Чыгып китегез,—ди хезмәтче хатын, коты алынып.— Мине эштән кудыртасыз бит!

Аның сәясәттә эше юк. Аның бурычы—йорт-җирне җыештырып тору һәм саклау.

Өлкән кешеләрнең йокысы сак була. Өстенә чапан киеп төнге кунаклар янына залга башта гаилә башлыгы Сәетгәрәй Алкин, аннан соң уллары чыга. Йокысы бүленгәнгә җен ачуы чыккан Ильяс Алкин:

— Э-э, кулга алыргамы? Көндез ярамас идемени? Качар бу дип уйлыйсызмы? Мин качмас идем!—ди.

«Кунаклар»ның тәбәнәк буйлысы, бәрәңге борынлысы теләр-теләмәс кенә җавап бирә:

— Көндез ничектер вакыт җитми шул.

— Я, ярый,—ди Ильяс, тынычлана төшеп.— Бер стакан сөт эчәргә рөхсәт итәрсез бит? Әйе, акт төзегез: физик көч кулланганга гына буйсынам.

— Ильяс, нинди акт инде ул?—ди кызылармеец.

— Мин бары тик физик көчкә генә буйсынам,—ди Ильяс тагын кырт кисеп, ә үзе тыныч кына, әйтерсең лә «Идел-Урал җөмһүрияте»нең президенты, сөт эчүен дәвам итә...

Сәетгәрәй абзый ирексездән көлемсерәп куя: кара әле син аны, егерме икесен яңарак кына тутырган бала үзен ничек ир-егетләрчә тота. Юридик мәсьәләләр буенча әтисе әйткән-өйрәткәннәрне күңеленә салып барган икән егет... Менә ул Алкиннар каны һәм Алкиннар аңы... Хәер, кая монда юриспруденция, аң? Кемдә көч—шул хаклы, шул аңлы. Көчленеке, явызныкы хәзер замана—бөтен хокук менә шул.

Ильясның абыйсы Җиһангир түзеп тора алмый:

— Сез үзегезнең нәрсә эшләвегезне беләсезме?! Гомуми

эшкә, милләткә хыянәт итәсез ләбаса!—Ул гасабиланып телефонга үрелә башлый, ләкин аңа мөмкинлек бирмиләр.

— Мәшәкатьләнмә,—диләр аңа.—Телефон инде кичтән үк өзеп куелган.

Госман Токымбетовны, Йосыф Мозаффаровны шулай ук, шул ук төнне... Ә менә Сәлах Атнагуловны, Гата Баһаветдин ахунны, полковник Бигловны кулга алырга өлгерми калалар — таң ата. Ул чакта бик алай иркен кылана алмыйлар: «эләктерү группасы» көпә-көндез эш итәргә халыктан шикләнә[4].

ГАДЕЛЛЕК ХАКЫНА

Әлбәттә, бу вакыйга мөселман халкы арасында зур ризасызлык тудыра, шау-шу, тәртипсезлекләр башлана. Кемнеңдер Советка, революцион штабка һәм аларга каршы көрәшмәгән, битарафлык саклаган вәисевчеләргә каршы астыртын котыртуы да сизелеп тора.

Вәисевчеләрнең штабы хәзерге Нариман урамындагы бер йортта урнашкан була. Оешманың җитәкчесе Гайнан Вәисев яңа төзеләчәк җөмһүриятнең нинди булырга тиешлеге турында уйлана. Аның төп максаты — булачак җөмһүриятне Татарстан дип түгел, Болгарстан дип игълан итү. Хәер, бу максат бер Гайнанныкы гына түгел, ул вәисевчеләр хәрәкәтенә нигез салучы әтисе Баһаветдин Болгари (1804—1893) тарафыннан ук куела, «Дөреслек вә гаделлек» җитәкчесе Г. Вәисев өчен дә төнге кулга алулар көтелмәгән күңелсез вакыйга була. Бүгенге вәзгыятьтә нинди юлга басарга? Бу хакта фикер алышырга килгән Хәрби Шураның төбәк комитеты вәкиле Садретдин Йосыпов та үзенең «Сез бу очракта нәрсә эшләячәксез?» дигән соравына җавап көтә. Гайнан, озак уйлаганнан соң, үз оешмасының кыйбласын болай дип бәянлый: «Без, газилар, орыш-талаш сукмагына басу нигезендә түгел, ә бәлки Хак Тәгаләнс, динебезне саклау җирлегендә берләшү турында хыялланган идек. Һәрхәлдә, без Советларга каршы көрәштә катнашмаячакбыз»[5].

Йосыпов киткәннән соң озак та үтми, Г. Вәисов янына Хәйретдин Вәлиев килә. Ул хәрби шурачыларны кулга алу уңае белән фетнә күтәрелә башлаганын әйтә, Советка каршы көрәшергә теләмәгәнегез өчен сезгә карата да янаулар ишетелә, дип кисәтә. Аның сүзләрен раслагандай, йорт янына фетнәчеләр төркеме җыйнала, кычкырыш, хәтта ату тавышлары яңгырый. Гайнан ярсыган халыкны тынычландырырга теләп тәрәзәсен ача һәм урамдагы төркемгә

мөрәҗәгать итә: «Милләттәшләр, кардәшләр! Кемнәрдер сезне хата юлга кертергә маташа. Тынычланыгыз, өйләрегезгә таралыгыз. Газиләр сезне хак юлга чакыра. Мин хәзер үк Советка барам һәм кулга алынганнарны азат итү чарасын күрәчәкмен...»

Гайнан сүзләрен әйтеп бетерергә өлгерми, берничә җирдән аңа төбәп атып җибәрәләр. Г. Вәисев күкрәген тотып диванга ава һәм берничә минуттан җан тәслим кыла... Фетнәчеләр йортка бәреп керәләр һәм штабның астын-өскә китерәләр, ваталар, җимерәләр[6].

Әлбәттә, хәрби корылтай җитәкчеләрен кулга алулар да, вәисевчеләр җитәкчесе Гайнанны үтерү дә үзара нык бәйләнгән һәм тирәнтен уйлап эшләнелгән явыз коткы (провокация) дип бәяләнергә тиеш. Беренче вакыйганы (кулга алуларны) Казан Советы, ревком оештырган. Ә икенчесен? Соңгы сорауга җавап юк әлегә. Шулай да Г. Вәисевне үтерү турындагы җинаять эшенең бик тиз (1920 елда) ябылуын искә алсак, күңелдә икенче бер шөбһәле сорау туа: бу «эш»не ябарга нигә шулай ашыктылар икән? Кемнәр өчен файдалы булган бу? Киләчәктә яңа документлар табылса, бәлки моның асыл сере ачыкланыр.

Әлегә бу фаҗигале вакыйгалар турында түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Мөселман хәрбиләрнең II Бөтенрусия корылтае җитәкчеләре кулга алынуын тулысынча хуплап, М. Солтангалиев Советларның бу гамәлен болай аңлата:

«а) Татар дәүләтен игълан итүнең татар халкында милләтчеләр файдасына кискен борылыш ясавы мөмкин; б) Без бу вакытта кораллы конфликт юлына баса алмый идек: беренчедән, безнең (ягъни Советларның.— *Р. В.*) Казанда кораллы көчләребез юк иде диярлек, ә Хәрби Шура татар солдатларының санын Казанда гына да 60—80 меңгә кадәр җиткерә ала иде»[7].

Күренә ки, большевиклар җитәкчелегендәге Совет хакимияте четерекле милли-сәяси мәсьәләләрне көч куллану юлы белән хәл итүне кулайрак күргән. Кызганычка каршы, Солтангалиев кебек «милли большевиклар» да үз халыкларына карата башлыча шушындыйрак чаралар күрүне хуплаганнар.

«Февраль фетнәсе»нең асылын ачыклауга ярдәм итүче икенче дәлил дә бар. Аны беренче мәртәбә танылган тарихчыбыз Мидхәт Мөхәррәмов ачыктан-ачык әйтте һәм мөселман хәрбиләренең II Бөтенрусия корылтае җитәкчеләрен кулга алуны Казан Советы оештырганын дәлилләп ачып салды. Хәрби Шура җитәкчеләре Казан Советы тарафыннан Мәскәүгә (Подвойскийга) җибәрелгән телеграмманы кулга төшерәләр. Анда Казанга килергә тиеш-

ле мөселман полкын юлда коралсызландыру кирәклеге хакында әйтелгән була; янәсе, мөселман полкы коралланган килеш Казанга килеп төшсә, «милләтчеләр»нең хәрби куәте артачак, бу исә Совет хакимиятен куркыныч астына куячак. Ильяс Алкин Казан Советының бу мәкерле коткысын корылтайда фаш итә. Нәтиҗәдә, корылтай әлеге телеграмманы юкка чыгарырга, аңа имза куйган Шелыхмановны эшеннән азат итәргә, Казан Советын яңадан сайларга, мөселман полкының имин килеш Казанга килеп җитүен тәэмин итәргә, дигән карар кабул итә. Бу карарга хәтта корылтайның сул канатын тәшкил иткән татар социалистлары, большевиклары да кушылалар. Әмма карар тулысынча үтәлми: мөселман полкы имин килеш Казанга килеп җитсә дә, шәһәр Советына яңа сайлаулар уздырылмый, Шелыхманов та үз эшендә кала, аңа шелтә бирү белән чикләнәләр. Шулай да бу вакыйга гадел булмаган гамәлләрдән баш тартмаучы Совет белән көрәштә беренче җиңү буларак бәяләнергә хаклы.

Мөселман хәрбиләре корылтаеның җитәкчеләре, «тәүбәгә килү»ләрен исәпкә алып, төрмәдән чыгарылалар. Нәкъ менә шуннан соң инде «Болак арты республикасы» игълан ителә. Әмма Үзәк тә йоклап ятмый, Казан большевикларына һәм алар хакимлегендәге Советка ярдәмгә ашыга; 1918 елның 22 мартында Татар-Башкорт Совет Республикасы турында декрет игълан ителә. Соңыннан бу декретның гамәлгә кертелмәве, татарларны һәм башкортларны аерымландыру сәясәте искә алынган декретның большевиклар тарафыннан вакыт отар өчен генә эшләнгән гамәл булуын тулысы белән раслады͏лар.

Күренә ки, «Болак арты республикасы» барлыкка килүгә «милләтчеләр»нең Совет тарафдарлары сәбәпле. Ачыграк итеп әйткәндә, «Болак арты республикасы» үзләре үк күтәреп чыккан «милләтләрнең үзбилгеләү хокукы» шигареннән баш тарткан большевиклар коткысы нәтиҗәсендә туа. Хәер, 1937 елда, сорау алу вакытында Г. Шәрәф бу турыда ачыктан-ачык әйтә: ««Идел-Урал штатлары» һәйәте «Идел-Урал штатлары»н оештыру турында сөйләшүләр башлады. «Болак арты республикасы» белән Казан Советы арасындагы сөйләшүләрдә үзем арадашчылык иттем. Минем төп максатым — Кызыл Армия белән мөселман хәрби берлекләре арасында кораллы бәрелешне, кан коюны булдырмау иде»,— ди ул[8].

Табигый рәвештә сорау туа: 1918 елның февралендә сәяси киеренкелекне булдырмау мөмкин идеме? Әлбәттә, мөмкинлекләр була. Эш шунда ки, «милләтчеләр» белән большевиклар арасында ике төрле идарә формасына кара-

ган мәсьәлә буенча кискен көрәш бара: беренчеләре демократия формасын дәгъваласалар, икенчеләре диктатура урнаштыруны даулыйлар. Ә мәсьәләнең гадел хәл ителүе, ул чорның сәяси вәзгыятен истә тотып, демократия белән диктатура элементларының бергә үрелеп кулланылуы нигездә генә мөмкин иде. Әмма беренчеләренең җиңелүе мәсьәләне диктатура тарафдарлары файдасына хәл итте. Моның фаҗигале нәтиҗәләрен һәркайсыбыз бүген яхшы аңлый. Шулай ук диктатура хакимиятенең озын гомерле була алмавы да аңлашылды — моны тарих үзе исбат итте.

Үзәкнең диктаторлык сыйфатларын уңышлы файдалануы нәтиҗәсендә 1920 елның 25 июнендә Казанда тантаналы рәвештә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы игълан ителә. Әлбәттә, 1552 елда Явыз Иван Казанны яулап алып, татар халкының милли дәүләтчелеге юкка чыгарылганнан соң, чикләнгән хокуклар белән генә булса да дәүләтчелекнең торгызылуы мөһим тарихи вакыйга иде. Шовинист көчләр никадәр генә моңа юл куймаска тырышсалар да, барып чыкмады, милли-азатлык хәрәкәте күпмедер дәрәҗәдә җиңүгә ирешә. Әмма ул моны чын җиңү дип кабул итеп алданды, чөнки тугандаш татар һәм башкорт халыклары бүленделәр, аерымландылар. Аларның милли азатлык өчен көрәштә аерым-аерым хәрәкәт итүе большевистик диктатура файдасына булды, ә диктатура гамәлдә бөекмәмләкәтчел, шовинистик сәясәт үткәрде. Ике җөмһүрият — Татарстан һәм Башкортстан совет хакимияте елларында матди яктан кайбер уңышларга ирешсәләр дә, милли мәдәниятләре һәм туган телләре үсешендә торгынлыкка дучар булдылар. Моның беренче билгеләре 20 нче еллар азагында ук ачык күренә башлады.

Татарстан Җөмһүриятен игълан итү алдыннан һәм аннан соң бу хакта җыелышларда күп сүзләр сөйләнгән, матбугатта бик күп язылган. Аларда төрле, кайчакта каршылыклы фикерләр дә әйтелгән. Бу очракта безне заманында «Татар учагы»н төзегән, аннан соң Милли Мәҗлес, Татар-Башкорт, Татарстан җөмһүриятләрен төзү-оештыру мәсьәләләрендә актив катнашкан Галимҗан Шәрәфнең уй-фикерләре кызыксындыра. Аерым алганда, аның «Кызыл Армия» газетасында басылган зур күләмле мәкаләләре игътибарга лаек. Менә 1920 елның 16 июнь санында басыла башлаган мәкалә. Ул «Республика мөнәсәбәте белән» дип атала. Турыдан-туры әйтелмәгән булса да, авторның Татар-Башкорт Республикасының тормышка ашмавына аяныч белдерүе сизелә. Г. Шәрәф фактларга, саннарга таянып, татар һәм башкорт халыкларының тарихын, милли мәдәни-

ятләренең, туган телләренең якынлыгын, уртаклыгын тасвирлый, кайсы губерналарда һәм өлкәләрдә күпме татар һәм башкорт яшәгәнлеген күрсәтүче саннар китерә. Мәкаләдән аңлашылганча, авторны борчыган иң төп мәсьәлә — бердәм дәүләт булырга тиешле җөмһүриятнең өч кисәккә — Башкортстанга, Татарстанга һәм Уфа губернасына бүлгәләнүе.

Татарстан игълан ителгән көндә югарыда искә алынган газета битләрендә басылган, «Татар Җөмһүрияте татар баласына нәрсә бирә ала?» дип исемләнгән мәкаләсендә исә Г. Шәрәф автономиянең милли мәгарифне, милли мәдәниятне үстерү мөмкинлекләрен киңәйтәчәгенә, музейлар, китапханәләр ачылачагына, идарә эшләрендә татар телен куллану нәтиҗәсендә җитәкче урыннарда милли кадрларның нисбәте уңай якка үзгәрәчәгенә өмет баглавын белдерә.

Беренче карашка, бу мәкаләләрнең мәгънәләре ике төрле кебек. Әмма игътибар белән укысак, аларның әсаси уртаклыгы булуын абайлау һич тә кыен түгел. Әйе, бердәм татар-башкорт дәүләтен төзү нияте барып чыкмады. Моңа «бүлгәлә дә хакимлек ит!» шигаренә таянып гамәл йөртүче шовинистик Үзәк комачаулады, бер дәүләт урынына ике җөмһүрият барлыкка килде. Башкортстан җөмһүрияте күпмедер күләмдә җирле халык теләген искә алып, ягъни астан күтәрелгән инициатива нигезендә барлыкка килсә, Татарстан җөмһүрияте халык теләгенә колак салмыйча өстән көчләп тагу, ягъни административ юл белән оештырылды. Дөрес, автор бу хакта ачыктан-ачык язарга ярамаганлыгын яхшы аңлый, әмма аның нәкъ шундый фикердә булуын «Республика мөнәсәбәте белән» дигән мәкаләсе бик ачык раслый. Икенче мәкаләсендә инде Г. Шәрәф, олы өметләренең гамәлгә ашмавын аңлап, милли дәүләтчелекне торгызу юлындагы минимум белән дә канәгатьләнергә туры килгәнлеген белдерә, бу, һич югында, милли-мәдәни мохтарият вазифаларын үтәргә җирлек тудырыр дип өметләнә. Бу — табигый, чөнки килеп туган вәзгыять белән исәпләшмичә эш йөртү дөрес булмас иде. Игълан ителгән җөмһүриятка багланган өметләрнең киләчәктә акланып җитмәвен, ягъни Үзәкнең сәясәтеннән алдануны да исәпкә алу кирәктер. Бу яктан караганда М. Вахитов белән М. Солтангалиев тә бик нык алданалар. Бигрәк тә большевистик Үзәккә ышанган һәм үзенең алар куйган максатлар өчен көрәше нәтиҗәләрен үзе үк татыган Солтангалиев. Алар Татарстан союздаш республикалар дәрәҗәсендә булыр, аларга бирелгән хокуклардан ул да файдаланыр дип инанганнар.

Безнең заман диктатурага нигезләнгән сәясәтнең киләчәге булмавын ачык күрсәтте. Әмма үз вакытында күпләр моны аңлый алмады, матур-матур «бәйнәлмиләлчел» шигарьләргә алданды. Моның барысын да мәкерле Сталинга гына сылтап калдыру бик үк дөрес булмас, чөнки ул еллардагы кара эшләрнең байтак өлеше шовинизм байрагын күтәргән Совет тәшкиләтләре тарафыннан да эшләнде. Патшалык хакимиятеннән калган мирас-идарәчелек аппараты, Ленин сүзләре белән әйткәндә, беркадәр Совет буяуларына буялса да, рус булмаган халыкларның «союздан ирекле чыгу» хокукларын «буш кәгазьләргә» әйләндерде. Мондый аппарат, әлбәттә инде, гайре рус булган милләтләрне «чын рус кешесеннән, бөек рус шовинистыннан, рус бюрократларыннан яклый алмады», чын бәйнәлмиләл җирлектә торган «советлаштырылган хезмәткәрләр бу шовинистик диңгездә сөткә батып үлгән чебен»[9] хәлендә калдылар. Татар-башкорт мәсьәләсен тикшергәндә менә бу хакыйкатьне дә истән чыгармаска кирәк.

Милли мәсьәләләрнең бөекмәмләкәтчелек, «бүленмәс һәм бердәмлек» мәсләгеннән чыгып хәл ителүен Совет аппараты белән шовинистик көчләргә генә кайтарып калдыру да дөреслеккә хилаф булыр иде. Бу очракта тагын бер факторны искә алу кирәк: ул да булса, милли-азатлык хәрәкәтләрендә бердәмлек булмау, төрле фиркаләргә, агымнарга бүленеп хәрәкәт итү. Большевиклар партиясе, бигрәк тә Сталин җитәкчелекне үз кулына алгач, бу таркаулыктан оста файдалана: «Милләтчелеккә каршы көрәш» шигаре астында суверен дип игълан ителгән җөмһүриятләрнең хокукларын чикләүләр башлана, милли мәдәниятләрне рус җирлегендә «бәйнәлмиләлләштерү» сәясәте үткәрелә, милли республикаларда туган телләрне файдалану кануннары тупас бозыла, бу өлкәдә тәфсилле кагыйдәләр системасын булдыру Ленин тәкъдим иткәнчә милли әһелләргә бирелми, ә бәлки бу эшне Үзәк тулысынча диярлек үз кулына ала. Бу өлкәдә эшләргә белеме һәм сәләте булган Галимҗан Шәрәф кебек зыялылар, галимнәр эзәрлекләнә башлый, эш урыннарыннан куыла. Мондый эзәрлекләүләр большевистик системага тугрылыклы хезмәт итеп килгән эшлеклеләрне дә читләтеп үтми. Моны дәлилләү өчен М. Солтангалиев язмышын гына искә төшерү дә җитә.

Татарстан җөмһүрияте төзелү милләтпәрвәрләрнең иҗтимагый эшчәнлекләрен ирекле җәелдерү өчен мөмкинлекләр булдырмады гына түгел, бәлки «милләтчелеккә кар-

шы көрәш» сылтавы белән Мәскәү хөкемдарлары бу юнәлештә яңадан-яңа ясалма киртәләр тудыралар. Галимҗан Шәрәф тә үзенең сәяси активлыгын киметергә мәҗбүр була. Аның каравы, ул үзенең гыйльми-фәнни эшчәнлеген бик нык көчәйтә. 1919—1920 елларда ук Г. Шәрәф Казан университетының тарих-филология факультетында лекцияләр тыңлый һәм бер үк вакытта Н. Катанов җитәкчелегендә төрки телләр, Н. Ашмарин җитәкчелегендә чуваш теле, В. Богородицкий җитәкчелегендә татар теле һәм гомуми лингвистика буенча фәнн-тикшеренү эшләре алып бара; шул ук елларда Үзәк Мөселман фәнни һәйәтендә (коллегиясендә) татар орфографиясен үзгәртү буенча зур тырышлык белән эшли. Бу юнәлештәге гыйльми эшләрен ул 1921—1922 елларда да дәвам итә һәм Академүзәкнең Шәрекъ бүлеген җитәкли, аның мөдире була. Шуның өстенә, татарча язманы үзгәртү буенча Татарстан хөкүмәте каршында оештырылган «өчлек»нең гыйльми сәркатибе вазифаларын да үти.

Бу елларда укытучылар, бигрәк тә тел укытучылары арасында татар орфографиясен үзгәртү-камилләштерү буенча кызу бәхәсләр кабынып китә. Бу мәсьәлә буенча «Мәгариф» журналы битләрендә җитди фикерле мәкаләләр белән тел галимнәре байтак чыгышлар ясыйлар. Аерым алганда, М. Корбангалиев, Ф. Хәмидуллин мәкаләләре игътибарга лаек. Тел белгече Г. Шәрәф мәкаләләре исә укучыларда аеруча кызыксыну уята. Бу бәхәсләр тирәнәя барган саен милли телләр мәсьәләләре буенча җитди фикер алышу, конференция үткәрү зарурилыгы сизелә башлый. Шуны истә тотып, Г. Шәрәф, Җ. Вәлиди, Х. Бәдигый, М. Корбангалиев шундый конференция әзерләү эшенә керешәләр. Аны оештыру эшләрен Мостафа Сөбхи җитәкчелегендәге гыйльми һәйәт башкара[10].

Конференция Бөтенрусия күләмен ала һәм 1918 елның 31 декабрендә Казанда ачыла. Аның эшендә Мәскәүдән, Оренбургтан, Уфадан, Әстерханнан, Уральскидан һ. б. шәһәрләрдән, төбәкләрдән килгән тел белгечләре һәм галимнәр катнаша. Делегатлар арасында күренекле тюркологлардан А. Самойлович, С. Малов, Н. Ашмарин, Н. Катанов һ. б. була.

Конференциядә орфография мәсьәләләрен тикшергәндә үзәк урынны гарәп графикасын камилләштерү һәм латин графикасына күчү-күчмәү проблемасы ала. Берәүләр, гарәп әлифбасын саклап калып, аны татар теле үзенчәлекләренә яраклаштыру-камилләштерүне алга сөрсәләр, икенче берәүләр гарәп графикасыннан латин хәрефләренә күчәргә

өндиләр[11]. Г. Шәрәф тә татар орфографиясен камилләштерү мәсьәләләрен тикшерүдә актив катнаша, үзенең фикер-тәкъдимнәре белән уртаклаша, «гарәпчеләр» тарафдары булуын ачыктан-ачык белдерә.

Күрсәтеп үтелгән гыйльми шөгыльләре белән бергә, Г. Шәрәф этнографик статистика буенча да фәнни тикшеренүләр алып бара, башлыча Татарстан җөмһүриятендә яшәүче халыкларның этнографик составын өйрәнә, аны күрше республикалардагы мәгълүматлар белән чагыштыра. «Шәрекъ халыклары күргәзмәсе»н оештыру буенча төзелгән комиссия әгъзасы буларак, ул Татарстан үзәк музее өчен этнографик экспонатлар әзерли, төрле-төрле диаграммалар, картограммалар төзи. Аларның күбесе демография мәсьәләләренә бәйле була. Соңыннан ул экспонатларның һәм карта-диаграммаларның бер өлеше Бөтенрусия авыл хуҗалыгы күргәзмәләрендә дә файдаланыла.

Егерменче еллар башында сәясәт сәхнәсендә «уңнар» белән «суллар» арасындагы көрәш төп вакыйгаларның берсенә әверелә. «Уңнар»ны әйдәп баручылар К. Мохтаров, М. Бурундуков, Ю. Вәлидов, А. Енбаев, Р. Сабиров, В. Исхаков булалар. С. Сәетгалиев, Б. Мансуров, Ш. Әхмәдиев, Ф. Сәйфи, Г. Ибраһимов, Ш. Шәймәрданов «суллар» сафына керәләр. Татарстан Үзәк Башкарма Комитетының татар телен гамәлгә кертү комиссиясендә, шулай ук милли статистика һәм уку-укыту эшләре комиссияләрендә эшләве дәверендә Галимҗан Шәрәф беренчеләре белән дә, икенчеләре белән дә еш очраша, аралаша. Ул үзе «уңнар» ягынарак тартыла, чөнки аның уйлавынча, «уңнар» милли мәсьәләгә, бигрәк тә милли мәдәнияткә күбрәк игътибар бирәләр, ә Г. Шәрәф бу мәсьәләләр белән аеруча кызыксына.

Гарәп графикасы, латин хәрефләре турында кызу бәхәсләр башлангач, күренекле тел галиме булган, татар орфографиясе һәм фонетикасы мәсьәләләрен тирәнтен өйрәнгән Г. Шәрәф, әлбәттә, читтә кала алмый. «Гарәпчеләр» һәм «латинчылар» арасындагы көрәш тюркологларның 1926 елның февраль-март айларында Баку шәһәрендә үткәрелгән I Бөтенсоюз корылтаенда югары ноктасына җитә[12].

Корылтайда катнашучы Татарстан делегациясен Г. Ибраһимов җитәкли. Делегация составында Г. Шәрәф, М. Корбангалиев, С. Атнагулов, Г. Максудов, Г. Рәхим, Г. Алпаров, Н. Хәким, Г. Сәгадәт булалар[13].

Г. Шәрәфнең шундый югары абруйлы делегация составына кертелүе һәм танылган галимнәр белән бергә коры-

лтай эшендә катнашуы һич тә очраклы хәл түгел. Бу вакытта ул татар теле, этнографиясе һәм тарихы буенча танылган галим була. Әле 1922 елда ук Шәрекъ педагогия институтында тел, этнография, тарих фәннәреннән студентларга лекцияләр укый, гамәли дәресләр алып бара, фәнни атамаларны өйрәнү комиссиясендә эшли. Аның югары уку йортларында тел гыйлемен, лингвистиканы өйрәтү ысулларын камилләштерү юнәлешендә башкарган хезмәтләре дә игътибарга лаек. Кыскасы, Г. Шәрәф егерменче елларда үзен киң карашлы галим һәм оста педагог итеп таныта, төрле фәнни җәмгыятьләрдә әгъза булып тора, яшьләрдән гыйльми кадрлар хәзерләүгә зур көч куя, аспирантларга җитәкчелек итә. 1923 елда Татарстанның этнографик картасын төзүе һәм этнография өлкәсендә башка хезмәтләре өчен ул Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе дипломы белән бүләкләнә. Аның «яңалиф»не телеграфта куллану өчен төзегән программасы Бөтенсоюз бүләгенә лаек була һәм Бөтенсоюз күләмендә кулланугa раслана, сукырлар өчен «яңалиф» орфографиясе нигезендә төзелгән Брайль әлифбасы да яхшы дип табыла.

Шулай да Г. Шәрәфнең төп эшчәнлеге Шәрекъ педагогик институты белән бәйле. Ул анда 1922 елдан алып 1937 елга кадәр фәнни-педагогик эш алып бара, бер үк вакытта (1933 елга кадәр) Татарстан җөмһүриятенең Үзәк административ комиссиясендә фәнни киңәшче дә булып тора.

Танылган галимнең хезмәтләре гыйльми җәмәгатьчелек һәм идарәче даирәләр тарафыннан лаеклы бәяләнә. ТАССРның биш еллык юбилее уңаеннан ул Үзәк Башкарма Комитетының һәм Татарстан хөкүмәтенең Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Анда мондый сүзләр язылган була: «Республика өчен бу тантаналы һәм шатлыклы көнне Үзәк Башкарма Комитетының һәм Халык Комиссарлары Советының җитәкче хезмәткәрләре Сезне озак еллар буена яхшы хезмәткәр буларак белүләрен белдерәләр. Сез даһи эшчәнлегегезне Совет дәүләте алдында торган бурычларның эчтәлеген һәм рухын аңлап башкардыгыз, бигрәк тә элек изелгән милләтләрне яңартуда һәрвакыт бөтен белемегезне, көчегезне, рухыгызны хезмәт ияләренең рәхәт яшәвенә, эшче-крестьяннар, рус һәм татарлар арасындагы ышанычны ныгытуга бирдегез. Без Сезне иң яшь Республиканың һәм Совет дәүләтенең аппараты, алдынгы хезмәт ияләре исеменнән сәламлибез»[14].

1926 елда Г. Шәрәф СССРның өлкәләрне өйрәнү Үзәк бюросына әгъза-корреспондент һәм СССР Фәннәр Академиясенең СССРдагы һәм чиктәш илләрдәге кабиләләр сос-

тавын өйрәнү Комитетына әгъза итеп сайлана. 1929 елда ул эксперименталь фонетика буенча Халыкара ассоциациягә хакыйкый әгъза буларак кабул ителә. Шунысы әһәмияткә лаек, СССРда мондый дәрәҗәгә академиклардан бары тик В. А. Богородицкий, Л. В. Шерба, А. И. Томсон һәм Р. И. Шор гына лаек булалар.

Менә шуларны истә тотканда, Г. Шәрәфнең Бакуда үткәрелгән тюркологлар корылтаенда катнашуы бик урынлы һәм табигый. Корылтайның икенче утырышында ук ул «Кавказ төркиләрен этник яктан өйрәнү буенча кичектергесез бурычлар» дигән темага чыгыш ясый. Ул үзенең нотыгында төбәктә яшәүче халыкларның телләрен һәм икътисади хәлләрен өйрәнү буенча төпле, кызыклы фикерләре белән уртаклаша. Корылтайның унынчы утырышында Г. Шәрәф яңадан «Татарларда һәм төрки халыкларда гарәп һәм латин хәрефләре системасын файдалану мәсьәләләре» дип аталган доклад белән чыга. Доклад корылтай делегатлары тарафыннан бик хуплап кабул ителә, аның тезислары чит ил матбугатында да басылып чыга. Андагы төп фикер гарәп графикасын яклауга, латин хәрефләренә күчүгә каршы чыгуга кайтып кала. Аерым алганда, ул катгый рәвештә: «Гарәп хәрефләре уку һәм язу өчен латин әлифбасына караганда күпкә җайлырак... Төрки халыкларның хәзер кулланыла торган гарәп әлифбасыннан латинга күчүләре чынбарлыкта ул халыкларны язма әлифбасы булмаган өммәтләр дәрәҗәсенә төшерәчәк... Бу адым төрки халыкларның мәдәни үсешен бик нык тоткарлаячак һәм берничә елга артка алып ташлаячак»,—дип белдерә. Гомумән, Г. Шәрәф фикерләре делегациягә партия өлкә комитеты биргән күрсәтмәгә каршы килми. «Латин хәрефләренә күчүгә принципиаль каршы төшмәскә, ә гамәлдә Татарстан өчен яңа әлифбага күчү әлегә мөмкин түгел дип исәпләргә»[15] дигән күрсәтмә бирелгән була.

Бу ике докладтан тыш, Г. Шәрәф «Туган телне укыту ысулларында яңа алымнар» һәм «Төрки телләрне укытудагы төп ысуллар» дигән докладлар буенча фикер алышуларда кызыклы фикерләргә бай чыгышлар ясый. Соңгы йомгаклау сүзе белән дә ул чыга.

Тулаем, Г. Ибраһимов «җитәкчелегендәге делегация корылтайда партия өлкә комитеты биргән күрсәтмәне төгәл үти. Соңыннан өлкә комитеты делегациянең корылтайдагы эшчәнлеген хуплаган карар да кабул итә. Әмма корылтайдан соң да «гарәпчеләр» белән «латинчылар» арасындагы көрәш сүрелми. «Суллар» тарафыннан оештырылган «Латин әлифбасы дуслары җәмгыяте» («Яңалиф») гарәп

хәрефләреннән латинчага күчү өчен көрәшне көчәйтә бара: «Яңалиф» төркемнәре һәм түгәрәкләре барлыкка килә, матбугат битләрендә шау-шулы кампания алып барыла. Шуның тәэсирендә ВКП(б)ның өлкә комитеты әлифба мәсьәләсендә үзенең элеккеге карашын үзгәртә. 1927 елның 3 маенда партия өлкә комитетында «Яңалиф» җәмгыяте эше турындагы мәсьәлә тикшерелә һәм махсус карар кабул ителә. Анда гарәп хәрефләреннән баш тарту һәм латинчага күчү кирәклеге әйтелә, партиянең район оешмаларына, матбугат органнарына, Мәгариф буенча Халык Комиссариаты тәшкиләтләренә латинчага күчүне көнүзәк мәсьәлә дип карарга дигән күрсәтмә бирелә. Тора-бара латин хәрефләренә күчүгә каршылык күрсәтү «милләтчелек» дип бәяләнә башлый. М. Солтангалиевнең партиядән чыгарылып кулга алынуыннан соң җөмһүрияттә сәяси вәзгыять аеруча киеренкеләнә. Татарстандагы бөтен оешмаларда, тәшкиләтләрдә диярлек «буржуаз милләтчелек» тарафдарлары «фаш ителә» башлый, милли мәнфәгатьләр файдасына әйтелгән һәр сүз «бәйнәлмиләлчелеккә каршы юнәлтелгән сыйнфый көрәш» дип бәяләнә.

Әлбәттә, мондый шартларда нинди дә булса мәсьәлә буенча объектив фикер әйтү һәм аны яклау мөмкинлекләре бик нык чикләнә, дөрес булу-булмавына карамастан «суллар» яклаган гамәлләр өстенлек ала башлый. Чынбарлыкта көрәш үз фикерләренә, үз инануларына таянып эш йөртүчеләр белән бернинди фәнни нигезләрне һәм реаль ихтыяҗларны искә алмыйча, Мәскәү таләп иткәнчә генә гамәл кылу тарафдарлары арасында бара. Мондый шартларда кемнең өскә калкачагы, кемнәрнең җиңеләчәге алдан ук хәл ителгән булуы аңлашылса кирәк. Әлифба мәсьәләсендә дә «латинчылар»ның җиңеп чыгуы һич тә көтелмәгән хәл түгел иде.

Милли хокуклар, милли мәнфәгатьләр белән Үзәкнең исәпләшмәвен чагылдыручы тагын бер дәлил — егерменче еллардан ук, хәтта Автономияле җөмһүрият игълан ителгәч тә, дәүләт эшләре белән идарә итүгә милли кадрларның бик аз җәлеп ителүе. Мәсәлән, 1944 елга кадәр Татарстан өлкә комитетының беренче секретарьлары булып йә яһүдләр, йә руслар, йә латышлар утырдылар. Бары тик 1944 елда гына ул урынга, ниһаять, татар кешесе З. И. Моратов билгеләнә. Әле бу вакытта да моңа ризасызлык белдерүче шовинистлар табыла.

Әлбәттә, татарларны җитәкчелектән болай читләштерү милли зыялылар арасында табигый ризасызлык тудыра. Әле 1926 елның декабрендә үк, ВКП(б) өлкә комитеты

бюросы утырышында ясаган чыгышында, Татарстан хөкүмәте рәисе Ш. Шәймәрдәнов бу хәлгә тирән борчылуын белдерә: «Без хакимият тәшкилэтләренә татар кадрларын күбрәк җәлеп итү турында еш сөйлибез,—ди ул.— Әмма хәл уңай якка бөтенләй диярлек үзгәрми, киресенчә, артка китү күзәтелә». Мәсәлән, 1926 ел ахырына җаваплы хезмәткәрләр арасында татарлар саны алдагы елдагыга караганда 3,24 процентка кимегән. Милли кадрлар саны бары тик техник хезмәткәрләр арасында гына, анда да әле нибары 0,29 процентка арткан. Кантоннар идарәсендәге татар кадрлары 1924 елдагы 29 процент урынына 1926 елда 24,4 процентка гына калган. Волостьларда бу сан 55 проценттан 42,5 процентка кадәр кимегән. Үзәк Башкарма Комитет әгъзалары арасындагы татарлар саны 53,3 проценттан 48 процент, шәһәр Советлары әгъзалары арасында 31,1 проценттан 26 процент кына калган. Хәтта утырышта катнашкан партия Үзәк Комитеты инструкторы да бу вәзгыятькә бәя биреп: «Кайбер тәшкилэтләрдә «милли кадрлар» санын арттыру өчен татарларны идән җыештыручы, йорт себерүче, ат караучы, йә ат йөртүче (кучер) итеп эшкә алалар икән. Бу бит идарә тәшкилэтләрен «татарлаштыру» түгел, ә бәлки «кучерлаштыру» булып чыга»,—дигән нәтиҗә ясый.

Хәер, мондый фактлар элегрәк тә күрсәтелә киленгән. Мәсәлән, 1924 елда язылган һәм 39 зыялы имза куйган хатта партиянең өлкә комитеты җитәкчеләре арасында милли кадрлар бик аз булуы, шул ук вакытта Бурундуков, Казаков, Исхаков, Еникеев, Бурнашев кебек тәҗрибәле татар зыялыларының эшсез калулары хакында әйтелә. Хат авторлары өлкә комитеты секретаре Хатаевич, Контроль комиссиясе рәисе Жуков, ОГПУ начальнигы Шварц милли кадрларны даими эзәрлеклиләр, дип белдерәләр һәм үзәктән әлеге җитәкчеләрне Татарстаннан чакыртып алуны таләп итәләр. Әмма ул чакта мондый дәгъвалар күтәрергә батырчылык итүчеләргә «милләтчеләр» мөһере сугыла. Соңыннан исә аларның гомерләре Сталин лагерьларында һәм төрмәләрендә өзелә.

Кызганычка каршы, милли кадрларны эзәрлекләүдә шовинистларга татар зыялыларының кайберләре үзләре дә булышлык күрсәтәләр. Бәлки алар үзләренең нинди тозакка эләгүләрен аңлап та җиткермәгәннәрдер, әмма моңа карап аларның татар милләтенә китергән зыяннары һич тә кимеми. Кайбер күренекле әһелләрнең мондый «абынулары» латин хәрефләренә күчү-күчмәү мәсьәләләрен хәл иткәндә ачык чагыла. «Латинчылар»ның иң гайрәтлеләре Фатыйх

Сәйфи, Сәлах Атнагулов һәм Шамил Усманов булалар. Аларның гамәлләрен партиянең өлкә комитеты секретаре Хатаевич хуплый. Димәк, латинча язуга күчәргә Үзәктән дә күрсәтмә булса кирәк. Ф. Сәйфи үзен «горур латинист» дип мактана һәм, латин хәрефләренә күчкәндә, 24 сәгать эчендә белемле кешеләр булачакбыз, дип ышандырмакчы була. Менә шуңа күрә Галимҗан Ибраһимов аны «шовинист-русификатор» дип атый.

Кыскасы, «латинчылар», бәлки үзләре дә аңламыйча, Сталинның милли мәсьәләдәге астыртын сәясәтенә булышалар. Әмма беренче мәлдә алар әле азчылык тәшкил итәләр һәм «Яңалиф» җәмгыятендә барлыгы 2000 ләп кенә кеше булалар, алары да тәмам инанып бетмиләр. Мәсәлән, 1927 елның көз айларында «латинчылар»ны рухландырып торучы Хатаевич бюро утырышында бу мәсьәләне тикшергәндә азчылыкта кала, хәтта, рухи төшенкелеккә бирелеп, ВКП(б) Үзәк Комитеты секретаре В. Молотов исеменә: «Монда биш-алты айдан да артык утырып булмас, мин бик арыдым, эшләр бик авыр. Мин киткәнче Казанга хәзер Үзәк Комитетта эшләүче Ежовны җибәрсәгез, бик әйбәт булыр иде»,— дип хат та яза[16].

Әлбәттә, партия өлкә комитетындагы хәлләр, милли кадрларга кырын караш, шовинизм рухының һаман көчәя баруы Галимҗан Шәрәфне дә битараф калдырмый. Ул татар әдәбиятының һәм мәдәниятенең киләчәк язмышы, татар халкы тарихының объектив тикшерелүе турында тирән борчыла, милли мәсьәләләрне хәл итүдә гаделлек өчен көрәшә. Латинчага күчү кампаниясе көчәеп, «гарәпчеләр»гә карата басым арта баруга чын күңеленнән хафаланып, ул әлеге шартларда мөмкин дип уйлаган соңгы чараны кулланырга батырчылык итә — үзен борчыган мәсьәләләр турында Сталинга хат яза. (Фәнни эзләнүләр вакытында без урысча язылган ул хатны табып алдык. Күренекле әдибебез Мөхәммәт Мәһдиев аны татарчага тәрҗемә итте. Ул 1990 елның 22 маенда «Әлмәт таңнары» газетасында һәм «Социалистик Татарстан»да, соңрак «Мирас» журналында (1994, № 2) басылып чыкты. Биредә әлеге хатның текстын тулысынча китерүне кирәк таптык:

«Хөрмәтле иптәш Сталин!

Сезгә үземнең «Төрки халыклар өчен латин хәрефләрен кабул итүгә карата» дигән хезмәтемне юллап, Сезнең игътибарыгызны түбәндәге моментларга юнәлтергә теләр идем.

1. Хәрефләрне алыштыру мәсьәләсе төрки халыклар арасында гомуми саннары берничә миллион исәпләнгән грамота-

лы һәм ярым грамоталы булган һәркемгә бик якыннан кагыла. Хәреф алыштыру мәсьәләсе — бу уку һәм язу процессында яңа күнекмәләр тудыру дигән сүз, ә бу, бик күп энергия һәм матди чыгымнар тотып, өр-яңадан укырга-язарга өйрәтү була. Миллионнарча укый-яза белүче кешеләр халыкның бөтен катлауларында таралган булу сәбәпле, бу эш массовый мәсьәлә булып тора һәм, һичшиксез, үзенә зур игътибар белән килүне таләп итә, уйламыйча гына әзерлексез эшләп булмаганлыкны күрсәтә, чөнки бөтен җәмгыяви катламнарның актив өлеше гадәттә халыкның укый-яза белгән өлешен тәшкил итә. Мондый адымның халыкның укый-яза белмәгән өлеше өчен нинди психологик тәэсир ясаячагы турында әйтеп тә торасы юк.

2. Абстракт рәвештә фикер йөрткәндә, хәрефләр алыштыру язма культура мәсьәләсендә чынлыкта бер халыкны элек яки бүген дә әлифбасы булмаган өммәткә төшереп калдыру дигән сүз, чөнки яңа графикага күчү элеккеге язмадан һәм язу күнекмәләреннән бөтенләй баш тартуга бәрабәр. Ике төрле язуны вакытлыча саклау һәм яңа графикага әкренләп күчү дә бары тик бу фактны яшерү, күчү кыенлыкларын өлешчә җиңеләйтү генә була.

3. Хәрефләр алыштыруга җитди карасак, бу гамәл дәүләттән зур чыгымнар таләп итәчәк, наданлыкны бетерүне яңадан башлауга, китапларны яңадан басуга, мәктәпләрдә ике төрле әлифба өйрәтүгә һ. б. бәйле өстәмә матди чыгымнарга һәм күптөрле административ чаралар куллануны тәэмин итүгә китерәчәк.

4. Югарыда күрсәтелгән күпләп сарыф ителәчәк көчдәрман һәм матди чыгымнар ахыр чиктә хәреф сызымнарының алышынуына гына китереп, яңа хәрефләрне өйрәнүчеләргә ни мәдәни, ни икътисади яктан бернинди уңай нәтиҗәләр бирмәячәк, чынлыкта кирәклеге әллә ни мөһим булмаган формаль адым гына булып калачак.

5. Уку-язуның тизлеге полиграфик яктан да, уку-язу ягыннан да латин хәрефләренең бүген төрки халыкларда гамәлдә булган һәм камилләштерелгән гарәп графикасыннан тулаем алганда бернинди өстенлеге дә юк. (Бу беркадәр парадоксаль булып яңгыраса да, чынбарлыкта һичшиксез нәкъ шулай.) Бу мәсьәләләр мин Сезгә җибәрә торган хезмәтемдә фәнни-өйрәнү ысуллары ягыннан бик җентекле тикшерелгән.

6. Хәрефләрнең халыкара кулланылышлары ягыннан карағанда да, һәр тел аерым-аерым булганлыктан, латин әлифбасының бәйнәлмиләллеге тышкы яктан гына.

7. Төрки халыкларның мәнфәгатьләре күзлегеннән кара-

ганда, бернинди уңай алшартлар булмаган көе әлифба алыштыру мәсьәләсен кую һәрьяктан зарарлы, ул гавамның ачуын кабартуга һәм ризасызлыгы артуга, Совет хакимиятенең мәдәни чараларыннан гомумән канәгатьсезлек белдерүенә китерәчәк. Гамәлдәге хәрефләрне латинчага алыштыру төрки халыклар арасында көчләп урыс транскрипциясе кертү турындагы 1907 елгы патша фәрманының («31 март кагыйдәләре») эчен тышка әйләндерү буларак кабул ителәчәк. Миссионерларның һәм ярыммиссионерларның латин хәрефләрен кертүдә ачыктан-ачык яки астыртын рәвештә катнашуы халыкның ризасызлыгын көчәйтәчәк кенә. Бәлки әлифба алыштыру бүген яхшы ният белән эшләнәдер, әмма соңгы нәтиҗәләре мәдәни үсештә торгынлыкка китергәнлектә, файдасыннан зарары күбрәк булачак.

8. Югарыда әйтелгәннәргә дә карамастан, бу мәсьәлә буенча Шәрекъ Совет җөмһүриятләрендә яраклы һәм яраксыз алымнар белән чикләнмәгән коткылар таратыла, чынбарлыкта, бигрәк тә быел, латин графикасына көчүгә каршы ни телдән, ни язма рәвештә бер генә чыгышка да мөмкинлек калдырылмады.

9. Милли коммунистлар арасында күпмедер «латинчылар» булуы чын вәзгыятьне билгеләми, чөнки аларның барысы да диярлек якыннанрак танышканда йә төзәлмәс карьерачылар, йә үз карашларына җавап бирә алмый торган сай акыллы халык булып чыга.

...Бу мәсьәләнең искиткеч зур сәяси әһәмияткә ия булуын истә тотып, Сезнең секретарьлардан берәрсенең минем бу язмам белән һәм узган ел Бакуда уздырылган тюркологларның беренче корылтаендагы докладларда һәм чыгышларда бәян ителгән фикерләр тупланган стенографик хисап белән Сезне дә таныштырып, Сезнең шәхсән үзегезнең бу мәсьәләгә беркадәр игътибар бирүегезне үтенергә җөрьәт итәм...

Стенографик хисапны Сезгә җибәрмәгән булсалар, аны Мәскәүдәге Бөтенрусия Шәрекъне өйрәнү ассоциациясеннән сорап ала аласыз. Инде тюркологлар корылтаеның бу мәсьәләләр буенча кабул иткән карарларына килгәндә, кызганычка каршы, алар ярым-йорты хәлдә һәм бу Шәрекъ җөмһүриятләрендәге партия тәшкиләтләренең бик аз ярдәм итүләре белән аңлатыла. Бу мәсьәләнең зур игътибарга лаек булуын тагын бер мәртәбә ассызыклап әйтүне кирәк табам.

Сезне ихтирам итүче Г. Шәрәф. 1927 ел. 7 май.
Минем адрес: Казан шәһәре, Жуковский урамы,
15 нче йорт, 4 нче фатир. Г. Шәрәф»[17].

Бу хатны язып, дөньякүләм мәшһүр тел белгече Галимҗан Шәрәф сабыйларча беркатлылык күрсәткән, дип

әйтү дөрес булмас иде. Ул, чын галим буларак, үзенә куркыныч янаса да, соңгы чарадан файдаланырга тели: ятып калганчы — атып кал, диләр бит. Хаттан күренгәнчә, китергән дәлилләр төпле, җентекләп уйланылган.

Мәгълүм булганча, 1927 ел — «арыслан»ның сикерергә әзерләнгән чоры: Ленин көрәштәшләре Троцкий, Каменев, Зиновьев, Бухарин, Рыковларны һ. б. алып ташлар өчен мәкерле планнар әзерләнгән вакыт. Барысы да диярлек югары белемле, чит илләр, чит җирләрне күргән, инкыйлаби көрәш юллары узган зыялылар, үз теләкләре белән диярсең, башларын өч класс белемле, әйтергә кирәк, талантлы плагиат-авантюрист куйдырган бүкәнгә салганнар...

Г. Шәрәф тә «даһи юлбашчы»га ышаныч баглый әле: фикерләрен ачыктан-ачык әйтеп аңлата, өй адресларын яза, җавап көтә. Күп тә үтмәс, «халыклар атасы» тәмам ныгып алгач, шул адрес белән килерләр дә, төн уртасында Галимҗанның ишеген кагарлар, менә сиңа татар әлифбасы, диярләр. Ә төрмәдә әлифба бер генә: кириллица да түгел, латинча да түгел, ул — диварга шаку, ул — бәйнәлмиләл әлифба. Күренекле әдип Ибраһим Сәлахов әлеге әлифба турында үзенең «Колыма хикәяләре»ндә: «Артык күпкә китмәсен өчен, егерме дүрт аваз гына файдаланыла иде», — дип искә ала.

ОГПУның татар бүлеге начальнигы Кадушин, Г. Шәрәф Сталинга әлеге хатын язганнан соң егерме көн үткәч, ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты секретаре Хатаевичка «Бик яшерен, бары тик Хатаевичның үзенә генә» дигән хат юллый. Хатта татарлар арасында милләтчелекнең көчәюе, бу тенденциянең Ф. Әмирхан, Н. Хәким кебек язучыларның китапларын бастырып чыгарырга омтылышта сизелүе, «аеруча бертуган Шәрәфләрнең халыкка тәэсире зур» булуы, «татар зыялылары белән динчеләр арасындагы гади мулладан алып мөфти Риза Фәхретдиновка кадәр элемтәнең бертуган Шәрәфләр аша алып барылуы» әйтелә. Бер уңайдан «Кызыл Татарстан» газетасы да гаепләнә: янәсе, газета «буржуаз шагыйрь Габдулла Тукайга һәйкәл кую кирәклеген күтәрә».

Бертуган Шәрәфләрнең хәлен тагын бер вакыйга бик нык катлауландырып җибәрә, аларны эзәрлекләүләрне тагын да көчәйтә. Эш шунда ки, әлифба алыштыру мәсьәләсе буенча бер төркем партиясез татар зыялылары (галимнәр, рәссамнар, укытучылар, журналистлар, табиблар, язучылар, студентлар, агрономнар) И. Сталинга, партиянең Татарстан өлкә комитеты пленумына һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты инструкторы Пшеничныйга 82 кеше имза куйган хат

җибәрәләр. Хатта бәян ителгән төп фикер — гарәп графикасыннан латин язуына күчмәскә, чөнки ашык-пошык әлифба алыштыру татар халкын күп гасырлар гамәлдә булган бай мәдәниятеннән аерачак, күп өлкәләрдә торгынлыкка китерәчәк. Бу хатны язуга Г. Шәрәфнең дә катнашы бар. Әлеге хатны язуны үтенеп, аның фатирына Хәсән Исхаков белән Садри Вәлидов киләләр. «Бу — безнең үтенеч кенә түгел, бәлки бөтен татар зыялыларының үтенече»,— диләр алар. Галимҗан үтенечне кире какмый, хатның текстын язып бирә. «82»ләрнең әлеге хаты белән Г. Шәрәфнең Сталинга язган хаты арасында күзгә ташланып торган аваздашлык сизелә. Әмма Галимҗан бу хатка үзе имза куймый. Моны ул болай аңлата: «Миңа «петиция» рәвешендә И. Сталинга мөрәҗәгать итү ошамый»,— ди. Ә безгә калса, бу — аның үз-үзен кабатлыйсы гына килмәведер. Шул ук вакытта ул, ихтимал, Сталинга төрле яктан төрле кешеләр тарафыннан язылган хатлар юллауның әһәмияткә ия булуын да искә алгандыр.

«82»ләр хаты «Кызыл Татарстан» газетасында партия өлкә комитетының латин әлифбасына күчү турындагы карары басылу уңае белән язылган. Хатның авторлары, Г. Шәрәф кебек үк, «бөек юлбашчы»ның татар мәдәнияте турында кайгыртучанлык күрсәтәчәгенә, «гарәпчеләр»не эзәрлекләүләргә чик куячагына һәм Татарстанда бу мәсьәләне гадел хәл итүгә булышачагына ышаналар.

ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты «82»ләр хаты буенча махсус карар кабул итә. Анда мондый юллар бар: «1. Төрки әлифбадан латин хәрефләренә күчүнең асылы буенча мәсьәлә хәл ителгән дип санарга һәм бу хакта бәхәс кузгатмаска. 2. Бу мөрәҗәгатьнең язылуы ВКП(б)га каршы юнәлтелгән буржуаз милләтчел элементларның активлашуын күрсәтә. 3. Өлкә комитет бюросына бу факттан тиешле нәтиҗәләр ясарга, кирәкле дип табылган иҗтимагый-оештыру чаралары күрергә һәм аңлату эшләре үткәрергә кушарга»[18].

«Оештыру чаралары» да күрелә, «аңлату эшләре» дә алып барыла. Нәтиҗәдә, хат авторларының күбесе үз имзаларыннан баш тартырга мәҗбүр булалар. Җыелышларда һәм матбугатта «халык алдында тәүбә итү»ләр башлана. Мондый җыелышлар бик зурлап уздырылалар, газеталарда «тәүбә» мәкаләләре өчен махсус бүлек кертелә. Хат авторларын астыртын эзәрлекләүләр дә киң колач ала.

Менә шушы көннәрдә бертуган Шәрәфләрнең исемнәре вакытлы матбугат битләрендә еш кабатлана башлый, хәтта турыдан-туры аларга багышланган мәкаләләр дә басыла.

Шундыйларның берсе — «Кызыл Татарстан» газетасында «А. К. Б.» имзасы белән басылган «Шәрәфлекне чикләргә кирәк» дигән мәкалә. Әйе, монда «Шәрәф» турында гына түгел, ә бәлки «шәрәфлек», «шәрәфчелек» турында сүз бара. «АКБ»ның язуына караганда, «шәрәфчелек»не Шәрәфләр фамилиясенә генә бәйләп калдырырга ярамый, чөнки бу төркем үзен бөтен партиясез зыялылар вәкиле, аның авангарды итеп күрсәтә. Алар әле моның белән генә чикләнмиләр, ә бәлки тотнаксызрак коммунистларга йогынты ясарга да тырышалар. «Шәрәфчелек»нең тамыры менә шуңа барып тоташа, имеш[19].

Галимҗанның туганнары бу көннәрдә авыр хәлдә калалар. 1927 елның 9 июлендә ОГПУ тарафыннан Гыйльметдин Шәрәф кулга алына. 27 декабрьдә Борһан Шәрәфне кулга алу турында әмер бирелә һәм 28 декабрьдә аның өендә тентү үткәрелә. 1928 елда Шәһер Шәрәф кулга алына һәм Коми АССРга сөрелә. Боларның барысын да Галимҗанның Сталинга язган хатына җавап дип карарга кирәк.

Сталинның милли мәсьәлә буенча егерменче еллар башында ук җитлеккән уй-планнары («автономияләштерү планы»н да кертеп), ниһаять, тормышка аша, бу өлкәдә милләтләрне көчләп якынайту һәм берләштерү сәясәте өстенлек ала. Әлбәттә, бу сәясәткә юнәлешне Үзәк бирде һәм җитәкләде. Латин хәрефләренә күчүне генә алыйк. Тюркологларның 1926 елгы корылтаеннан соң өч ел узгач (1929 елның февралендә), азәрбайҗан делегациясе тәкъдимен хуплап, латин графикасына күчү турында декрет чыгарыла һәм 1931 ел башыннан ул барлык төрки җөмһүриятләрдә тормышка да ашырыла. Әлбәттә, сталинчылар өчен бу «яңа дистанциягә сикерү» өчен хәзерлек кенә була. 1939 елда яңа декрет чыгарыла һәм латин әлифбасы кириллица белән алыштырыла. Шулай итеп, патша хакимияте заманнарында Ильминскийлар булдыра алмаган бөекмәмләкәтчел максат большевистик Советлар хакимияте тарафыннан тормышка ашырыла. Бу бөек руслык шовинистларының зур җиңүе була. А. Рорлих раслаганча, кириллицага күчү 1917 елда исламга каршы башланган һөҗүмнең бер мәдәни тармагы гына ул: асыл максат исә «Советлар Союзы халыкларын якынлаштыру» шигаре астында барлык өммәтләрне руслаштырудан гыйбарәт була, ә латин хәрефләреннән кириллицага күчерү шушы максатны гамәлгә ашырудагы бер корал гына[20].

Шәхес культы чорында Советлар хакимиятенә таянып үткәрелгән бу сәясәт төрки халыклар, шул исәптән татар

мәдәнияте өчен дә чын фаҗига булды. Берничә ел эчендә ике тапкыр әлифба алыштыру төрки халыкларны гасырлар дәвамында тупланган рухи мирасларыннан аерды, мәдәни торгынлыкка китерде. Бүгенге яшь буынның үз туган теленнән аерылып руслашуы, бөтен бер буынның манкортларга әйләнүе нәкъ менә шуның белән аңлатыла да. Бу яктан караганда, ул еллардагы «шәрәфчелек»нең хаклы булуы, тирәнгәрәк үтеп һәм алгарак карап фикер йөрткәнлеге бүген тулысынча расланды инде. Бүген безгә шушы фаҗигале сәяси вакыйгалардан сабак алырга һәм, дөрес нәтиҗәләр ясап, заманында җибәрелгән авыр хаталарны төзәтергә кирәк.

КАҺАРМАН РУХЛЫ ГАЛИМ

Ачыктан-ачык яла ягулар, турыдан-туры кулга алулар Шәрәфләрне туган илдән, гаиләләреннән, дусларыннан аера, илнең төрле тарафларына тарата. Шундый шартларны истә тотып, Галимҗан бик сак булырга тырыша. Ул үзенең һәм сеңелләренең күзәтү астында булуларын бик яхшы аңлый. Шуңа күрә аны нәрсәдә булса да гаепләү кыен була. Югары зыялылык, нечкә һәм үткен акыл хәтта дошманнарында да аңа карата хөрмәт уята.

«Латинлаштыру»га совет һәм партия оешмалары да керешкәч, Г. Шәрәф фәнни-тикшеренү эше белән шөгыльләнүен тагын да тырышыбрак дәвам итә. Әлбәттә, эшчәнлектә мондый «борылышлар» ул елларда бер Г. Шәрәфкә генә хас нәрсә түгел. Әмма Галимҗанның бүтәннәрдән үзенчәлеге шунда ки, ул тоталитар режим шартларында да үз урынын таба алды: лингвистика фәнен, татар теле белемен үстерүгә зур өлеш кертте, мәшһүр галимгә әверелде.

1927 елның 1 февралендә Г. Шәрәф педагогия институтының әдәбият-лингвистика комиссиясенә гариза яза һәм үзенең эксперименталь фонетика өлкәсендә махсус эшләргә теләге барлыгын белдерә. Профессор В. А. Богородицкий икенче көнне үк аның гаризасына «Г. Шәрәфне фәнни-әдәби эшчәнлеге һәм эксперименталь фонетика кабинетында элек тә эшләве буенча яхшы белгәнлектән, мин аны шушы кабинетка кече ассистент итеп сайларга тәкъдим итәм» дигән резолюция сала. Бу вакыйгадан соң ике ел үткәч, профессор институт директоры исеменә үзе гариза яза. Гаризаның эчтәлегеннән аңлашылганча, В. А. Богородицкий, Г. Шәрәфне кече ассистент итеп алганда ук аны үз урынына

хәзерләүгә исәп тотып эш йөрткән булса кирәк. «4 ноябрьдә (1930 ел — *Р. В.)* минем фәнни-укыту эшчәнлегемә 50 ел тула, — дип яза ул гаризасында. — Һәм мин, олыгаюым вә исәнлегемнең начарлануы сәбәпле, агымдагы уку елы ахырында педагогия институтында укытуымны туктатырга мәҗбүрмен. Әлбәттә, бу минем фәнни хезмәтемне дә туктатуым дигән сүз түгел. Мәгълүм булганча, үзебездә һәм чит илләрдә дә Казан шәһәре тел белемен өйрәнү өлкәсендә зур бер мөстәкыйль лингвистика мәктәбе үзәге буларак билгеле. Фонетика кабинеты СССРның горурлыгы дип санала икән, бу аның фәнни-тикшеренү эшләре өчен тупланган кирәкле җиһазларына гына түгел, ә бәлки башкарган фәнни эшләренә дә бәйле. Шуны истә тотып, үз урыныма тел белеме һәм эксперименталь фонетика өлкәсендә тапшырылачак җаваплылыкка лаек булырдай варис калдыруга үземнең әхлакый бурычым итеп карыйм. Мондый галим дип мин Галимҗан Шәрәфне саныйм. Аны мин 1918 елдан бирле — 10 елдан артык беләм. Ул — минем җитәкчелегем астында эшләгән иң талантлы, иң сәләтле фәнни хезмәткәр. Мине алыштырачак кеше буларак, мин сездән аны профессор исеменә тәкъдим итүегезне үтенер идем, чөнки шулай иткәндә ул матди яктан тәэмин ителәчәк һәм фәнни, укыту, тел белеме вә эксперименталь фонетика өлкәсендә эшләү өчен уңай мөмкинлекләр алачак. Минем әлеге бәяләмәмне гадел булмаган шәхси фикер генә дип кабул итмәсәгез иде, чөнки Г. Шәрәфнең «Сонорная деятельность татарских гласных» дигән тирән эчтәлекле гыйльми хезмәтенә атаклы француз лингвисты А. Мейе да мактаулы бәя бирә. Прага лингвистика түгәрәге дә, минем бәяләмәләремне раслап, әле 1923 елда ук Г. Шәрәфнең фәнни хезмәтләренә югары бәя бирде»[21].

Профессор В. А. Богородицкий гаризасындагы сүзләргә өстәп тагын шуны да әйтергә мөмкин: ул елларда Галимҗан Шәрәфнең фәнни-тикшеренү эшләрендәге тәҗрибәсен өйрәнү өчен Казанга еш кына төрле республикалардан да галимнәр килә. Мәсәлән, 1928 елның декабрендә Төрекмәнстаннан махсус рәвештә тел белгече А. П. Поцелуевскийның килгәнлеге мәгълүм.

Профессор ярдәме белән Г. Шәрәф әкренләп лаборатория эшләренә җитәкчелек итә башлый һәм фән кыясының яңа биеклекләренә күтәрелә. Сәләтле галим өчен бу табигый хәл. Гыйльми эшчәнлеккә ашкынулы дәрте, зур ихтыяр көче, озак вакытта исәпләнгән уй-хыяллары булган галим өчен бигрәк тә. Әйе, нинди генә кыенлыклар булганда да төшенкелеккә бирелмәүче Г. Шәрәф 30 нчы елларда фән

өлкәсендә тагын да дәртләнебрәк эшли башлый. «Кешелек дөньясындагы телләрнең ижтимагый-икътисади формацияләргә бәйләнештәге үсешләре» дигән тема өстендә тикшеренүләр алып бара. 1934 елның җәендә Мәскәүдә һәм Ленинградта булып, ул анда әлеге юнәлештә эшләүче галимнәр белән очраша, темасын, булачак хезмәтенең аерым бүлекләрен ачыклый. Аның бу планнарын философия академиясе дә хуплый. Академик И. И. Мещанинов, мәсәлән, Г. Шәрәфнең эш планы һәм тикшеренүенең асылын чагылдырган тезислары белән танышкач, галимнең бу эшен бик мөһим дип югары бәяли. Аны бу бәяләмәсенә Тел белеме институты директоры Якобсон, академик А. Н. Самойлович, СССР Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты Л. В. Щерба да кушылалар. Соңрак, Г. Шәрәфкә профессор исеме бирү мәсьәләсе күтәрелгәч, әлеге галимнәр үзләренең элеккеге бәяләмәләрен тагын да тулыландыра төшеп кабатлыйлар. Аерым алганда, Казан дәүләт педагогия институтының гыйльми советы исеменә җибәрелгән бәяләмәсендә академик А. Н. Самойлович: «Галимҗан Шәрәфнең эшләренә объектив бәя биреп, без аны мәшһүр совет лингвисты итеп танырга тиешбез. Ул — татар теле белеме өлкәсендәге иң зур белгеч», — дип яза.

Кыскасы, гыйльми-фәнни эшчәнлегенә бәяләмә бирүчеләрнең һәммәсе дә Галимҗан Шәрәф лингвистика һәм тел белеме өлкәсендә докторлык дәрәҗәсе һәм профессор исеме бирергә әлбәттә, лаек, дигән фикер белдерәләр. Нәтиҗәдә, Гыйльми совет аны, докторлык диссертациясе якламаган килеш, профессор исеменә бертавыштан тәкъдим итә. Бу вакытта инде Г. Шәрәфнең матбугатта күпсанлы фәнни хезмәтләре басылган була. Әдәби иҗат өлкәсендә дә каләм тибрәтә — 300 дән артык шигырьләр, бәстләр, мәсәлләр яза. Ул тупланган фәнни материаллар, статистика мәгълүматлары һәм төрле газета-журналларда басылган мәкаләләре, архивларда сакланып галимнәрнең игътибарын көтә. Аларның күбесенең әле беркем тарафыннан да укылмаган да булуын искә алсак, галимнең фәнни мирасын өйрәнүнең никадәр әһәмиятле мәсьәлә булуы аңлашылса кирәк. Чөнки Г. Шәрәфнең үз вакытында вакытлы матбугатта басылып онытылган яки бөтенләй дә басылмаган килеш аның шәхси архивында гына сакланган ул материаллар башлыча Татарстан тарихының төрле аспектларын өйрәнүгә багышланганнар, этнография, милли мәдәният мәсьәләләрен яктырталар. Г. Шәрәфнең фәнни мирасы нинди күпкырлы булуын тулырак күз алдына китерү өчен аларның кайберләрен генә атап китү дә җитә: «Чыңгыз хан

дәверендә татарларның һәм башка халыкларның тормышы», «Җәдитчелекнең мәдәният тарихындагы урыны», «Мелла Хөсәен Фәйзханов» дигән хезмәтләре, икътисади география дәреслеге буенча материаллар, схемалар, карталар, мәдәният тарихына бәйле материаллар һәм хатлар, докладларының текстлары, тезислары һәм башкалар.

Ышанып әйтергә мөмкин: Галимҗан Шәрәфне Татарстанның бердәнбер энциклопедик галиме дип атасак һич тә арттыру булмас. Аның бай мирас хәзинәсен җентекле өйрәнү халкыбызның, җөмһүриятебезнең тарихын гадел һәм объектив яктыртуга, моңа кадәр яшәп килгән тупас хаталарны, шовинистлар таккан «нәзари фикерләр»не төзәтүгә зур мөмкинлекләр тудырыр иде, дип уйлыйбыз.

Мәгълүм булганча, моннан берничә ел гына элек Гаяз Исхакыйның исемен телгә алу да «кяферлек» дип санала иде. Хәзер ул заманнар үтте инде. Вакытлы матбугатта Г. Исхакыйга кагылышлы бик күп мәкаләләр басылды, газета-журналлар аша байтак әсәрләре укучыларга кире кайтарылды, әсәрләренең тупланмасы күләмле аерым китап буларак та («Зиндан») нәшер ителде. Моңардан тыш, олуг әдипкә багышлап конференцияләр уздырылды, күргәзмәләр оештырылды, тантаналы төстә 115 еллык юбилее билгеләп үтелде.

Бу — бүген. Әмма сталинчыл дәһшәтле елларда да Гаяз Исхакыйны олуг язучы, танылган җәмәгать эшлеклесе буларак хөрмәтләүче, аның иҗатына ихтирам белдерүче куркусыз олы җаннар юк түгел иде. Шундыйларның берсе — Галимҗан Шәрәф булды. Г. Исхакыйны хәтта Галимҗан Ибраһимов та «кара әдәбият вәкиле, ак эмигрант» дип каһәрләгән, югары уку йортларында һәм зыялылар арасында: «Гаяз Исхакыйның иҗатын өйрәнү кирәкме?» дигән сорау туган заманда Г. Шәрәф педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасында эшләүче хезмәттәшләре алдында Исхакый турында махсус доклад белән чыгыш ясый. «Гаязның иҗатын өйрәнүгә берьяклы гына килергә ярамый,— ди ул үзенең докладында.— Бу мәсьәләдә киң карашлылык булырга тиеш. Аның әсәрләрен бүтән татар язучы-шагыйрьләренең рухи мираслары белән бергә тикшерү һәм бәяләү заруури. Олуг әдипнең исемен дәреслекләрдән һәм матур әдәбият тарихыннан алып атуны хуплау һич тә мөмкин түгел».

Әмма кафедра утырышында катнашучыларның барысы да бу мәсьәләдә Г. Шәрәф тарафдарлары булмыйлар, киресенчә, аның Г. Исхакыйны яклау фикерләренә кискен каршы чыгалар. Мәсәлән, кафедра әгъзасы Яфаров: «Институтта Г. Исхакый әсәрләре бөтенләй дә өйрәнелергә тиеш

түгел, уку-укыту процессында без алардан файдаланмаска тиешбез»,— ди. Утырышта катнашучы язучы Гадел Кутуй, Яфаровны хуплап: «Исхаков әсәрләренә татарчадан урысчага тәрҗемә ителгән җыентыкларда урын булмаска тиеш»,— дип өсти. Ихтимал, ул елларда мондый фикердә торучылар бер алар гына булмагандыр.

Әмма Г. Шәрәф тә үз мәсләгеннән баш тартырга, тәнкыйть фикерләреннән куркып чигенергә җыенмый. «Әлбәттә,— ди ул заман куйган кырыс таләпләрне искә алып,— яшьләрне рухи тәрбияләүне иң әүвәл инкыйлаби язучыларның әсәрләре нигезендә алып бару зарури. Әмма шул ук вакытта эстетик тәрбия турында сүз барганда буржуаз, хәтта феодализм чорындагы әдәбиятның һәм дә халык авыз иҗаты әсәрләренең дә файдалы булуы ихтимал. Аларда инсани (гуманистик) идеяләр алга сөрелә икән, нигә файдаланмаска. Бу фикерне танылган рус әдипләре һәм зыялылары да хуплыйлар. Аерым алганда, М. Горький, А. В. Луначарский, Матур әдәбият академиясе рәисе П. С. Коган һ. б. шундый ук фикердә торалар. Алар, мәсәлән, Октябрь инкыйлабына кадәр иҗат ителгән татар әдәбияты әсәрләрен дөньяга чыгаруга каршы килмиләр, киресенчә, бу — кирәкле эш, дип саныйлар. Аерым алганда, Гаяз Исхакыйның минем тарафтан урысчага тәрҗемә ителгән ике хикәясен басып чыгаруны хуплыйлар».

Әйе, Г. Шәрәф моһаҗирлектә дә иҗатын дәвам иттергән мәшһүр әдибебез Гаяз Исхакый турындагы фикерләрен бoргаланууларсыз, кыю белдергән. Аның бу фикерләре югары фәнни бәягә лаек. Шуңа күрә Г. Шәрәфнең кафедра утырышында ясаган чыгышының ахырын сүзгә-сүз китерү урынлы булыр.

«Исхакый иҗаты мәсьәләсенә килгәндә,— ди ул сүзен йомгаклап,— барыбызга да бик яхшы мәгълүм булганча, ул, Галимҗан Ибраһимов белән бергә, Октябрьгә кадәрге татар әдипләренең иң күренеклесе. Әгәр тәнкыйтьчеләр, революциягә кадәрге татар әдәбиятына чынбарлыкны һәм көндәлек тормышны реаль тасвирлау хас, дип бәялиләр икән, Исхакый иҗатында бу төсмерләр аеруча тулы чагылалар. Өстәвенә әле, Исхакыйның күпсанлы әсәрләре буржуаз дәвердәге татар әдәбиятындагы иң кыйммәтле вә нәфасәт ягыннан иң камил саналган әсәрләрнең яртысын ук булмаса да, иң кимендә өчтән берен тәшкил итәләр. Без әдәбиятка җәмгыяви продукт дип карыйбыз, димәк, аңардагы кыйммәтле дип исәпләнгән һәрнәрсә иҗтимагый казаныш дип каралырга тиеш. Әдипләрне һәм шагыйрьләрне матди яки рухи шәкелдә дәфен итсәк тә, аларның әсәрләрен барыбер югалтмыйбыз, саклыйбыз бит»[22].

Күренә ки, Г. Шәрәф татар кешеләренең Октябрьгә кадәрге тормышын Гаяз Исхакыйдан башка берәүнең дә хакыйкый тәгәллек белән дөрес тасвирлый алмавын бик яхшы аңлый. Чынлап та, татар мәдрәсәләренең эчке тормышы, авыл кешеләренең уйлары-фикерләре, шәһәр байлары балаларының әхлакый түбәнлекләре кем иҗатында шундый үтемле образлар аша тасвирлана соң? Бербөтен әдәбияттан шундый югары нәфасәтле әсәрләрне сызып ташлау әдәбиятны ярым-йорты хәлдә калдырмыйммыни? Исхакыйның иҗатын тирәнтен өйрәнми торып, бер әдипнең генә түгел, ә бәлки татар әдәбияты тарихын гомумән дә тулы килеш күз алдына китерү мөмкин түгел.

Шуны да кисәтү кирәктер, Г. Шәрәф кафедрадагы чыгышында Исхакыйның моһаҗирлектәге иҗатына тукталмый һәм бәя бирми. Бу, бердән, «тимер чаршау» сәясәте нәтиҗәсендә Г. Исхакыйның соңгы әсәрләре Ватанында мәгълүм булмау белән аңлатылса, икенчедән, Г. Шәрәф үзе дә, илдә хөкем сөргән шушы көннәрдәге сәяси вәзгыятьне истә тотып, «кырмыска оясына таяк тыгу»ны урынсыз дип санагандыр, күрәсең. Шулай да, утырыштагы чыгышларга бәя биреп, Галимҗан үзенең Исхакый иҗатына булган карашын имеш-мимешләргә урын калдырмаслык итеп өзеп әйткән. «Иртәме-соңмы,— дигән ул,— безнең тәрбиячеләребез һәм тәрбияләнүчеләребез (студентлар күздә тотыла.— *Р. В.*) Исхакыйны укыячаклар. Әгәр дә без аның иҗатын тиешенчә тикшермәсәк һәм ясалма рәвештә эндәшмәү юлына бассак, «Тәвә кошы» сәясәте булмасмы? Минемчә, бу — житди мәсләки мәсьәлә»[23].

Егерменче еллар ахыры — утызынчы еллар өчен мондый аек, чын фәнни фикердә булу һәм моны ачыктан-ачык бәян итү Галимҗан Шәрәфнең искиткеч зур акыл иясе, объектив һәм кыю карашлы галим икәнлеген күрсәтә.

«Латинчылар»га каршы көрәшеп «милләтче» мөһеренә «лаек булган» Г. Шәрәф «буржуаз эмигрант» Гаяз Исхакыйның да фикердәшенә әйләнгәч, урындагы түрәләрнең, большевик хөкемдарларның, бигрәк тә ОГПУның аңа булган тискәре мөнәсәбәте тагын да начарлана төшә. Ул әкренләп «чистарту кампаниясе» агымына тирәнгәрәк керә бара. Гомуми вәзгыять тә аның файдасына үзгәрми. 1928 елда М. Солтангалиев яңадан кулга алына. 1930 елда Казанда «инкыйлабка каршы» булган «Җидегән» оешмасы фаш ителә[24]. 1935 елда Казан дәүләт педагогия институты профессоры Н. Эльвов һәм аның фикердәшләре кулга алына. Нәтиҗәдә, педагогия институты гомумән «контрреволюцион үзәк», дип игълан ителә. Кулга алынучылар

«милләтчеләр», шул исәптән Г. Шәрәф турында да тикшерүчеләргә кирәкле «мәгълүматлар» бирәләр. (Андый «мәгълүматлар»ның һәм «шаһитлык күрсәтмәләре»нең нинди кансыз ысуллар белән алынганлыгы бүген яхшы мәгълүм.) Н. Эльвов, мәсәлән, үзенең сорау алганда биргән күрсәтмәләрендә ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты мәдәният-пропаганда бүлеге мөдире И. Рәхмәтуллинның эшкә «милләтчеләр»не, муллаларны һәм, гомумән, Совет хакимиятенә каршы кешеләрне генә алуы турында «шаһитлык итә». (Нәтиҗәдә, И. Рәхмәтуллин эшеннән азат ителә, соңыннан партиядән дә чыгарыла.) Имеш, Г. Шәрәф тә И. Рәхмәтуллин ярдәмендә эшкә урнашкан, ә Галимҗан исә әле Ленинградта чакта ук «милләтче» буларак танылган һәм ул бүген дә үз мәсләгеннән ваз кичеп тәүбә итмәгән «бердәнбер милләтче» икән. Бу гаепләүгә Нәкый Исәнбәт тә үзеннән өлеш кертә — 1936 елның 19 сентябрендә ВКП(б) өлкә комитетының контроль комиссиясенә язган гаризасында Г. Шәрәф турында: «Ул Милли Мәҗлестә эшләде, Татар-Башкорт федерациясен төзеп, Башкортстанны колониягә әверелдерергә теләде. Ильяс Алкинны президент итмәкче иде»[25], — дип яза.

Шул ук вакытта «халык дошманнарын фаш итү» буенча үткәрелгән партия җыелышларында инде «дошманлыклары ачыкланган» Г. Касыймов, С. Атнагулов, Г. Нигъмәтиләр белән беррәттән Галимҗан Шәрәфнең дә исеме кабатлана тора. Партия әгъзасы булмаганлыктан, аны җыелышта «тәүбә» иттерә алмыйлар. Аның каравы, «чистарту»ны җитәкләүче «центристлар», һәртөрле анонимщиклар аңа докторлык дәрәҗәсен һәм профессор исемен бирдермәс өчен бөтен тырышлыкларын куялар. Бу хакта тәфсилле язар өчен әлегә безнең кулда җитәрлек документлар юк, әмма Г. Шәрәфнең профессор исеме бирелүне раслау буенча югары аттестация комиссиясенең карар кабул итүне озакка сузуына борчылып һәм бу мәсьәләгә ачыклык кертүне сорап төрле тәшкиләтләргә язган берничә хаты кайбер нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, институт җитәкчелегенә язган хатында Г. Шәрәф болай ди: «Академик яктан караганда, минем профессор исеменә лаек булуым шик астына алынмый, ләкин исемем тирәсендәге шикле күләгәләр мәсьәләне башка тиешле оешмалар белән киңәшүне таләп итәләр, имеш. Минем профессор исеменә тәкъдим ителүемнән соң педагогия институтының берничә директоры алмашынды, яңадан тәкъдим итүләр булды... Әмма эш мәсьәләне хәл итүгә килеп җиткәч, яңадан да очсыз-кырыйсыз «киңәшләшү кирәк»леге беленә. Шулай итеп, бу мәсьәлә биш ел буе инде һавада эленгән килеш кала бирә»[26].

Ихтимал, Г. Шәрәфнең тормыш юлына аркылы төшкән бу бәлаләрдә кайберәүләрнең аңардан көнләшү факторы булгандыр. Кайберәүләр аның доценттан югары күтәрелә алмавы белән канәгатьләнсәләр, икенчеләре сәләтле галимнең бөтенләй дә юкка чыгуын, башы төрмәләрдә черүен теләгәннәр булса кирәк. Чөнки бу очракта аның фәнни хезмәтләрен, ачышларын курыкмыйча үзләштерергә мөмкинлекләр туачак.

БОЛЫТЛАР КУЕРА

Инде әйткәнебезчә, Галимҗан Шәрәф олы галим була. Шул ук вакытта җәмгыяви тормышта актив катнашуы һәм тотынган һәр эшен уңышлы башкарып чыгуы белән күпләрне сокландыра. Бер карасаң, ул Татарстанның чикләрен билгеләү-аныклау өстендә эшли, икенче карасаң — җөмһүриятнең төгәл картасын төзи. Ул да түгел, «Труд и хозяйство» дигән журналда (ул тирән эчтәлеге, икътисади мәсьәләләрне тәфсилле яктыртуы белән Татарстанда чыга торган журналларның иң абруйлысы була) аның «Районлаштыру принциплары турында» дигән кызыклы хезмәте басылып чыга. Мәкаләдә күтәрелгән фикерләр, тәкъдимнәр бүген дә әле үзләренең әһәмиятләрен югалтмаганнар: җентекләп укысалар, бүгенге идарәчеләр дә аннан байтак файдалы киңәшләр табарлар һәм эшләрендә җибәрелә торган хаталарның күбесен вакытында күреп төзәтә алырлар иде, мөгаен.

Галим-педагогны булачак белгечләрнең — студентларның үз һөнәрләрен никадәр нәтиҗәле үзләштерү проблемалары да борчый. 1937 елның 20 февралендә ул институтта бу хакта доклад ясый һәм студентларның белемнәрен күтәрү мәсьәләсенә җентекләп туктала[27]. Ихтимал, докладта кыю фикерләр дә әйтелгәндер — берничә көннән аның тел белеме турындагы лекциясенә «кунаклар» да керә: факультетның партоешма җитәкчесе һәм декан урынбасары. Г. Шәрәф сөенеп тә куя: әллә чынлап та аның яңа укыту алымнары белән кызыксыналармы?! 15 ел дәверендә аның лекциясенә беренче мәртәбә шундый дәрәҗәле «визит» бит бу! Ләкин аның куанычы икенче көнне үк челпәрәмә килеп юкка чыга. Институт җитәкчелеге аңа бөтен бүлекләрдә һәм курсларда лекцияләр укуны тыя, чөнки декан урынбасары Г. Шәрәфне лекция укуда тыелган алымнар куллануда гаепләгән икән.

Галимҗан эшнең ялгыш алым куллану-кулланмауда түгел икәнлеген яхшы аңлый, бу — һичбер нигезсез һәм

ясалма бер сәбәп кенә. Чынлыкта, педагоглар коллективын чистарту, «педагогия институтында оялаган халык дошманнары»н фаш итү кампаниясе бара. Моннан бер атна элек кенә үткәрелгән партия җыелышында нәкъ шул мәсьәлә тикшерелгән була. Анда ВКП(б) өлкә комитетының бүлек мөдире Пинхасик чыгыш ясый һәм институт директоры Газыйм Касыймов белән аның булышчысы Сәлах Атнагуловны Совет хакимиятенә каршы «корткычлык эше» алып баруда гаепли. «Икейөзле милләтчеләр» исемлегенә Эльвов белән Фәритова да кертелә. Пинхасик докладыннан соң җыелышта «тәүбә итү»ләр китә! Унбишләп кеше чыгыш ясый һәм үз-үзләрен уяулык күрсәтмәүдә, «дошмани фикерләр» таратучыларны үз вакытында фаш итмәүдә тәнкыйтьләп гафу үтенәләр. Хәер, ул вакытта мондый «тәүбә итү» җыелышлары бер педагогия институтында гына оештырылмый. Менә ул җыелышның зәхмәтле җиле «укытуда тыелган алымнар кулланучы» педагогка килеп кагыла да инде, чөнки җыелыш карарына, партиясез булса да, аның исеме дә кертелә һәм «Г. Шәрәф укыту эшләре алып бару өчен ышанычлы кеше түгел» дип раслана. Менә шуны гамәли тәсдыйклау өчен партоешма җитәкчесе белән декан урынбасары аның лекциясенә керәләр дә инде: өстән бирелгән «күрсәтмә»не үтәргә кирәк була.

Шушы вакыйгалар, төрле идарә тәшкиләтләренә килгән яла ягулы имзасыз гайбәт хатларына кушылып, Г. Шәрәфнең сәяси хәлен бик нык катлауландыралар, аның язмышын куркыныч астына куялар. Без галим язмышына да кагылышлы шундый бер «анонимка»ны укучыларга тулысынча тәкъдим итәбез: ул хат шул чорның атмосферасын һәм гайбәтчеләрнең астыртын, пычрак явызлыкларын шактый төгәл тасвирлавы белән әһәмиятле.

«Партия өчен иң зарарлы кешеләрнең берсе — Галимҗан Нигъмәти. Ул бит кешеләрнең идеологияләре ничек үзгәрүен өйрәнә торган профессор. Димәк, ул кешеләрнең бияләй эчендәге бармакларының да кайсы якка таба хәрәкәт иткәнен белә. Ул Татарстанда берничә контрреволюцион милләтчеләрнең лакее булып яшәде, үзенең тәнкыйть әсәрләрендә аларны яклап килде. Либерал балластка әйләнгән һәм шул ук вакытта бик оста хәйләкәр кеше партия өчен куркыныч зарарлы элемент булып тора.

Татобкомның Нигъмәтинең йөрәк тамыры ничек тибүен әле булса да белеп җиткәне юк. КДПИның (Казан дәүләт педагогия институты турында сүз бара.— *Р. В.*) элекке партком секретаре (хәзер партколлегиядә) Гафарова дигән бер мәхлук — сәүдәгәр кызы, Биктаһиров, Касыймов, Ат-

нагулов һәм Хөрмәтуллиннарның лакее. Йөрәге, каны белән оста хәйләкәр либерал Биктаһировның рекомендациясе белән бер ай эчендә партком, райком аша партколлегиягә күтәрелде. КДПИда тел укытучысы Рамазанов Шиһап дигән бер мәхлук бар. Башкиров, Касыймов, Атнагулов, Галимҗан Шәрәфләрнең лакее. Нәселе кулак. Бу группа турында Татобкомның икенче секретаре Абдуллинга язылды. Ләкин ул либераллык күрсәтте, тикшерелмәде. КДПИда партком секретаре булып эшләгән (Бауман районы), хәзер Ленин комиссиясендә тәрҗемәче, мулла, Эльвовның, Касыймовның, К. Галинең, Рәхмәтуллинның, Г. Сәйфетдиновның лакее, оста, хәйләкәр малай. КДПИда 1930 елдан партком тирәсендә йөрүче Фәйзуллина — сәүдәгәр кызы. КДПИдагы бөтен пычракларны үстереп ятучы һәм Касыймовның лакее. Оста, хәйләкәр либерал, балластка әйләнгән мәхлук. Җәләлетдинов Латыйф — КДПИда тел укытучысы, мулла малае, каенатасы Самарада әле дә мулла. Аның белән элемтә тотуын белсә дә, Биктаһиров мактап-мактап партиядә калдырды.

Сәлах Атнагулов һәм Рамазанов белән Касыймовларның лакее Ворфаламеева да КДПИда эшли. Атасы 27 нче елларда алтын, көмеш белән сәүдә иткән. Биктаһиров мактап-мактап аны да партиядә калдырды. Касыймовның һәм Рождественскийның лакее.

Менә дошманнар ничек эшлиләр. Ихтимал, югарыда исемнәре күрсәтелгән «кадерле иптәшләр» Татобком өчен кадерлеләрдер, ә түбән катлау өчен аларның бәясе бер тиен тормый. Бу кешеләр Маркс, Ленин, Сталин тәгълиматларының түбән катлауга килеп җитүен томалап торалар. Мәсьәләнең куркыныч ягы менә шунда»[28].

Имзасыз бу хат 1937 елның 10 февралендә партия өлкә комитетының идеология буенча секретаре Мөхәммәтҗановка җибәрелгән. Галимҗан Шәрәфкә 1937 елның 1 мартында лекцияләр укуның тыелуын искә алсак, әлеге «анонимка»ның да бу эшкә өлеш керткәнлегенә шик калмый.

Менә шулай итеп, институтта, Татарстанда сәяси вакыйгалар катлаулана, куркыныч төс ала бара. Ирекле фикер йөртүчеләр, кыю һәм сәләтле галимнәр, җитәкчеләр, гади хезмәт ияләре, коммунистлар, партиясезләр, хәтта студентлар да «халык дошманы», «буржуаз милләтчеләр», «провокаторлар», «бандитлар» булып китәләр. Мәркәзнең урыннардагы Лепа, Хатаевич, Ходоровский кебек «курчаклары» бу сәяси уенны бик оста оештыралар. Мөмкинлек туганда чаткыны да керосин сибеп дөрләтеп җибәрәләр, мәркәзгә бертуктаусыз хатлар язып, ни эшләгәннәрен һәм нәрсәләр

эшләргә җыенуларын хәбәр итеп торалар. Әмма соңыннанрак мондый «курчак уены»н оештыручыларның үзләре дә репрессияләр машинасына эләгеп юкка чыгалар. Гаделсезлекнең тимер мантыйклы кануннары соңрак аларның да якасыннан эләктереп алалар.

С. М. Киров үтерелгәннән соң ВКП(б) Үзәк Комитетының 1935 елның 18 гыйнварындагы ябык хаты партия җыелышларында уку уңае белән «халык дошманнары»н «фаш итү» тагын да киңрәк колач ала, хәтта бу өлкәдә үзенә күрә «социалистик ярыш» та башланып китә. Мәсәлән, Татарстан Эчке эшләр халык комиссариаты җитәкчесе Михайлов, 2—3 мең кеше урынына 5—6 меңне «фаш итәргә» рөхсәт сорап, Ежовка мөрәҗәгать итә.

1936 елның 16—19 сентябрендә Казан шәһәрендә партия активы җыелышы үткәрелә. Анда «троцкийчы-зиновьевчы бандалар блогын фаш итү йомгаклары турында»гы мәсьәлә карала. Төп докладны өлкә комитетының беренче секретаре Лепа ясый. Ул үзенең докладында Казанда, югары уку йортларында, идарә тәшкиләтләрендә «корткычлар эшләп килгәне», аларның фаш ителүе хакында әйтә дә, кайбер «дошманнар»ның исемнәрен дә атый. Менә алар: Диковицкий, Корбут, авиация институтыннан Гроднинский, Гудзин, «Крестьян иттифагы»ннан[29] Баймбетов, Сәгыйдуллин, Садретдинов, Әминов, Ханзафаров, Кудояров, Борнаев һ. б. Докладчы педагогия институты буенча ВКП(б) өлкә комитетының 1935 елдагы 27 март карарын да искә төшерә һәм «банда»га кергән Эльвов, Ищенко, Винтайкин, Рәхмәтуллин, Атнагулов, Сәйфи, Гимранов һәм Красный фамилияләрен «нәфрәт белән» телгә ала.

Лепаның «фактларга бай» бу докладын Татарстан буенча 1936—1938 еллар өчен репрессияләр программасы дип карау да дөрес булачак.

Менә шушы «актив җыелышы»ннан соң җөмһүриятнең бөтен районнарында, югары уку йортларында, партия оешмаларында һәм идарә тәшкиләтләрендә «халык дошманнарын фаш итү» җыелышлары уздырыла. Аларда кемнәрдер үзләренең «дошман коткысына бирелү»ләренә үкенәләр һәм «саф йөрәктән тәүбә итәләр», кемнәрдер, уяулык күрсәтеп, әле күптән түгел генә бергә эшләгән иптәшләренең «дошманлык»ларын фаш итәләр. Педагогия институтындагы җыелышларда Л. Җәләй, Рамазанов, Назаров, Г. Шәрәф исемнәре еш телгә алына. Соңгысын хәтта комсомол җыелышларында да «фаш итәләр». Мәсәлән, 1937 елның гыйнварь аендагы комсомол җыелышында Сәлахов дигән студент Г. Шәрәфне Ленин өземтәләрен (цитата-

ларын) бозып күрсәтүдә гаепли. Бу «фаш итү» җыелышына Г. Касыймов кереп: «Шәрәфкә яла якмагыз, ул үз өлкәсендә иң мәшһүр белгеч, бернинди бозуларга да юл куя торган галим түгел», дигәч кенә тукталып кала. Шул ук көннәрдә институтта уздырылган партия җыелышында Л. Җәләй, С. Атнагулов, Хангильдин һәм Саадиларны партия әгъзасы итеп калдыру-калдырмау мәсьәләсе карала. Аларның төп гаепләре итеп Г. Шәрәф белән элемтәдә булулары күрсәтелә. Җыелышта чыгыш ясаган Кәримов дигән кеше, мәсәлән, Л. Җәләйне «халык дошманнарының башкомандующие» дип атый, С. Атнагуловны аның секретаре булуда, «милләтче Шәрәфнең хезмәтләрен таратуда һәм пропагандалауда» гаепли. Аны студентларның укыту программасына Г. Шәрәф әсәрләрен керткән өчен дә тәнкыйтьли...

Г. Шәрәф өстендә кара болытлар куерганнан-куера бара. Аның өчен иң авыры студентларга лекцияләр укудан мәхрүм ителү була. Шуның өстенә газета-журналларга язган, нәшриятка тапшырган мәкаләләренең һәм хезмәтләренең кульъязмалары кире кайтарыла, йә редакцияләрдә хәрәкәтсез ята. Хезмәттәшләренең, танышларының кулга алынулары аның күңелен шомландыра. 1936 елда абыйсы Шәһерне кулга алалар һәм ул, «халык дошманы» буларак, Уфа төрмәсендә атыла. Борһан Шәрәф тә төрмәдә була.

Менә шундый авыр көннәрдә Галимҗан, үзенә ябылган гаепләрнең нигезсезлеген исбатлау өчен, партиянең өлкә комитетына мөрәҗәгать итәргә карар кыла, анда үзен аңларлар дип өметләнә. Архивларда аның өлкә комитетына язган ике хаты сакланган. Беренче хаты 1936 елның 9 ноябрендә язылган һәм бүлек мөдире Пинхасикка адресланган. Беренчедән, Галимҗан редакцияләрнең, нәшриятның аның фәнни хезмәтләрен ни өчен басып чыгармауларын ачыкларга тели. Бигрәк тә аны фонетика мәсьәләләренә багышланган һәм әле профессор исеменә тәкъдим ителгән көннәрдә үк тәмамланган хезмәтенең язмышы борчый. Бу хезмәткә Казан галимнәреннән Аптекаев белән Пронин, Ленинград галиме Самойлович язма рәвештә югары бәя биргән булалар. Г. Шәрәфне институт директоры Г. Касыймовның аны чакырып алуы һәм әлеге фәнни хезмәтне чын авторның фамилиясен күрсәтмичә, коллектив исеменнән чыгарырга тәкъдим итүе аптыраште калдыра. «Бүтәнчә мөмкин түгел, бу тәкъдим өстән килә»,—ди директор. Галимҗан үзенең хатында нәкъ менә шуны — «өстәгеләр»нең китапны ни өчен авторын күрсәтмичә чыгарырга тәкъдим итүләрен аныклауны сорый. Хаттагы икенче дәгъва авторлык хокуклары мәсьәләсенә кагыла. Эш шунда була: институт деканы үзен

докторлык дәрәҗәсенә тәкъдим иткәндә басылып чыккан фәнни хезмәтләре исемлегенә Г. Шәрәфнең «Эшчеләргә һәм колхозчыларга бүгенге татар әдәби теленең аңлаешлылыгы мәсьәләсе» дигән хезмәтен дә керткән. Галимҗан башта бу гайре табигый хәлне институтның кадрлар бүлегендә ачыкларга тели, әмма анда «тавыш чыгармауны» артыграк күрәләр һәм әлеге фактны йомып калалар. Г. Шәрәф әнә шул мәсьәләнең дә очына чыгуны сорый.

Әлбәттә, бу очракта Г. Шәрәф, галим буларак, әлеге мәкалә язмышы белән генә кызыксынмый. Аны икенче нәрсә — фәнни тикшеренүләргә мондый карашның, автор хокуклары белән исәпләшмәүнең киләчәктә гыйльми эшләрнең сүлпәнләнүенә, сыйфат дәрәҗәләре түбәнәюгә китерү ихтималы борчый. «Һәр җитди нәзари тикшеренү эше коллектив хезмәт булып тора,— дип яза ул үзенең хатында.— Чөнки ул инде моңа кадәр төрле телләрдә язылган әдәбиятны, шул исәптән тикшерелә торган фәнгә якын торган бүтән фәннәр өлкәсендәге әдәбиятны да искә алу һәм тәнкыйди файдалану нәтиҗәсендә иҗат ителә. Бер фән өлкәсендә эшләүче галимнәр үзләренең басылган хезмәтләре аша бер-берләре белән даими бәйләнештә торалар, үзенә күрә бертуктаусыз бәхәс алып баралар. Шундый аралашу нәтиҗәсендә генә фәннең үсеше, алга барышы тәэмин ителә. Тикшеренү нәтиҗәләренең коллектив хезмәт булуы нәкъ менә шуңарда чагыла. Бер галим тикшергән һәм язган хезмәткә икенче берәүләрнең исемен кую беркайчан да коллектив хезмәт була алмый»[30].

Г. Шәрәф икенче хатын 1937 елның 9 мартында партия өлкә комитетының икенче секретаре Г. Мөхәммәтҗанов исеменә язган. Бу юлы ул укыту-тәрбия мәсьәләләрен күтәрә, бу өлкәдәге проблемалар турында фикер алышырга теләвен белдерә. Г. Шәрәф бу мәсьәлә буенча хатта үзенең 1937 елның 26 февралендә институтта ясаган докладының текстын да теркәгән. Хатка Мөхәммәтҗанов тарафыннан «Иптәш Пинхасик, мәсәләнең нидән торуы белән кызыксынырга кирәк. Автор нәрсә турында сүз алып бармакчы?» — дигән резолюция салынган.

Әмма өлкә комитеты түрәләренең берсе дә хатларга җавап бирергә дә, аларның авторын чакырып сөйләшергә-аңлашырга да җыенмый, чөнки һәркайсы белә — галимнең иректәге көннәре генә түгел, сәгатьләре дә санаулы калган инде...

Г. Мөхәммәтҗанов Галимҗан Шәрәфнең хатына резолюциясен 23 март көнне салган булса, шул ук төндә галим кулга алына.

«БИРЕЛЕРГӘ ТЕЛӘМИМ»

Галимҗан үзенең язу өстәле артында эш кәгазьләрен, газета-журналларны караштырып утыра иде. Ул инде берничә айдан бирле педагогия институтында лекцияләр укымаса да, боларның барысын да иске гадәт буенча, вакыйгалар агышыннан хәбәрдар булып тору өчен эшли. Бу вакыт эчендә ул бик күп нәрсәләр турында кат-кат уйланды, күз алдыннан үткәрде.

Ул көпшәсыман итеп төрелгән кечкенә генә төргәкне — телеграф тасмасын кулына алды. Бу — Мулланур Вахитов һәм Иосиф Сталин белән сөйләшүләрнең язмасы иде. Галимҗан Сталин белән очрашуларны искә төшерде. Ул Татар-Башкорт һәм Татар Автономияле республикаларының проектлары әзерләнгән чакта Милләтләр эше буенча Халык комиссары советының урындагы вәкилләр фикере белән генә түгел, югарыдагыларныкы белән дә бик исәпләшмәячәген белде. Комиссар сугу өчен җайлы мизгелне көтеп торучы оста боксчыны хәтерләтә иде. Ләкин төп куркыныч аның китереп сугуга гаҗәеп оста булуында түгел, ә аның чигенә, юл куя белүендә дә иде. Мөселман комиссариатында эшләүче М. Вахитов, Г. Ибраһимов, Ш. Маннапов, Ю. Ибраһимов, И. Әсәкәев, М. М. Килдебәков, М. Алиев әлеге комиссариатны Татар-Башкорт комиссариаты итеп үзгәртү мәсьәләсендә Сталин белән килешмичә, отставкага китмәкче булдылар. Шунда Сталин аларга түбәндәге хат белән мөрәҗәгать итте: «Отставканы кабул итәргә һич тә риза түгелмен. Комиссариат әгъзаларының барысының да үз урыннарында калуларын һәм үзара аңлашылмаучанлыкны җайга салуны үтенеп сорыйм...» Отставкага китәргә җыенучылар тиздән үз гаризаларын кире алдылар. Алдандылар, аларның барысын да бер үк язмыш — үлем көтә иде. Беренче сугудан соң икенчесе дә көттермәде — «Идел-Урал» да юк ителде, Татар-Башкорт республикасына карата да шундый ук сәясәт үткәрелде: бүлгәләнгән социалистик республикалар — ТАССР, БАССР, ЧАССР һ. б. пәйда булды. В. И. Ленин әйтмешли, ашыгыч рәвештә СССР да төзелде.

Сталин үз дигәненә иреште — урындагы «милләтчеләр»нең барлык проектларын юкка чыгарды, аларның сафына таркаулык кертте. Ә бит «Идел-Урал штаты» составына Идел буенда яшәүче күп кенә халыклар үз теләкләре белән кермәкчеләр иде. Чуваш халкының вәкилләре соңыннан Ленин белән очрашкан вакытта да үзләрен татарлар белән бергә яшәргә теләүләрен белдерделәр. Ләкин

аларны бу уйдан кире кайтырга үгетләделәр һәм уңышка да ирештеләр. Галимҗан Шәрәфкә булачак республикаларның, шул исәптән хәзерге Татарстанның да чикләрен билгеләү эше йөкләнде. Сталинның бу йомышыннан баш тарта ала идеме ул? Әйе, ала иде. Ләкин бу мөһим эш белән намуссыз кеше шөгыльләнүен теләмәде, шунлыктан М. Солтангалиев, А. Енбаев, Егоров һ. б.лардан торучы Тармакара административ комиссия составына керергә ризалык бирде.

Барысын да төптән уйлап эшләргә күнеккән Шәрәф Сталинның гына түгел, гомумән хөкүмәтнең дә милләтләр мәсьәләсендәге эшчәнлегенең патша хөкүмәте белән Вакытлы хөкүмәтне бәреп төшерергә өндәгән чакта бирелгән вәгъдәләргә туры килмәвен сизә иде. Үзбилгеләнү, тигез хокуклылык һәм гаделлек өчен көрәштеләр бит, ә нәрсә килеп чыкты? Шәрәфнең бу сизенүләре яңа фактлар, Сталин аппараты эшчәнлегенең яңа яклары белән торган саен ныграк исбатлана барды, Сталин Столыпин белән Ильминский булдыра алмаган нәрсәне эшләде — милли мәсьәләне акылга сыймастай мәгънәсезлеккә әверелдерде. Гарәп шрифтын юкка чыгару үзе генә дә ни тора! Ә безнең «Идел-Урал штаты»н төзү планыбызны «Советка каршы җинаятьчел план» дип саныйлар... Ул төргәкне шкаф артына тондырды һәм кулына журнал алды.

— Нәрсә сөйләнеп утырасың, әйдә, Галимҗан, кичке аш әзер,— дип хатыны Әсма ирен табын янына чакырды.

— Хәзер, хәзер, Әсма.— Ул, журналны куеп, юынгыч янына юнәлде. Шулчак кыңгырау шалтырады, бер үк вакытта ишекне дә дөбердәтә башладылар.

«Алар»,— дип уйлап алды Галимҗан һәм ишекне ачты. Тышта дүрт кеше басып тора иде.

— Галимҗан Шәрәфетдинович Шәрәф биредә яшиме? — дип сорады НКВД кешесе.

— Биредә, биредә,— диде ул акрын гына, тирән йокыга талган балаларын уятмаска теләп.

— Минем фамилиям Царевский, ә болар Орадовский белән Чурмантаев иптәшләр. Монысы йортлар идарәсеннән Рахлина.

Барысы да тиз генә Галимҗанның эш бүлмәсенә үттеләр. Сержант Царевский тентүгә керешә. Бүлмә хуҗасы бер сүз дәшмичә китапларның, кульязмаларның, хатларның, фотосурәтләрнең бер-бер артлы идәнгә очуларын карап тора иде.

Ул үзенең 1918 елда Көнчыгыш фронтының 5 нче армия махсус бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан беренче тапкыр

кулга алынуын исенә төшерде. Ул чакта аның туганы Шәһер Шәрәф белән Буа районының Аксу авылыннан Казанга барышы иде. Озакламый университетта укулар башланырга тиеш. Ул чакта аларны төрмәдән берничә тәүлектән соң чыгарып җибәрделәр. Ә хәзер? Гаҗәп: үзенең юлдашлары белән Царевскийның килеп керүе аны хәтта беркадәр тынычландырды да. Бәлки хәзер ачыкларлар, аңларлар...

Царевскийга Орадовский белән Чурмантаев булышалар, Рахлина бер читтәрәк басып тора. Ул профессорга теләктәшлек хисе белән карый һәм нәрсә эшләргә дә белми иде.

Тентү төне буе дәвам итте. Өч бүлмәнең дә астын-өскә китерделәр. Алынырга тиешле китапларның исемлеген төзеделәр. Бу исемлеккә Бакунин, Каутский, Михаил Корбут, Мальтус, Мәрҗани әсәрләре, «Бич народа» журналы һ. б. керде. Царевский ул чакта һәркемгә мәгълүм шәхес, мәрхүм мөфти Фәхретдиновның — кулга алынучының каенатасының фотосурәтләрен дә үзе белән алды[31]. Бераз уйлап торгач, ул әлеге кәгазьләр һәм китаплар янына Шәрәфкә Англиядән җибәрелгән хатларны, аның 1934 елның 6 январенда ВКП(б) Үзәк Комитеты Секретариатына язган гаризасын, «Идел-Урал штатлары»н тормышка ашыру коллегиясе тарафыннан 1918 елның 28 нче февралендә бирелгән 73 нче номерлы таныклыгын, Шәрәфнең 1937 елның 9 нчы мартында ВКП(б) өлкә комитетына язган гаризасын, ТАССР районнарын эреләндерү турында брошюраны, Оренбург Мөселманнар советының 1917 елның 7 декабрендә язган хатын да теркәде. (Алгарак китеп булса да әйтик: әлеге тентүдән соң документларның шактый өлеше эзсез югала, алар исемлектә дә, архивларда да, тикшерү эшләрендә дә табылмый.)

Махсус бүлек хезмәткәре, эшне төгәлләп, аңа тентүнең беркетмәсен сузды:

— Менә монда кул куегыз!

Китап шкафына мөһер сuктылар, аннары Царевский аны ачарга ярамаганлыгы турында Әсманы кисәтте.

Махсус бүлек хезмәткәре беркетмәне күн сумкасына пөхтәләп кенә салып куйды да, тәрәзәгә таба карап, Шәрәфкә:

— Тиз генә җыеныгыз! — диде.

Галимҗан ирексездән күз кырые белән генә тротуарга күз төшереп алды, тик анда инде күнегелгән шымчы да, «черный ворон» дип йөртелүче машина да күренми иде. Хатыны елый башлады.

— Әсма! — диде ул аңа, бугазына килеп тыгылган

төерне йотып җибәрергә тырышып.— Балаларны сакла, үзеңне сакла! Мин тиздән кайтырмын, гаебем юклыгын беләсең бит. Җибәрерләр...

Хатыны аңа таба атлады, ләкин Чурмантаев белән Орадовский аңа аркылы төштеләр, ә Царевский:

— Киттек, гражданин Шәрәф! — дип боерды.

Эчке киемнәр белән урын-җир әйберләре алырга да ирек бирмәделәр хәтта. «Ярар, иртәгә китерерләр әле»,— дип уйлады Шәрәф. Бу «иртәгә»нең берничә елга сузыласын белми иде ул...

Галимҗан Жуковский урамында яши, ә төрмә исә янәшәдә генә — Дзержинский урамында иде. «Бердәнбер юанычь»,— дип көлемсерәде Галимҗан. Ул төрмәгә җәяү генә килде.

Бу хәл 1937 елның 23 мартында булды. Яз житсә дә, Галимҗан өчен шомлы, салкын көннәр башланды. Әсманың өйдә ике кечкенә бала белән калуы җанны әрнетә иде. Алар нишләп ята икән? Тәшвишләнү хисе күңелгә таш булып ятты...

25 мартта НКВД хезмәткәре Дунаев аннан берничә тапкыр сорау алды.

— Хатыныгыз белән балаларыгыздан кала барлык якын туганнарыгызны санап чыгыгыз.

— Абыем Борһан Шәрәф Казанда яши,— дип җавап бирде Галимҗан.— Аңа илле яшь, ул проектлаштыру бюросында, Горький оешмасы вәкиллегендә статист булып эшли. Революциягә кадәр журналист иде. Аннан укытучы, тәрҗемәче булып эшләде. Утызынчы елда кулга алдылар һәм срогыннан алда азат иттеләр. Ни өчен кулга алуларын белмим. Гаиләләребез белән йөрешәбез.

Аннан Галимҗан Шиһап абыйсы турында сөйләде:

— Аңа илле тугыз яшь, кинотеатрда каравылчы булып эшли, революциягә кадәр әти белән бергәләп сәүдә итте, революциядән соң мулла булды, утызынчы елда кулга алынды һәм раскулачиваниегә эләкте. Гаиләләребез белән йөрешәбез... Кыз туганнарым бар — Фатыйма Монасыйпова. Абыем Гыйльми 48 яшьтә, Ленинград ягында кооперация системасында бухгалтер булып эшли. Элек Казанда Татбанкта директор урынбасары булып эшләде, 1928 елда валюта эшендә гаепләнеп кулга алынды, Орел шәһәренә сөрелде. 1936 елның җәендә, отпуск вакытында, минем янга Казанга килеп, ике атна яшәп китте. Кызы Ленинград университетында укый. Кыз туганым Хадичә Сәгыйтова — стенографистка, моннан ике ел элек Ленинградка күчеп китте. Аның ире Кәрим Сәгыйтов анда Фәннәр академиясендә

тәрҗемәче булып эшләде. 1936 елда аны кулга алдылар һәм Ерак Көнчыгышка сөрделәр, ул хәзер дә шунда. Алтмыш яшьлек абыем Шәһер Шәрәф Уфада, 1936 елда казый Зыя Камали, Кашшаф Тәрҗеманов һ. б.лар белән бергә кулга алынды. (Галимҗан Шәрәф ялгыша. Аның бертуган абыйсы Гыйльметдин беренче тапкыр 1927 елның 9 июлендә кулга алына.— *Р. В.*)

Дунаев җавапларны җентекләп язды да икенче сорауны бирде:

— Кемнәр белән аралашасыз?

Галимҗан республика Госпланында эшләүче Гомәр Бикбулатовны, Госбанкта эшләүче Хәмит Сәйфуллинны, Ш. Рамазановны, С. Атнагуловны, М. Фазлуллинны, Х. Бадыйговны, Гали Рәхимне, Мөхетдин Корбангалиевне, Нигъмәт Хәкимне, В. А. Богородскийны, Л. В. Щербаны, Һади Атласовны атады. Соңгысын ул тарихчы буларак белә, аның белән беренче тапкыр 1917 елда Уфада Милли Мәҗлестә очрашкан иде. Аннан соң берничә тапкыр аның Казандагы фатирында очраштылар. Галимҗан шулай ук Мирсәет Солтангалиевне, А. Енбаевны һәм башкаларны да атады. Ул партия өлкә комитетының, Министрлар Советының бөтен составларын диярлек санап чыга ала һәм өстәвенә Сталинның үзен дә атый ала иде. Ләкин ул инде кулга алынган яисә шик төшмәстәй кешеләрнең фамилияләрен атап чыгу белән генә чикләнде.

Шуның белән сорау алу тәмамланды. Тикшерүче Дунаев үзен бик әдәпле тотып, хәтта ихтирам итеп сөйләште. Бу тоткынга өмет бирде.

Чираттагы очрашу икенче көнне үк булды. Бу юлы Дунаевның тавышы кырыс, яңгырап чыга иде.

— Чит илләрдәге танышларыгыз турында сөйләгез!

Галимҗан дәшмәде.

— Нигә дәшмисез?

— Нәрсә әйтергә дә белмим,— диде тоткын.— Сез шаяртасыздыр?

— Һич шаяртмыйбыз, гражданин Шәрәф. Бездә сезнең элемтәләрегез турында төгәл мәгълүматлар бар, сез шулар хакында ихлас күңелдән сөйләп бирергә тиешсез!

— Алай барысын да белгәч, сорап торасы да юк инде,— диде Галимҗан.

— Вакытны сузмагыз, гражданин Шәрәф.— Тикшерүче сәгатенә күз төшерде һәм папирос кабызды. Күзләрен кыса төшеп, Шәрәфкә текәлде.

Галимҗан йөткерергә кереште. Ютәлне тыеп булмый иде.

— Йә, нәрсә көтәсез?

— Эксперименталь фонетика буенча халыкара ассоциацияне исәпкә алмаганда, чит илләр белән элемтәм юк. Аның үзәге элек Венада иде, хәзер исә Лондонда,— дип нык тавыш белән акрын гына сөйләп китте Галимҗан.— 1929 елда мине бу ассоциациягә гамәли әгъза итеп сайладылар, шул ук елны Венадан миңа бу хакта хәбәр иттеләр. Әлеге ассоциация Гамбургта бастырып чыгара торган журнал миңа килеп тора. Ассоциациянең рәисе — америкалы Скрепчур. Моннан тыш, 1930 елның декабрендә Финляндиянең Гельсингфорс шәһәрендәге бер галимнең фонетика турында хезмәтен алдым. Бу көтмәгәндә булды. Мин аны бөтенләй белмим.

Аннары ул үзенең хәзер инде чит илләрдә яшәүче иске танышларын — Гаяз Исхакыйны, Габделбари Батталны, Садри Максудины, Фуат Туктаровны санап чыкты.

Беразга тынлык урнашты. Дунаев Шәрәфнең күзләренә текәлде.

— Ә хәзер, Галимҗан Шәрәфетдинович, үзегезнең Солтангалиевнең контрреволюцион оешмасы эшендә катнашуыгыз турында сөйләп бирегез.

— Әйе, четерекле сорау бу,— диде Шәрәф тикшерүче белән килешкәндәй, елмаеп.— Минем Солтангалиев оешмасына бернинди катнашым юк. Ә соң андый оешма бармыни?

Дунаев дәшмәде. Сорау алу шуның белән тәмамланды. «Бүген ноктаны мин куйдым»,— дип уйлады Шәрәф.

2 апрельдә тикшерүче белән яңадан очраштылар. Галимҗан сорау алу вакытында хата җибәрергә, ялгыз сүз ычкындырырга, саксызлык күрсәтергә ярамавын аңлый иде. Чөнки мондый хәл кем өчендер фаҗига булып чыгарга мөмкин иде.

— Тикшерү күрсәткәнчә,— дип башлады Дунаев,— Сез пантюркистлар хәрәкәтендә катнашкансыз, аерым алганда аларның «Учак» дип аталган контрреволюцион оешмасына да кергәнсез. Сез моны раслыйсызмы?

Галимҗан дәшмәде. Бу сорау аны яшьлегенә, Октябрь революциясенә кадәрге елларга кайтарып куйгандай булды. Ул чакта Г. Шәрәф Петербург тимер юл инженерлары институты студенты иде. Бер үк вакытта университетның иң яхшы профессорлары укый торган лекцияләргә йөрергә дә өлгерде. Алар татар халкын патша хакимияте салган богаулардан азат итү турында хыялландылар, дәүләт төзелеше рәвешләре турында фикер алыштылар, бәхәсләштеләр. Менә шулчакта ул «Татар учагы» дип исемләнгән студент-

лар оешмасын төзеде. Аңа Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар, Гани һәм Габдулла Абызовлар, Кәрим Сәгыйтов, С. Якубова, Салих Рахманкулов, Солтанбек Мамлеев, Давыт Еникеев һ. б.лар керде.

— Әйе, әйе, мин үземнең «Татар учагы» дип аталучы милли оешмада торганлыгымны раслыйм. Ләкин бу революциягә кадәр үк төзелгән студентлар оешмасы иде, аңа татар студентлары керде һәм аның пантюркизм белән бернинди уртаклыгы булмады.

— Менә ничек,— диде Дунаев алдында ятучы кәгазьләрне гасабиланып актара-актара.— Алайса, бу оешманың төп сәяси принципларын аңлатыгыз.

— Принциплар... Бу оешма, алда инде күрсәтеп үткәнемчә, милли төсмергә ия, аның төп сәяси принцибы татар милләтенең мәнфәгатьләрен яклау булды. Безнең оешманың үз уставы бар иде һәм ул нәкъ менә панисламизм белән пантюркизмга каршы көрәште.

Галимҗан анда катнашучыларның башлыча мәдәният һәм мәгариф мәсьәләләре белән генә кызыксынуларын сөйләде. Алар татар әдәбиятының хәле һәм аның үсеше турында сөйләшкәннәр, Мөселман хәйрия җәмгыятендә спектакльләр куйганнар. Тагын нәрсә? Гаяз Исхакый тәкъдиме белән татарча әсәрләрне урысчага тәрҗемә иткәннәр. «1917 елда без үзебезнең оешма исеменнән татар корылтаен мөселманнныкыннан аерым үткәрү турындагы мәсьәлә белән Дәүләт Думасына мөрәҗәгать иттек.»

— Әйе, оныта язганмын,— дип өстәде Галимҗан,— без мәчетләрдә намазны татарча укуны таләп иттек, моның өчен безне тәнкыйтьләп тә чыктылар.

— Сез,— дип бүлдерде тикшерүче,— Октябрь революциясе башланганда «Учак» оешмасы үз эшчәнлеген туктатты дип сөйләп, ялганлыйсыз. Мондый раслау дөреслеккә туры килми.

— Беренчедән, безнең оешма «Татар учагы» дип атала иде; мин бары тик төгәллек кенә кертәм. Икенчедән, минем кайбер нәрсәләрне оныткан булуым да мөмкин — никадәр гомер үтте бит,— диде Галимҗан.— Әгәр дә Сез сорауларны ачыграк итеп куйсагыз, мин Сезне канәгатьләндерергә тырышырмын.

Дунаев төпчеген изеп сүндерде, торып басты да тәрәзә янына килде. Шәрәфнең үзен тыныч, ышанычлы тотуы аңарда ихтирам уята иде. Ләкин вазифаны үтәргә кирәк.

— Карышуны туктатыгыз! — Дунаев Галимҗанга йөзе белән борылды.— Ниһаять, дөресен генә сөйләгез! Сез бит 1923 елда «Татар учагы»ндагы хәлләрне тасвирлап, Ильяс

Алкин белән Гани Абызовка хатлар язгансыз, алай гына да түгел, үз фикердәшегез буларак, Абызовны Татарстанга эшкә чакыргансыз.

Бер генә мизгелгә Галимҗанның хәле китте, башы әйләнә, укшыта башлады. Тамагы кипте, аяклары сызлый башлады. Галимҗанга «Татар учагы»ның инде революциягә кадәр үк яшәүдән туктавын, ә хатларны оешма әгъзалары белән түгел, ә якын танышлары белән алмашуын Дунаевка озаклап аңлатырга туры килде.

Күрше бүлмәдә каты итеп кычкырган тавышлар ишетелде — кемнедер кыйныйлар иде. Дунаев кисәк торып басты да ишекне ачып коридорга күз салды. Аннан ишекне ныгытып япты. Тавышларны ишеттермәскә теләдеме, әллә кемнеңдер тыңлап торуыннан шикләндеме? Ул тоткын янына килде дә, тавышын әкренәйтеп:

— Сез күпкә түзә алмассыз, профессор,— диде.

— Кем белә бит? — дип җавап бирде Шәрәф.— Без барыбыз да бер үк юлдан барабыз, барыбыз да җир астына кереп ятачакбыз. Мин физик яктан көчле түгелмен, шулай да үземне ихтыяр көче шактый зур булган кеше итеп сизәм.

— Без сезнең ихтыяр көчегезне сындырачакбыз,— дип бүлдерде аны Дунаев,— һәм сез кирәклесен генә сөйләячәксез.

Бу сүзләрдән соң ул кыңгырау төймәсенә басты һәм бер үк вакытта Галимҗанга беркетмәне сузды.

— Кул куегыз!

Галимҗан беркетмәне укый һәм кул куя барды, кайчакта бер битнең берничә җирендә имза куярга туры килде. Барысы да дөрес язылган иде. Бәлки моны кайчан да булса башка кешеләр укырлар, аңларлар...

Кулга алынганнан соң бер ай вакыт үтте. Гаиләдән, дуслардан берәр хәбәр булсачы... Тышкы дөнья белән бернинди элемтә юк, тулы аерылганлык... Камера тынлыгында Галимҗан нәтиҗәләр ясый.

Ул бер тапкыр да үзен гаепле дип танымады һәм кемнең дә булса язмышын хәрап итәрлек документларга кул куймады. Дунаев күрсәткән материаллар аңа тап төшерә алмыйлар, ә башкалары әле юк булса кирәк. Ләкин аны белүче башка тоткыннарның, ниһаять, абыйлары Борһан белән Шиһапның да, җәзалауларга түзә алмыйча аңа каршы сөйләүләре мөмкин иде.

Юкка гына шикләнми иде Галимҗан. Мәскәүдә күренекле татар язучысы, «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнарының авторы Мәхмүт Галәүдән, Азәрбайҗанда исә профессор Вәкир Чобанзадәдән, Газиз Гобәйдуллиннан

сорау алулар бара иде. Алар инде Галимҗан Шәрәфне яхшы беләләр...

Дунаев белән чираттагы очрашу 4 апрельдә булды. Бу юлы сүз аның сәяси карашлары турында барды. Шәрәф болай диде: «Мин Компартия белән Совет хакимиятенең программасын тулаем һәм тулысынча уртаклашам. Көндәлек эшемдә, фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлегемдә марксистик, большевистик линия үткәрдем».

Шулай да Галимҗан Совет хакимиятенең беренче көннәреннән үк аның тарафдары булып китмәвен таныды: «Мин шактый вакыт (1926—1927 елларга кадәр) теге яки бу дәрәҗәдә буржуаз милләтче идем, буржуаз милли хәрәкәттә актив катнаштым. Февраль һәм Октябрь революцияләре вакытында буржуаз милли мәнфәгатьләрне яклауны үзенең бурычы итеп куйган мөселман Милли Мәҗлеснең әгъзасы идем. Милли Мәҗлес тарафыннан сайланган коллегия әгъзасы буларак «Идел-Урал штатлары»н, ягъни буржуаз-демократик стройлы милли дәүләт төзү буенча эш алып бардым... 1926 елда мин яңалифне кертүгә каршы актив көрәш алып бардым».

Барысы да ул әйткәнчә иде. Ул коммунист-администратор түгел, ә партиясез зыялыларның җитәкчеләреннән берсе булды.

Галимҗан Шәрәф «эш»е буенча шулай ук Гали Кудояров, Мингәрәй Сәгыйдуллин, Гали Ганиев, Фатих Абдуллин, Ибраһим Мозаффаров, Габдулла Ибраһимов, Ибраһим Кулиев, Зәки Мөһсинов, Сәлах Атнагулов, Нәсыйх Мохтаров, Рәүф Әлмиев, Ибраһим Әмирханов, Габдулла Ибраһимов һәм башкалардан, хатыны Әсмадан да сорау алдылар.

1937 елның 23 июнендә Гали Рәхимне (Гали Шакир улы Габдерәхимовны) кулга алдылар. Ул 1930 елда Казанда басылып чыккан «Авылны өйрәнү» китабын төзүче иде. Аны чит ил разведкасы шымчысы булуда һәм пантюркистик юнәлештәге контрреволюцион оешма кушуы буенча Татарстанда баш күтәрүне әзерләүче җитәкчеләрнең берсе булуда гаеплиләр.

Бер айдан соң Садри Вәлидовны (Садри Җәләлне) кулга алдылар. Кулга алуның сәбәбе — пантюркистик юнәлештәге оешмада әгъза булып тору, чит илләрдә яшәүче татарлар белән элемтәдә булу.

Алар икесе дә берьюлы берничә маддә нигезендә гаепләнәләр. Ниһаять, аларның «эш»ләрен Галимҗан Шәрәф «эш»е белән берләштерәләр. Яңа документка 3404 саны бирелә. Галимҗан Шәрәф, Гали Рәхим, Садри Җәләл эше

буенча ясалган нәтиҗәдә болай диелә: «ТАССР НКВДсы Совет хакимиятен бәреп төшерүне һәм мөстәкыйль буржуаз-демократик төрки-татар дәүләте «Идел-Урал штаты»н төзүне максат итеп куйган, Советка каршы милләтчелек оешмасын ачты һәм юк итте».

Галимҗан үзенең «эштәш»ләрен яхшы белә, тик хөкемгә кадәр алар белән очрашудан мәхрүм иде. Мәгълүматлар тикшерүче аша гына килеп җитә. Бичара Садри Җәләл тоткынлыкта сукырайган. Өзек-төтек мәгълүматлардан Галимҗан гомуми күренешне күз алдына китерде. Барысының да хәле җитди икәнлеге ачык иде. Аларга «халык дошманнары, шымчылар» дигән дәһшәтле мөһерләр тагылды. Зур түземлелек белән хөкем булганын көтү һәм анда барлык башбаштаклыклар, кичергән газаплар турында кычкырып әйтү өмете генә калды.

1937 елның язгы-җәйге айларындагы сорау алулар ничектер имтихан алуга охшаганнар иде. Мәсәлән, аңа Марр теориясен җентекләп аңлатырга туры килде. Академикның үлеменә карата язылган некролог материаллары да ярап куйды; әлбәттә, истә калганнарны гына сөйләп чыга алды. Сорау алуның әлеге беркетмәсе зур белемле галимнең фәнни хезмәте кебек укыла.

Аннан соң «Татарларның мәгърифәтлелеге тарихы» китабын редакцияләгән өчен җавап тотарга, Газиз Гобәйдуллин белән очрашулар, егерменче елларда «суллар»га һәм «уңнар»га мөнәсәбәте турында сөйләргә туры килде. Бу соңгылары белән аңа Татарстан Үзәк Башкарма Комитетының татар телен тормышка ашыру, милли статистика һәм педагогика хезмәте буенча комиссиясендә эшләгән чакта эш итәргә туры килгән иде.

Тикшерүчене алыштырдылар — хәзер Галимҗаннан яшь канцелярия күсесе, НКВД лейтенанты Әхмәтов сорау ала иде. Беренче очрашудан ук ул куркыныч якынлашуын сизеп алды. Әхмәтов Галимҗанны ял итәргә дә вакыт бирмичә, көнозын сорау алды. Шул ук вакытта сорау алуның тизлеге дә, аның басым ясавы да көннән-көн арта бара иде.

— Сез корткычлык эшенә кайчан керештегез?

Галимҗан моңа әзер түгел иде, чөнки аның корткычлык белән шөгыльләнгәне булмады. Ә нәрсә бар иде соң? Башка илләрдәге галимнәр белән хат алышып тору бар иде, халыкара фәнни ассоциациядә әгъза булып тору бар иде. Мөстәкыйль җөмһүрият төзү омтылышы бар иде.

— Мин хакыйкать белән ялганны аерып бирү өчен суд каршына басарга әзермен,— диде Галимҗан.

— Бик әйбәт,— диде тикшерүче.— Ә хәзер моңа күз салыгыз.

Әхмәтов аңа папка сузды. Бу алдан ук әзерләнгән сорау алу беркетмәсе булып, Г. Шәрәф аңа кул куярга тиеш иде.

«*Сорау:* Сез Газиз Гобәйдуллин өйрәтүе буенча кайчан контрреволюцион эшчәнлек белән шөгыльләнә башладыгыз?

Җавап: Мин Газиз Гобәйдуллиннан Казанга кайткач, укучы яшьләр һәм укытучылар арасында пантюркистик идеяләрне тарату, пантюркистик юнәлештә эшләрлек кадрларны булдыру юнәлешендә эшләргә күрсәтмә алдым.

Сорау: Сез Гобәйдуллинның күрсәтмәсен ничек тормышка ашырдыгыз?

Җавап: Мин педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнә идем. Студентлар һәм авыл укытучылары арасында үземнең лекцияләремдә бик сак кына пантюркизм идеяләрен тараттым. Моның өчен читтән торып уку курсларын да файдаландым. Казандагы контрреволюцион һәм пантюркистик эшчәнлегем буенча мин КДМИ доценты Хаҗи Бадыйгов, КДУ профессоры Мөхетдин Корбангалиев, пединститут доценты Нигъмәт Хәким, пединститут профессоры Мөхәммәтхан Фазлуллин, Татарстан комвузында эшләүче Ш. Абдулла, Академик үзәк доценты Гаяз Максудов, пединститут доценты Гали Рәхим (Гали Габдерәхим) белән бәйләнештә идем. Әңгәмәләр вакытында бу кешеләр пантюркизм идеяләрен тулысынча уртаклашалар иде...»

«Бу нинди сафсата?» — дип уйлап алды Галимҗан.

— Мондый әшәке язманы кем әвәләде соң, хөрмәтле начальник? — дип сорады ул Әхмәтовтан.

— Анысы мөһим түгел, Галимҗан Шәрәфетдинович, тик ул тиешенчә язылган һәм сез моны үзегезнең имзагыз белән расларсыз.

— Юк һәм тагын бер тапкыр юк,— диде Галимҗан нык итеп.— Әйе, мин аларны белә идем, аралаштым да, тик алар турында берниндн дә начар сүз әйтә, бигрәк тә биредә язылган нәрсәләрне дөресләп кулымны куя алмыйм.

Галимҗан сүзләрен дә әйтеп бетерә алмады, йөзенә китереп сугудан күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китте. Бераз гына исенә килгән иде — чигәсенә китереп суктылар һәм Галимҗан аңын җуйды.

Хәзер Әхмәтов сорау алырга керешкән саен Шәрәф җәһәннәм газаплары кичерә иде.

— Үзеңә, үзеңнең хакыйкатеңә генә ышансаң — бернәрсә дә барып чыкмас,— дип аңлата иде Әхмәтов, аны кыйныйкыйный.— Безгә ышансаң, үзеңнең фонетикаң турында яңадан лекцияләр укырсың...

Берсендә, аеруча зәһәрләнеп кыйналгач, Галимҗан канга

баткан иреннәрен көчкә кыймылдатып: «Мин риза»,—дип пышылдады.

Әхмәтов тиз генә Галимҗанның кулына ручка тоттырды һәм ул берничә урында «Шәрәф» дип тырнаштырып куйды.

Икенче көнне аны яңадан сорау алуга чакырттылар. Тикшерүчене тагын алыштырганнар—хәзер Якубов сорау ала иде.

— Сез Нигъмәт Хәкимне беләсезме?

— Ничек белмәскә, бергә эшләдек, яхшы белгеч, Көнчыгыш тарихын яхшы белә. Петербургта укыган. Һиндстанда практика үткән.

— Без монда уннан артык кешедән сорау алдык һәм аларның барысы да диярлек Нигъмәт Хәкимнең Советка каршы эшчәнлек белән шөгыльләнүен раслады... Минемчә, сезнең дә карышып торырлык сәбәбегез юк. Укып чыгыгыз да кул куегыз.—Якубов аңа кәгазьләр сузды.

Галимҗан текстны укып чыкты—бу да шул ук әзер беркетмә иде. Нәрсә таләп ителсә, шуны язганнар.

— Мин ул ялганга кул куймаячакмын,—диде Галимҗан.—Мин Нигъмәт Хәкимне намуслы кеше буларак беләм, ә монда «ул фашист, Советка каршы эшләүче, Сталинны сүкте» дип язылган... Болар барысы да ялган. Нигъмәт андый кеше түгел ул.

Якубов сикереп торды, беркетмәне ертып ыргытты да, җикеренә башлады:

— Тагын илле тапкыр чакыртачакмын, подвалга ябып куячакмын. Барыбер кул куярга мәҗбүр булырсың.

Сорау алулар, кыйнаулар көн саен кабатланса да, Галимҗан бирешмәде. Ул үзенең Якубов белән бәрелештә җиңеп чыгуын аңлый иде. Хәзер ул үз өстенә булмаган гаепне алырга мәҗбүр иткән Әхмәтов белән көрәшеп карарга ниятләде. 1937 елның 28 декабрендә Шәрәф прокурор исеменә гариза язды: «Миннән сорау алулар нәтиҗәсендә язылган ике беркетмәне гамәлдән чыгару турында күрсәтмә бирүегезне сорыйм. Чөнки әлеге беркетмәләрнең миңа кагылган өлеше бөтенләй... (шуннан соңгы сүзләрне танып булмый.—*Р. В.*), ә башка кешеләргә кагылган өлеше миңа билгесез яки аз билгеле булган фактлар шактый үзенчәлекле итеп аңлатыла. Мин әлеге беркетмәгә өч тәүлек буена өзлексез дәвам иткән сорау алулардан соң, 60 сәгатьтән артык басып торганнан соң, тикшерүче Әхмәтовның берничә тапкыр каты итеп йодрык белән сугуыннан һәм шул ук хәрәкәтләрне дәвам итәчәге белән янавыннан соң кул куйдым. Башка кешеләргә кагылган өлешенә шул ук тикшерүче йогынтысы нәтиҗәсендә кул куйдым...»[32].

Бу хәл яңа 1938 ел алдыннан була. Ике көн дәвамында Шәрәфне борчымыйлар, ә 3 январьда исә хәлдән тайдыргыч очсыз-кырыйсыз сорау алулар башлана. Тагын Әхмәтов пәйда була. Бу юлы инде Галимҗанга Татарстанда милли дәүләт төзелешенең башлангыч чоры турында тулы бер лекция укырга туры килә. Әхмәтовның аның Уфада, Милли Мәҗлес утырышында докладны кем кушуы буенча ясавы турында соравына Галимҗан болай дип җавап бирә: «1917 елда Казанда булып үткән Икенче мөселман съездында (сүз мөселман хәрбиләренең Бөтенрусия корылтае турында бара.— *Р. В.*) Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының Милли Мәҗлесен чакыру буенча коллегия сайланды. Аның составына, миннән тыш, Максудов, Әхмәтов, Алкин, Корбангалиев, Мөхетдинова, Атласов һ. б.— барлыгы уникe кеше керде. Милли Мәҗлесне чакырудан тыш, коллегиягә экстерриториаль һәм территориаль автономияләр турында материаллар әзерләү дә йөкләнде. Мин «Идел-Урал штаты» дип исемләнгән территориаль автономияне тормышка ашыру буенча материаллар әзерләү белән җитәкчелек иттем, ә Максудов шул ук эшләрне экстерриториаль автономия буенча башкарды. Милли Шурага Фуат Туктаров җитәкчелек итте. Аның белән элемтәдә тордык».

Аннан соңгы сорау алуларда сүз Милли Мәҗлес турында бара. 8 гыйнварда ул болай дип сөйли: «Милли Мәҗлес буржуаз-демократик стройга нигезләнгән «Идел-Урал штаты»н төзү турындагы проектны кабул иткәч, ул Казанга җибәрелде. Бу вакытта анда икенче мөселман хәрбиләре съезды бара иде. Проект анда да кабул ителде, шул ук съездда хәрби коллегия сайланды, аның рәисе итеп полковник Биглов билгеләнде. Бу коллегиягә мөселман хәрби берлекләрен берләштерү бурычы йөкләнде. Безнең коллегиянең рәисе Ильяс Алкин бер үк вакытта Казандагы Хәрби Шура рәисе дә булып торганлыктан, «Идел-Урал штаты»н төзү буенча барлык практик әзерлекне миңа башкарырга туры килде. Төгәл генә әйтә алмыйм, шулай да бу 1918 елның гыйнварында булды. Ревком тарафыннан Казанда Хәрби Шура җитәкчелеге кулга алынды. Алкин, Госман Токымбетов, Йосыф Мозаффаров кулга алындылар... Кулга алуның сәбәбе шунда: ревком мөселман берлекләрен фронтка җибәрмәкче булды, ә Хәрби Шура моңа каршы төште, чөнки Икенче мөселман съезды карары нигезендә бу берлекләр төзелеп килүче «Идел-Урал штаты»нда калырга тиешләр иде. Кулга алынганнарны, алар Хәрби Шураны таратырга сүз биргәч, өч көннән соң азат иттеләр. Тик шушы мизгелдә хәрби коллегия җитәкчелегендәге хәрби берлекләр

Совет хакимиятенә каршы чыктылар. «Болак арты республикасы»ның программ юнәлеше — «Идел-Урал штаты»н төзү иде».

1938 елның 5 мартында Галимҗанны Газиз Гобәйдуллин белән Вәкир Чобанзадәнең Бакуда алынган язма мәгълүматлары белән таныштыралар. Алар халык дошманнары буларак кулга алыналар. Галимҗан әлеге мәгълүматларның дүрт тәүлек буена өзлексез дәвам иткән сорау алулар нәтиҗәсендә тартып алынганлыгын белми иде. Аларның беренчесе үзенең Гали Рәхим, Йосыф Акчурин, Садри Максудов һ. б.лар белән элемтәдә торуын таный. Арырак исә Галимҗан үз фамилиясен күрә: «Әңгәмәләр барышында Җамал Вәлитов, Гали Рәхим һәм Г. Шәрәф миңа үзләренең Гаяз Исхаковның күрсәтмәсе турында инде белүләрен һәм Татарстанда солтангалиевчеләр Мансуров, Енбаев һәм Бурундуков җитәкчелегендә баш күтәрүчеләрне әзерләү баргалыгы турында да хәбәрдар булуларын әйттеләр». Язма мәгълүматларда түбәндәге юллар да бар: «1918 елга кадәр баш күтәрүчеләрне әзерләү белән пантюркистик үзәккә буйсынучы түбәндәге кешеләр җитәкчелек иттеләр: Фитрат — Үзбәкстан һәм Таҗикстан, Худуфлу — Азәрбайҗан, Гаяз Максудов, Г. Шәрәф, Нигъмәт Хәким, Ибраһим Кулиев, Садри Җәләл, Җамал Вәлитов, Гали Рәхим — Татарстан, Габдулла Гыйсмәтуллин — Башкортстан».

Чобанзадә биргән «мәгълүматлар»да милләтчеләрнең бердәм фронтын булдыру, аның тактикасының татар моһаҗирләре күрсәтмәләреннән чыгып эшләнүе турында әйтелә: «Мин, Чобанзадә, бу хакта Кырым эмиграциясе җитәкчесе Җаффар Сәедалитовтан төгәл күрсәтмәләр алдым. Шундый ук күрсәтмәләр проф. Гобәйдуллинга моһаҗирлектәге татар кешеләре Садри Максудов, Йосыф Акчурин, Гаяз Исхаков, Зәки Вәлитов, Габдерәшит Ибраһимов, Фуат Туктаров тарафыннан бирелде. Аның 1925 елда Бакуга барулары татар моһаҗирләренең һәм Солтангалиев оешмасының күрсәтмәләре аркасында булды. Төрек профессоры Исмәгыйль Хикмәт тә шул ук юнәлештә эшләде. Бу хакта аңа Англия разведкасы белән тыгыз бәйләнештә булган, Төркиядәге «Иттихат вә тарих» партиясе күрсәтмәләр биргән иде...» Арырак Чобанзадә болай дип «таный»: «...аларның (моһаҗирләрнең.— *Р. В.*) Габдрахман Сәгъди, Абдулла Шөнаси, Нигъмәт Хәким, Алпаров, шулай ук Гали Рәхимов, Җамалетдин Вәлитов һәм Галимҗан Шәрәф белән элемтәдә торулары мәгълүм иде». Чобанзадә 1929 елда Сәмәркандка фәнни конференциягә бара һәм бу хакта түбәндәгеләрне әйтә: «Монда Йосыпов

һәм Фитрат белән очраштым һәм аларга Г. Гобәйдуллин белән бергәләп әзерләгән чаралар планын тапшырдым. Үзбәкстанда әлеге күрсәтмәләр турында инде белүләре ачыкланды, чөнки аларга татар милләтчеләре Гали Рәхим, Җамалетдин Вәлитов, Галимҗан Шәрәф, Нигъмәт Хәким һәм Габдрахман Сәгъди хәбәр итеп торалар иде...» Документның иң ахырында исә Галимҗан Шәрәф белән Гали Рәхимнең немец разведкасыннан акча алулары турындагы юллар күзгә ташлана...

Галимҗан үзенең Гобәйдуллин һәм Чобанзадә белән берничә тапкыр очрашуын таный, шул ук вакытта болай дип белдерә: «Г. Гобәйдуллин белән Чобанзадәнең миңа кагылышлы мәгълүматлары чеп-чи ялган».

1938 елның 4 сентябрендә Әхмәтов Галимҗан Шәрәфне шаһит Мингәрәй Сәгыйдуллин белән күзгә-күз очраштыра. Әхмәтов Сәгыйдуллинга мондый сорау бирә: «Сез Галимҗан Шәрәфне халык дошманы дип саныйсызмы?» Җавап: «Галимҗан Шәрәфне, үзем шикелле үк, халык дошманы дип саныйм».

Әхмәтов Г. Шәрәфтән:

— Сез Сәгыйдуллинның сүзләрен раслыйсызмы? — дип сорый.

— Кире кагам,— дип җаваплый Шәрәф.

Сәгыйдуллин Г. Шәрәфне егерменче еллар башында «уңнар»га кушылып, партиясез татар зыялыларын алар өчен таяныч итүдә һәм «Идел-Кама крае» рәвешендә «Кече Туран» төзергә маташуда гаепли.

Башкалардан сорау алу юньле нәтиҗә бирми, сүз башлыча тикшерүгә мәгълүм фактлар турында бара.

1939 елның февралендә Г. Шәрәфкә тикшерү эшенә теркәлгән, ике том тәшкил иткән гаять күп документлар күрсәтәләр. Алар «Идел-Урал штаты»н тормышка ашыру буенча коллегиянең «Болак арты республикасы» белән үзара мөнәсәбәтләре турындагы детальләр белән тулыландырыла.

«Безнең коллегия,— ди Г. Шәрәф,— озак фикер алышулардан һәм бәхәсләрдән соң күпчелек тавыш белән «Болак арты республикасы»нда катнашмаска һәм совет органнары белән кичекмәстән автономияле «Идел-Урал Совет республикасы»н төзү турында сөйләшүләр башларга карар бирде. Коллегия мөселман хәрби берлекләре белән Кызыл Армия арасында кан коюга китерәчәк коралды бәрелешләрне булдырмас өчен Казандагы совет органнары белән «Болак арты республикасы» арасында арадашчы хезмәтен үтәргә теләде. Нәтиҗәдә Казан губерна башкарма комитеты «Ка-

зан республикасы»н оештыру турында Мәскәү белән, Уфа губерна башкарма комитеты белән һәм кызыксынучы башка губерна башкарма комитетлары белән сөйләшүләр башлап җибәрергә булды».

«Идел-Урал штаты» шигарен ак моһаҗирлекнең файдалануы турында сүз кузгалгач, Г. Шәрәф болай ди: «Мин бу турыда кулга алынганнан соң сорау алулар барышында гына белдем. Бу мәсьәлә буенча мин беркайчан да, беркем белән дә — моһаҗир Гаяз Исхаков һәм башкалар белән дә, Союз эчендәге контрреволюцион милләтче элементлар белән дә бәйләнешкә кермәдем. Тикшерү эшендәге Гали Рәхимнең һәм башкаларның шәхсән миңа кагылышлы сүзләре дөреслеккә туры килмиләр... Мин үзем контрреволюцион оешмалар эшендә катнашмадым һәм бернинди дә контрреволюцион эш алып барганым юк...»

Пантюркизмда гаепләүгә каршы чыгып, ул үзенең бу көрәнеш белән (аеруча әдәбият һәм тел гыйлеме өлкәсендә), аңа тартымлылык белән гел көрәшеп килүен әйтә. Мәсәлән, педагогия институтында эшләгән чакта ул телнең һәм әдәбиятның килеп чыгышында Алтын Урда теориясен яклап чыгучы коллегалары Х. Бадыйговны, М. Фазлуллинны, Н. Хәкимне тәнкыйтьләп чыга. Г. Шәрәф үзенең хезмәтләре һәм лекцияләренең текстлары белән танышып, төпле нәтиҗә ясый алырдай белгечләрдән торучы комиссия билгеләүне таләп итә.

Сорау алулар һәм тикшерү эшләре куркыныч төс ала бара. Хәлләр аеруча июньдә, сорау алуны тикшерүчеләр Кальметов белән Галакин алып бара башлагач, түзәлмаслык була башлый. 1938 елның 19 июнендә Г. Шәрәфне алдан әзерләнгән, ТАССР Эчке эшләр халык комиссарына адресланган гаризага кул куярга мәҗбүр итәләр. Менә ул: «Озак вакыт тикшерү астында булган хәлдә, мин үзем алып барган контрреволюцион эшчәнлекне яшереп килдем һәм, берничә тапкыр күзгә-күз очраштыруларга карамастан, тикшерү эшләренә төрлечә аяк чалдым. Моннан ары каршылык күрсәтү файдасыз дип табам. Мин Совет хакимияте органнарына үземнең дә, үзебезнең дә, контрреволюцион оешманың да советларга каршы эшчәнлегебез турында, ул оешманың моһаҗирлектәге буржуазия һәм чит илләрнең разведка органнары белән бәйләнешләре турында җентекләп сөйләп бирергә булдым».

Бишенче көнне ул сораулар һәм җаваплар рәвешендә төзелгән яңа документка кул куярга мәҗбүр ителә. Ул түбәндәгедән гыйбарәт:

«Сорау: Үзегезнең шымчылык эшчәнлегегез турында сөйләүне дәвам итегез.

Җавап: Мин, Шәрәф Г. Ш., үзебезнең озак еллар дәвамында чит ил разведкасы мәнфәгатьләрендә милләтчелек эшчәнлеге белән шөгыльләнүемне таныйм.

Сорау: Сез кайсы чит ил разведкасы мәнфәгатьләрендә шымчылык белән бәйләнештә тордыгыз?

Җавап: Япония һәм Германия разведкалары мәнфәгатьләрендә.

Сорау: Сез үзегезнең шымчылык эшчәнлегегездә Япония ягыннан кем белән бәйләнештә тордыгыз?

Җавап: ... бәйләнештә идем һәм шымчылык мәгълүматларын Яхъя Алмаевка тапшырып бардым.

Сорау: Германия разведкасы оешмасыннан сез кем белән бәйләнештә идегез һәм шымчылык мәгълүматларын кемгә тапшырып бардыгыз?

Җавап: Германия мәнфәгатьләрендәге шымчылык мәгълүматларын Шәфиев белән Габделхәмит Казаков аша тапшырып бардым».

Әлеге «танулар» уңаеннан язылган гаризаларында Г. Шәрәф аларның барысына да тикшерүчеләр Кальметов белән Галакинның «һич тә ярамаган йогынты ясаулары» нәтиҗәсендә, алар янавы астында кул куюы турында яза: «...Миңа кагылган өлешендә алар берсе дә дөреслеккә туры килмиләр... минем беркайчан да андый мәгълүматлар биргәнем юк»[33].

1939 елның 17 мартында Г. Шәрәф үзен кулга алганнан бирле күрмәгән туганнары белән очраштыруны таләп итә. Ул шулай ук үзенә адвокат ялларга рөхсәт итүләрен дә сорый...

Суд якынлашып килә. 1939 елның октябрендә ТАССР прокуроры Максимов гаепләү нәтиҗәсенә кул куя. Ике көн үткәч үк Г. Шәрәф ТАССРның Эчке эшләр халык комиссарына гариза белән мөрәҗәгать итеп, үз эшен яңадан карауларын сорый: «Мин, бернинди җинаять эшләмәгән һәм контрреволюцион эшчәнлек белән шөгыльләнмәгән килеш, инде 30 айдан артык тоткынлыкта утырам». Арырак ул түбәндәгеләрне яза: «Тикшерү эшендәге барлык мәгълүматлар... ялган һәм яла ягу гына. Беренче тикшерү вакытында мин кул куйган беркетмәләрнең күпчелегендә тәгъбирләр дөрес кулланылмаган, күп кенә беркетмәләргә мин физик көч куллану аркасында гына кул куйдым һәм алардагы бөтен нәрсә — ялган...»[34].

Татарстан АССР Югары судының җинаять эшләре буенча хөкем коллегиясенең утырышы 1939 елның 22 апреленә билгеләнә. Аның эшендә халык утырышчылары Савельев, Мухина, прокурор Максимов, яклаучылар Бабадаж,

Әхмәдуллин, сәркатип Гершкова катнашалар. Г. Шәрәфне, Г. Габдерәхимовны, С. Вәлитовны РСФСР Җинаятьләр Кодексының 58-2, 58-11, 1-к маддәләре нигезендә Советка каршы эшчәнлектә гаепләү буенча эш карала. Шаһитлар итеп М. Корбангалиев, Әсма Шәрәф, Фатих Абдуллин, Мостафа Шәрәфетдинов, К. Вәлиев, Әбүзәров, Ризяев һ. б.лар чакырыла. Ләкин икәү генә — Ризяев белән Әсма Шәрәф кенә киләләр. Судны кичектерәләр, шулай да ул Г. Шәрәфнең шаһитлар сыйфатында Ф. Мөхәммәдъяровны, И. Алкинны, академик А. Самойловичны, Н. Хәкимне, Г. Максудовны чакыртуларын таләп иткән гаризасын тыңлый. Ул судка Шиһап Рамазанов белән Хәдичә Ямашеваны да чакыртуларын һәм «эш»кә үзенең фәнни хезмәтләрен дә теркәүне таләп итә.

Судның икенче утырышы 1939 елның 25 маенда була. Тоткыннарны сак астында залга кертәләр. Шаһитлардан М. Корбангалиев, Әсма Шәрәф, Зәки Уразаев киләләр. Калганнары килмиләр, ләкин бу юлы адвокат белән прокурор булмый. Судны 20 июньгә, ә аннан соң 10 июльгә күчерәләр. Ул өченче, дүртенче тапкыр да кичектерелә. Аннары, Г. Шәрәфнең һәм башкаларның ачыктан-ачык чыгыш ясауларыннан куркып булса кирәк, аларның «эше» Берия үзе җитәкли торган махсус киңәшмә карамагына тапшырыла.

Галимҗанның хатыны Әсма Шәрәф вакыйгаларның агышын үзгәртү өчен кыю омтылышлар ясый. Мәсәлән, ул үзенең 1939 елның 14 декабрендә НКВДга язган гаризасында тикшерүнең бик озак баруын, суд утырышларының берничә тапкыр кичектерелүен белдерә. Ул «шаһитлар... беренче тапкыр тикшерү вакытында минем иремә яла яктылар һәм чынбарлыкка берничек тә туры килми торган мәгълүматлар бирделәр»,— дип раслый.

СССР НКВДсы каршындагы Махсус киңәшмә 1940 елның 27 февралендә Г. Шәрәф белән Г. Габдерәхимовны «Советка каршы милләтче оешма эшендә катнашкан өчен һәркайсын сигезәр елга ИТЛга (хезмәт белән төзәтү лагере.— *Р. В.*) ябарга» карар чыгара. С. Вәлитов сак астыннан азат ителә...[35].

Шулай итеп, палачлар никадәр тырышсалар да, Галимҗан Шәрәф үзен гаепле дип танымый. Гаепсез килеш хөкем ителеп, ул үзенең 8 ел гомерен «кыңгыраудан кыңгырауга кадәр» Севердорлагта үткәрә һәм аннан 1945 елда кайтып, 1950 елның 13 январенда Казанда вафат була[36].

Аның хатыны Әсма[37], ире кулга алынгач, ике яшь бала белән кала. Озак вакыт беркая да эшкә урнаша алмый,

аннары шәфкать туташы булып эшли. Кызы 1942 елда үлә. Галимҗанны кулга алган чакта аның улына ике яшь ярым гына була. Ул әтисен бөтенләй хәтерләми. Арслан Шәрәф Казан университетының геология һәм физика-математика факультетларын тәмамлый. «Радиоприбор» заводында инженер булып эшләп, лаеклы ялга чыкты. Аңа озак еллар дәвамында «халык дошманы малае» дигән мөһер тагылган иде.

Әсма дәүләт куркынычсызлыгы органнарына гариза белән мөрәҗәгать итә һәм Галимҗан Шәрәфнең «эш»е яңадан кузгатыла... Юстиция киңәшчесе Васильев 1957 елның 17 апрелендә «эш»не яңадан карауга җибәрә. КГБ тикшерүчесе Әминев тикшерү органнары тарафыннан җентекләп җыелган гаять күп документларны һәм материалларны зур игътибар белән өйрәнә һәм бу 1957 елның 22 ноябрендә үзенең нәтиҗәсен бирә. Ул СССР НКВДсы каршындагы Махсус киңәшмәнең 1940 елның 27 февралендә Г. Габдерәхимовка, С. Вәлитовка һәм Г. Шәрәфкә карата чыгарган карарын юкка чыгарырга, ә «эш»не туктатырга кирәк дигән нәтиҗәгә килә.

Үзгәртеп кору чоры башлангач, Арслан Шәрәф әтисенең «эше» белән танышырга теләк белдерә. Аңа мондый мөмкинлек бирелә һәм ул 1990 елның 26 июлендә КГБ архивындагы 4 томнан торучы (1000 бит чамасы) тикшерү эшен карап чыга. 20 августта ул әтисенең гамәлләрендә җинаять составын тапмавы турында гариза яза. Нәтиҗәдә, РСФСР Югары судының җинаять эшләре буенча суд коллегиясе 1991 елның 30 сентябрендә СССР НКВДсы каршындагы Махсус киңәшмәнең 1940 елның 27 февралендә чыгарган карарын гаепләүнең дәлилсез булуы сәбәпле юкка чыгара.

3404 нче «эш» шулай төгәлләнә.

ХӘТЕР БУЛЫП КАЙТА ЯЗМЫШЛАР

Ачык аланнарда төлке уйный,
Урманнарга кача яшь болан.
Кил болан...
Урманнардан берни урламаган
Соңгы җан иясе мин булам.

Рәшит ӘХМӘТҖАНОВ
(Моңлану китабыннан)

ЮЛЛАР ЧАТЫ

Тарих укытучысы Шәһеретдин Шәрәфне көтмәгәндә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ректоры Галимҗан әл-Баруди бүлмәсенә чакыртып алдылар.

— Нәрсә булды икән?—дип шөбһәләнеп куйды Шәһер Шәрәф.

— Керегез,—дигән тавыш ишетелде.

Аны ректор урыныннан торып каршылады.

— Әссәламегаләйкем, Галимҗан әфәнде,—диде Шәһер дә каушый төшеп, ике кулын сузып исәнләште.

Хәл-әхвәлләрне сорашкач, Галимҗан Шәһергә:

— Нишлибез инде бу булачак журналист студент белән, Шәһер әфәнде? Кадрлар мәсьәләсен хәл итү бездә һәрвакыт авырга туры килә. Минем уемча, Борһаннан мулла чыкмас, мөәзинлеккә дә бармас. Моның сәбәбе Коръәнне белмәүдә түгел, киресенчә, ул аны барысыннан да яхшырак үзләштерә, хәтта аны тәрҗемә дә итә башлаган инде,— диде.

Шәһер Шәрәф җиңел сулап куйды, күңелендәге уйларын җиткерергә ашыкты:

— Галимҗан әфәнде, Борһан телче буларак, язу, сызу эшләренә дә бик оста. Аннан соң ул сәясәт өлкәсендә дә аңлы фикер йөртергә сәләтле. Математиканы да әйбәт үзләштерде.

Үз туганыңа бәһа бирү җиңел эш түгел. Шәһер артыгын куертмады.

— Бәлки без аны тел белеме буенча укытучы итеп калдырырбыз?—диде Галимҗан Баруди Шәһергә карап.—Сез, ничек уйлыйсыз, Шәһер әфәнде?

— Укытып карасын, Галимҗан әфәнде,—диде Шәһер гадәттәгечә тыныч кына.

Фикерләр уртак булды. Килештеләр — Борһанны тел белгече итеп калдырдылар, соңрак математика укытуны да өстәделәр. Тиз арада Галимҗан әл-Барудиның китапханәсе дә аның җаваплылыгына күчте. Бу хакта истәлекләрдә Борһан Шәрәф болай дип язып калдырган: «Галимҗан Барудиның китапханәсе Шәрекъ әдәбиятында иң бай китапханә иде, Русия буенча... Берничә ел эчендә мин анда Шәрекъ әдәбиятының төрле әсәрләре белән таныштым, шулай ук иркле фикер йөртүче Көнбатыш әдәбиятына да барып җиттем. Шул ук вакытта мин беренче тапкыр социалистик хәрәкәт һәм әдәбият белән дә таныштым. Менә инде шул вакытта минем аңымда монархия режимына карата нәфрәт туды, мин аны күрә алмый башладым, шул ук вакытта аның белән көрәш башлауның кирәклеген аңлыйм. Әмма бу көрәшне башлау өчен халыкның үзаңы үсүе, җитлеккән кадрларның булуын аңлап без бу юнәлештә көчебезне жәлләмичә эшкә тотындык. Менә нәкъ шул вакытларда Рус-япон сугышы башланып, ул дәүләткә каршы булган хисләрнең куеруына китерде, инкыйлабчыл пропаганда алып бару өчен мөмкинлекләр туды. Без бу эшне мәдрәсә кафедрасында да дәвам иттек, яшерен түгәрәкләр оештырып, 1905 елны каршы алдык»[38].

Менә шундый бай мәгълүмат туплап, 1905 ел инкыйлабыннан соң Борһан Шәрәф Оренбургка китә. Әлбәттә, китүнең бүтән сәбәпләре дә булгандыр. Иң әһәмиятлесе бу вакытта «Вакыт» газетасы чыга башлауга бәйле булырга тиеш. Әйтергә кирәк, «Мөхәммәдия»нең талантлы шәкертләренең күбесе Оренбургка килеп «Вакыт»та — әдәбият-журналистика үзәгендә үз каләмнәрен чарлаганнар. Зариф Бәшири Борһан Шәрәф турында түбәндәгеләрне яза:

«Борһан Шәрәфнең дә Оренбургка килеп «Вакыт» газетасында эшли башлавына бер елга якын иде (1908 ел.— *Р. В.*). Дөрес, үз дәрәҗәсендә мин аны да хөрмәт итәм, аның да яхшылыкларын оныта алмыйм. Татар матбугаты тарихында беренче тапкыр барлыкка килгән «Казан мөхбире» белән аннан соң чыккан «Әхбар» газеталарын башлап оештыручы һәм аларның бөтен җаваплы эшләрен алып баручы кеше — әнә шул Борһан Шәрәф иде. «Казан мөхбире» Сәетгәрәй Алкин акчасына чыгып, аның рәсми мөхәррире (редакторы) шул ук Сәетгәрәй Алкин иде. Ләкин ул газета чыга башлауга бер ел үткән булса да аның редакциясенә дә килеп карамаганлыгын беләидек. Аның редакторлык эшен дә, секретарьлеген дә Борһан алып барды. Ул да шулай ук, Галиәсгар абый шикелле, безнең ише яшь каләм ияләренә матди яктан да, мәгънәви яктан да ярдәм

итә иде. Бигрәк тә Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Миргазиз Укмасиларның башлап матбугат һәм әдәбият дөньясына чыгуларына, күтәрелүләренә аның ярдәме тиде.

Ул чагында бик күп яшь язучылар үзләренең язган әсәрләрен бастырып чыгарырга нәшрият таба алмыйлар, басылган әсәр өчен бөтенләй гонорар алмыйлар иде. Алган тәкъдирдә дә, бер китап өчен күп булса , җиде-сигез сумнан артмый иде. Мәсәлән, Г. Тукай үзенең беренче тапкыр басылган ике җыентыгына егерме биш сум гонорар алды. Бу инде бик шәп алудан санала иде. Менә шул чагында Мәҗит Гафуриның «Әхбар» газетасында басылган «Үги балалар» хикәясенә Борһан Шәрәф егерме биш сум гонорар түләде. Бу хәл күпләр телендә озак вакыткача гаҗәпләнү катыш сөйләнде, «Череп баеган икән Мәҗит Гафури!» — диделәр.

1905 ел революциясеннән соң, Казан шәһәрендә оештырылган «Берадарән Шәрәфләр матбагасы»ның төп хуҗалары — Шиһап, Борһан, Шәһер, Гыйльметдин, Галимҗан исемле биш агай-эне Шәрәфләрдән һәм аларның аталары Шәрәфи дигән авыл баеннан тора иде...[39]

Совет чорында язылган истәлектә дә милләтче, халык дошманы дип аталган Борһан Шәрәфкә карата булган мондый җылы юллар, әлбәттә, аның тагын да югарырак баскычта торганлыгын раслый.

Борһан Шәрәф үзе дә бу чор турында шактый мәгълүмат калдырган. Ул «Казан мөхбире»ндә, «Әхбар»да эшләгәндә үзе ирекле секретарь, мөхәррир дә булганлыктан, газета битләрендә чыгачак материалларны сайлау да аның үз ирегендә була, ул үзе теләгән материалны бастыра. Бу хәл шактый вакыт дәвам итә. «Ә беркөнне, һич көтмәгәндә С. Алкинның ресторанда утырганда «Казан мөхбире»н бер бутылка коньяк бәрабәренә купец Сәйдәшевкә сатканын ишеттем»,— ди ул.

«Әхбар»ны ул тагын да радикальрәк органга әйләндерә, игътибарны татар халкы тормышындагы дини мәсьәләләргә һәм җитәкче оешмаларның роленә юнәлтә. Менә инде шуннан соң җаваплы оешма аңа түләүне туктата һәм бу газетаны да Борһан ябарга мәҗбүр була. Шуны да әйтеп узарга кирәк. Озакламый Шәрәфнең эшләре белән жандармнар да актив рәвештә кызыксына. Аңа яхшылык теләүче бер иптәш аңа тиз арада кулга алыну мөмкинлегенә ишарә ясый. Бу кисәтү алдыннан берничә мәртәбә Б. Шәрәфтә тентүләр була, аны судка бирәләр. Шундый кискен хәл килеп туган чорда бердәнбер чара Оренбургка качып котылу була. Монда ул татарлар азрак, шуңа күрә эзәрлекләүләр дә азрак булыр дип уйлый. Шул ук вакытта

күп санлы журналистлар, язучылар Закир һәм Шакир Рәмиевләр чакыруы буенча Оренбург шәһәренә китәләр. Шушы уңай белән Г. Тукай «Яшен» журналында «Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны» дигән бер җыр бастырып чыгара. Шуннан соң беркадәр вакыт узгач Рәмиевләр Тукайның үзен дә Оренбургка чакыралар, әмма ул: «Мин Казанны ташлап китә алмыйм»,—ди. Б. Шәрәф эзәрлекләүләрдән качып үзенә журналистика өлкәсендә киңрәк мәйдан эзләп китәргә мәҗбүр була. Әлбәттә, башкалар кебек үк беркадәр матди яктан тәэмин ителү дә күз алдында тотылгандыр, әмма ул төп фикерен милләтне агартуга, аңа үзаңын үстереп, патша хөкүмәтен бәреп төшереп, нәтиҗәдә бердәм төрек-татар дәүләте төзүгә юнәлтә. Аның бөтен көче, бөтен өмете шуңа багышлана.

Күпсанлы хатларыннан, Казанга ашкынуларыннан аның Оренбургка мәҗбүри китүе бик тә ачык күренә. Оренбургка барып төшү белән ул Фатих Әмирханга хат юллый, Ф. Әмирхан да үз чиратында җавап хатлары җибәреп тора, дус-иш аркылы сәламнәр тапшыра. «Борһанга сәлам тапшырыгыз», ди ул Исмәгыйловка һәм Аитовка язган хатларында. Хатларының берсендә: «Борһанга сәлам сөйлә, минем өчен кулын кыс. Аннан соң хат язмый озак торган өчен бик нык орыш!»—дип яза. Шул ук елның (1909) 27 апрелендә язган хатында Б. Шәрәфнең өйләнүе турында ишеткәч ул шатланып: «Борһаннан бер озын хат алдым, Закирә туташка тәкъдим ясаганын белеп ничектер чын күңелемнән рәхәтләндем. Вакыт бик җиткән иде... Борһанның өйләнеп җибәрүе сезгә дә, дус ишләргә дә җиңел аяктан булсын»,—ди. Казанда чагында, әле Казанга килеп кенә җиткән Г. Тукайны Казан буйлап озатып йөргән Б. Шәрәф Ф. Әмирханның да аерылмас сердәше, дусты булып әверелүе мәгълүм.

Классик язучыларыбызның һәм сәясәт өлкәсендәге зыялыларыбызның дусты була алган Б. Шәрәф өметен өзми. Ул Казанны сагына һәм ешрак кайтып-китеп йөрергә тырыша. Шундый кайтуларның берсе август аенда, 1909 елда була.

ПАНАЕВ БАКЧАСЫНДА ОЧРАШУЛАР

Борһан Шәрәф, Панаев бакчасындагы кинематографка килеп кергәч тә, халыкның тәртипсез рәвештә чабышуын, йөгерешүен күрде. Сораштыра торгач, беленде: кинематографта янгын булган икән. Инде ут та сүндерелгән, ялкын каралтыларга күчәргә өлгермәгән.

Шау-шудан һәм ыгы-зыгыдан һәвәсләнгән Садри әфәнде Максудов, «Вакыт» газетасының хәбәрчесен күргәч:

— Әссәламегаләйкем, Борһан әфәнде,—дип кулын суз-ды.—Бу халык дигәнең бигрәк тә гаҗәп инде, тәртип саклый белмиләр. Кинематограф аппаратының бүлмәсе яна башлагач, халык аны-моны карамый тыгызлашты, чыгып та китә алмыйлар, сүндерергә керешүче дә юк. Аппарат будкасын менә шушы кулларым илә аударып җибәргәч кенә, ут каралтыларга күчми калды.

Хәл-әхвәлләрне кыскача гына сорашып, тагын да тынычлангач, Борһан:

— Садри әфәнде. Сезгә берничә соравым бар иде бит әле?—диде.

— Әйдә, әфәндем, сорашыгыз, «Вакыт»ны ни кызыксындыра икән бүген. Янгын турында инде сөйләдем кебек...

— Менә ни, ишетүем буенча, Сез бүген, 27 августта, губернаторда, әлеге дә баягы, теге думада да каралган мәсьәлә, җомга көн кибетләрне ябу турында сөйләшкәнсез икән. Ничегрәк тора икән бу мәсьәлә?

— Әйе, кердем. Губернатор үзе юк иде, шуңа күрә, вице-губернатор белән генә сөйләшергә туры килде. Ул үзе дә күптән түгел генә эшли, мәсьәләләрнең күбесен аңлап бетермәгәнлеге күренеп тора. Либерал булып кыланса да, мөселманнарга җомга көнне кибетләр ябу мәсьәләсендә бик нык каршы тора. Имеш, бу русларның сәүдәсенә зыян китерә, аннан соң алар кибет ябу мәсьәләсен барыбер төгәл үтәмиләр... «Якшәмбе һәм башка бәйрәмнәргә дә кибет ябу турында махсус закон бар, мин аны боза алмыйм», диде вице-губернатор. Бу мәсьәлә Дәүләт думасында каралып, яңа закон чыгарылганчы, мондагы гадәтнең дәвам иттерелүен һәм якшәмбе көн кибет япмаган өчен мөселман сәүдәгәрләре өстеннән ясалган протоколның эшкә ашырылмавын үтендем. Вице-губернатор тәртип бозылган очракта да җәза бирелүнең ашыктырылмавын әйтте.

Борһанның бер яхшы гадәте бар иде: ул үзе сөйләүчегә комачауламый, тыныч кына, аңа барысын да сөйләргә ирек бирә. Бу юлы да Борһан сабырлыгын җуймады. Ул, Садрины тыңлый-тыңлый, кесәсеннән кульъяулыгын алып, маңгай тирләрен сөртте, янә шул сораулар тирәсендә әйләнеп, мәсьәләнең югарырак баскычларда каралу-каралмавы хакында сорашты:

— Садри әфәнде, әлеге хәлне думада ничегрәк карыйлар икән соң? Аны дин белән бәйләп карауны яратмыйлардыр шул?

Садри әфәнде ашыкмады. Шактый уйланып торды да, салмак кына сөйләп китте:

— Мәсьәлә диндә генә булса, бәлки җиңелрәк тә булыр иде, Борһан әфәнде. Бу комиссиядә либераль фикердәге кешеләр аз түгел, ләкин мәсьәләнең икътисади җәһәте бар. Руслар, ни кадәрле хөр фикерле булсалар да, рус сәүдәгәрләренә мөселманнар тарафыннан зарар килүен яклый алмыйлар. Комиссиянең рәисе Тизенгаузен инородецлар күп булган шәһәрләрдә бәйрәм көннәрен үзләренә тәгаен итәргә рөхсәт бирү фикерендә. Гучков, үзең беләсең, сәүдәгәр, Милюков бу мәсьәләдә русларны ачуландырырга бер дә теләми... Милюков, кадет булса да, мөселман мәсьәләләрендә Гучковтан бик күпкә уңда.

— Беләм инде ул мөртәт Милюковны,—диде Борһан, бу юлы түземсезләнеп,—беләм мин аны... Мин аның кем икәнлеген Балкан мәсьәләләренә карата ясаган нотыклары аша чамалаган идем инде. Аның төрекләрне яратмаганын Болгариядә эшли башлагач ук абайладым. Ул бит София университетына профессор Драгомилов урынына чакырылган иде.

— Хәер, алай гына да түгел, Борһан әфәнде,—дип дәвам итте Садри Максудов.—Эш шунда ки: Гучков бөтен җаны-тәне белән сәүдә кешесе. Ул һәрнәрсәгә дә күнә, әмма Милюков рус милләтеннәндер. Ул һәрбер мәсьәләгә милләтенең мәнфәгате җәһәтеннән генә карый. Руслыкның һәрнәрсәдә өстен булуын таләп итә...

Фикерләр төрлесе төрле яктан килеп кушылдылар. Бу Борһанның һәм Садриның да күңеленә хуш килде. Әлеге минутта алар фикердәшләр иде. «Әйе, безгә шовинизм дигән явызлык яный. Ул Милюковтан өмет юк. Безнең милләткә карата аның эчендә гел карадыр»,—икесе дә шул фикердә калдылар.

— Алар арасында кара эчле кадетлар күп, әмма алар Милюков кебек тыштан күрсәтмиләр,—дип сүзен дәвам итте Дәүләт думасы депутаты Садри Максудов.

Сүз Дәүләт думасының булачак мәҗлесләренә күчте.

— Бу кыш мөселманнар өчен бик мөһим мәсьәләләр каралачы икән: сәүдә, һөнәрханәләр, мәктәп, халык мәгарифе,—диде Садри Максудов.—Иң мөһиме—укыту теле мәсьәләседер. Аннан соң, бу мәсьәләгә якын торган Европа илләре, Австро-Венгрия һәм Германияләрне искә алып, анда инородецларны немецчә генә укырга мәҗбүр итүләрен сөйләп, бездә дә бөтенләй үз телебездә мәктәп тәрбия итеп торыр дип өметләнергә бик күп ышаныч юк. Шулай да, думада октябристлар мәктәпләрдә башта ике ел буена ана телендә укытуны хуп күрделәр. Әгәр дә бу программаны

кабул итмәкче булып сатулашсак, бәлкем өч елга да күтәрерләр. Бәлки иске мәктәпләребезне, мәхәллә мәктәпләрен шул көе калдырырга мөмкин булыр.

Сүзне хөкүмәт тарафыннан оештырыла торган мәктәпләр турында алып бара иде депутат әфәнде. Аның шулай икәнлеген аңласа да, Борһан Шәрәф янә сорап куйды:

— Яңа программа шәһәр һәм земство-хөкүмәт тарафыннан оештырылган мәктәпләргә карыйдыр бит?

— Нәкъ шулай, Борһан әфәнде, нәкъ шулай. Әгәр шул программаны кабул итсәк, элек тә булган мәктәпләребез янына хөкүмәт, шәһәр вә земстволар тарафыннан мәктәпләр арттырылган була. Монда безнең кулыбыздан бернәрсә дә чыкмый, шушы яңа мәктәпләр балаларыбызга файда булсын.

Мондый нәтиҗәдән бераз аптырабрак калган Борһан Шәрәф, озак көттереп тормыйча, депутат әфәндегә яңа соравын биреп өлгерде:

— Бу нәрсә, Садри әфәнде, кяфердән иман өмет итмәк булумы инде?

— Өмет бар, халык аларны яратып кабул итсә, ул мәктәпләр күбәерләр, әмма алар янында мәхәллә һәм башка мәктәпләрне дә саклап калырга кирәк...

Сәгатенә күз төшереп алгач, Садри әфәнде ут капкандай сикереп торды:

— Борһан әфәнде, онытып ук җибәргәнмен бит, китәргә рөхсәт итә күрегез, киләсе кешем бар иде бит!—дип, китәргә җыенды.

— Кызганыч, бәлкем «Швейцария»гә (хәзерге Горький исемендәге Үзәк ял паркы.— *Р. В.*) барып чыгарбыз, Әмирханнар белән дә очрашып чәйләрбезме әллә дип өмет иткән идек бит,—диде Борһан.

Максудов көлемсерәде:

— Преферанс уйнап, хәмер-чәй кабып, милләт кайгыртыргамы?—диде ул.— Икенче юлы, алла боерган булса.

Очрашырга сүз куешып аерылышкач, Борһан Садри Максудовның артыннан карап калды. Аннан соң үзе дә кузгалды.

Акрын гына атлап, Рыбнорядская урамына килеп чыканын үзе дә сизми калган. «Урамы бар, балыгы гына калмаган...—дигән уй узды аның башыннан.— Мәктәпләре дә булыр, ә теле булырмы?» «Болгар» номерлары ягына атлады. «Габдулланы күреп чыгармын, әле вакыт күп, караңгы төшкәнче өйгә дә җитәрмен»,—дигән иде, шунда ук кире борылырга туры килде: Габдулла Тукай бүлмәсендә юк иде. Номерында берничә яшь егет кенә: «Менә кайтыр, көтегез!»—дип утыралар иде.

Сөйләшенгәнчә, шул ук бакчада, шул ук сәгатьтә диярлек очраштылар. Бүген Садри әфәнде тыныч һәм бөтенләй диярлек хафасыз иде. Бу юлы Борһанны аның Европа илләренә булган сәяхәте кызыксындырды. Ул дума депутатына күптән әзерләп куйган соравын бирде:

— Англиягә сәяхәтегез хакында сөйләмәссезме? — диде.

Сорау Садри әфәндене гаҗәпләндермәде, ул тыныч кына сөйли башлады:

— Инглизләр рус депутатларына гадәттән тыш хөрмәт күрсәттеләр, кунакка чакырдылар... Карл Эдуардның күрсәткән илтифат вә игътибары гадәттән тыш булды. Әмма аларның бер эшләре дә бушка түгел — үз файдаларына. Алар Русияне үз якларына аударырга тырышалар.

Аннан соң Максудов Берлинга сәяхәте турында сөйләде:

— Берлинга барыш Англиягә сәяхәттән бөтенләй башка, максатлар да башка, Русия депутатларының анда тоткан урыннары да башка. Мин анда нотык сөйләргә әзерләнгән идем. Хәзерге заманда дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә ислам дәүләтләре, исламны файдаланып бөтен дөньяда «бердәм килешү төзү», «гомум хәлне ныгыту» өчен моңа карата христиан диненең өлеше дә кертелергә тиеш кебек уйларымны сөйләргә теләгән идем. Аннан соң, дәлилләр итеп, Төркиядәге кансыз революцияне, Иран хәлләрен китермәкче идем, әмма күңелсез хәл килеп чыкты, сүзләремне әйтә алмадым.

— Ни булды, Садри әфәнде, тәфсилләп сөйләсәгез иде, — диде Борһан тагын да кызыксына төшеп. Ул Берлин вакыйгаларын ишеткән булса да, татар газеталарында Садри Максудовның материалларын күрмәгәнлектән, аптырап калган иде.

— Нотыкны сөйләргә рөхсәт итмәделәр. Милюков миңа: «Садри әфәнде, сез үзегезнең Русиядән килгәнегезне онытмагыз. Монда бәйнәлмиләл (интернационализм.— *Р. В.*) мәсьәләсен кую кирәкмидер, сез Истанбулдан, йә Тегераннан килмәдегез бит» кеби сүзләр сөйләде. Тагын да төрле сылтаулар таптылар. Гомумән, сөйләүне тыйдылар. Башка депутатлар белән дә шулай булмагандыр дип уйлап булмый. Шуңа күрә бу җыелыш немецләрдән башка берәүне дә разый итмәде. Француз депутатлары мәҗлесенең ахырын көтмичә кайтып киттеләр.

Милюковлардан башканы көтмәгән Борһан өчен бу, яңалык булса да, шаккатырырлык вакыйга түгел иде. Шуңа күрә ул депутатның фикерен башка сорауга юнәлтте:

— Киләчәктә безнең хокуклы һәм хөрриятле булу өметлеме?

Әлеге сорауга җавапны күптән эзләгән Борһан Шәрәф бу өлкәдә үзе дә күп уйлый иде; абыйлары Шиһап һәм Шәһер, энесе Гыйльметдин белән дә бер генә тапкыр сөйләшмәде. Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай һәм башкалардан да бу турыда аларның фикерен сораштырган иде...

Дәүләт думасының депутаты озак сузмады, җавабын да бирде:

— Тиздән зур инкыйлаблар көтәргә дәлилләр җитешми,— дип сүзен башлады ул.— Мәгариф вә милләт юлында эшләүчеләр күбәйсә, халыкның фикере ачылса, эшләр башка булыр иде. Менә, госдуманың бу җыелышында шәһәр вә земство идарәләре хосусында яңа законнар чыгарылачак. Мөселманнар да моңа катнашыр дип өмет итәм.

Соңрак сүз татарларның көче-куәте хакында фикер алышуга күчте. Депутат мөселман халыкларының киләчәген гомум алганда өметле дип таба. Ул, фикерен дәвам итеп, болай диде:

— Беләсең бит, иҗтиһад, гайрәт һәм вакыт көткәннән артык нәтиҗәләр бирә. Үткән биш-ун елда мәйданга килгән нәрсәләр элек тә көтелгәннән артык булды. Моннан соңгы биш-ун елда нигә шулай булмас икән[40]?

Бу сүзләрдән соң сигез ел үткәч, ике инкыйлаб булып, чыннан да зур үзгәрешләр башланды. Казаннан Оренбургка кайтып, «Вакыт» газетасына бу репортажны тапшыргач, Борһан Шәрәф яңа бер вазифа белән Иранга сәфәр чыкты. Бу вакыйгалар 1909 елда булды. Көз көне иде. Әле революциягә кадәр туп-тулы сигез ел калган, ә тирә-якта революцияләр кайнап тора. Шуларның берсе Иранда булып узды. Тынгысыз Борһанны ул вакыйга үзенә җәлеп итте. Киләчәктә хокук, хөррият даулаганда башкалар тәҗрибәсе безнең халыкка да ярап куймас дип кем әйтер?

Үзгәрешләр, чыннан да, көткәннән артык булды. Әмма революцияләрнең нәтиҗәләре «Гомум солых»ка, «Бөтендөнья килешү»гә, «Гомум хәлне ныгыту»га да китерә алмадылар. Әгәр дә С. Максудиның «Бөтендөнья килешү»е генә дә дөньяда тормышка ашырылган булса, без тоталитар режимны һәм бүгенге авырлыкларны бәлки әйләнеп уза алган булыр идек.

Бүген дә дөнья, алдынгы зыялылар килешү юлларын эзлиләр. Алга баруның юллары бертөрле генә түгел икәнлеге күптән, гасыр башында ук мәгълүм иде. Бүген дә шулай, әмма инде кешелек дөньясы күп җәфалардан соң бары тик реаль альтернативага гына баш ияр — бөтендөньяда килешү юлында гына бәхетле булачагын аңлар кебек тоела. Тарихыбыз да моны бик яхшы раслый.

ИНКЫЙЛАБКА БАР ӨМЕТ!

Борһан Шәрәф Оренбургка килеп урнашкач та, аның артыннан ук диярлек Зариф Бәшири, Галиәсгар Камал, Рәкыйб Рәкыйби, Заһит Шәркый, Шәриф Камал һәм башкалар да килеп газета-журналларда эшли башлыйлар.

Ул тиздән «Вакыт» газетасында Фатих Кәрими җитәкчелегендә эшкә керешә. (Фатих Кәрими «Вакыт» газетасының баш мөхәррире һәм Борһанның хатынының абыйсы була.) 1917 елга кадәр Б. Шәрәф әлеге газетаның махсус хәбәрчесе булып эшли. Беркадәр вакыт ул җаваплы сәркатиб була. Реакция чорында «Вакыт» газетасы күбрәк мәдәни-агарту эшләренә урын бирә, шул ук вакытта акрынлап сәяси һәм икътисади мәсьәләләрне дә көн тәртибенә куя.

Русиядә реакция котырган чорда Төркиядә, Иранда революцияләр булып уза. «Вакыт» газетасы аларның тәэсирен, алардан соңгы үзгәрешләрне белү, аларны халыкка җиткерү теләге белән үзенең тәҗрибәле журналистын Иранга эш белән җибәрә. Бу үзенә күрә бер күңел ачу сәяхәте кебек тоелса да, Борһан өчен исә бик авыр, җаваплы, хәтта куркыныч эш була. Шунысын да әйтеп узарга кирәк, аны Бакуда да, Тәһранда да каршы алучы булмый. Ул, ирекле корреспондент-сәяхәтче сыйфатында йөреп, үз хәлен үзе кайгыртырга тиеш. Бу сәяхәт вакытында ул Иранның Тәһран, Инзил, Решт кебек шәһәрләрендә була. Узышлый Баку, Петровск кебек шәһәрләрдән хәбәрләр юллый. Сентябрь-октябрь айларында да ул «Вакыт» газетасына Иран-нан үзенең «Иран мәктүпләре» (Иран хатлары.— *Р. В.)* дип аталган репортажларын җибәреп тора. Турыдан-туры Иранга караган беренче репортажы «Вакыт» газетасында 1909 елның 10 октябрендә басыла[41]. Бу репортажларында сәяхәтче нәрсә күрә, шуның хакында яза. Бу юлъязмалар шактый күләмле очерклар булып басылалар. Аның язуына караганда, Каспий диңгезендә Иран белән Русия арасындагы су юлын Бакудагы Тагиевлар пароход оешмасы тәэмин итеп тора. Иранда Русия акчалары зур дәрәҗәгә ия, сату-алу әйберләре шактый арзанга туры килә. Иран ягында төрле сәяхәтчеләр, төрле милләт кешеләре очрый. Күпчелеге әрмәннәр, руслар, бельгиялеләр, иранлылар. Алар арасында хатын-кызлар да бар, ди ул. Борһанның әйтүенә караганда ил чикләрен узу бик ансат була. Төрле шәһәрләрне тасвирлый, аларның икътисади һәм сәяси әһәмиятен дә күрсәтә. Аерым алганда ул: «Инзил шәһәре

аша күп юллар узганга, монда зур фирмаларның конторлары күп»,—ди. Аның язуына караганда, Инзил китапханәләрендә «Русское слово», «Речь» газеталары да була.

Аның Инзилдән Решт шәһәренә сәяхәте дә кызыклы. Әйтүенә караганда, Решт шәһәрендә ул «Альберт» дип аталган кунакханәдә туктала. Шунысы кызык, бу кунакханәнең хуҗасы Сембер губернасыннан чыккан крестьян хатын-кыз була. Б. Шәрәф әлеге шәһәрдә Англия, Германия һәм Русиянең илчелекләре булуы хакында хәбәр итә. Ул рус илчесен күрергә килгәч, аның бөтенләй китеп барганлыгын белә. «Решт халкы,—дип яза ул,—халык санын исәпкә алуның нәрсә икәнен белми. Шәһәрдә ничә мең кеше барлыгын чама белән генә 70—80 мең диләр. Шәһәр урамнарының исемнәре дә юк, ничә урам барлыгын да билгеле юк. Шәһәрдә хәрәкәт бик кызу, сату-алу эшләре дә җитез бара. Моннан елына 12 миллион сумлык ефәк кенә чыгарыла. Иң югары җитештерү проценты җиләк-җимеш сатуга туры килә. Монда немец, француз товарлары, Төркия һәм Русия аркылы урап, күпләп китерелә. Бик күп товарлар Русия аша почта белән бернинди пошлинасыз килә. Бер фирма, мәсәлән, почта аша йөзләгән, меңәрләгән посылкалар ала. Шаһ тарафдарлары булган Решт өлкәсе конституцион монархистларның үзәге булып исәпләнә».

Б. Шәрәфнең 1909 елның 24 ноябрендә язылган репортажында түбәндәге юллар бар: «Иран сәясәтенең бик буталчыклыгы сәбәпле тугры вә ачык хисап бирүнең мөшкел булуы—миңа сак кына каләм тибрәтергә мәҗбүр итә. Үзем канәгатьләнерлек бер фикер хасил итәр өчен күп тикшермәк вә күп урыннан мәгълүмат лазим иде. Хатамны танымыйча хәл юк, мин «яңарган Иран»га дип сәфәр иткән идем. Уемдагы шикләр: элеккеге шаһ Мөхәммәтгалинең сәяси революциясе Иранда чыгарылышы илә тәмам булды, инде төпле яңа тормыш башланачак. Иран территориясе конституция һәм хөрриятькә бик күп кан коюлар бәрабәренә җитешкән өлкә—иң асыл идарәмез бик интегеп көтеп ала... Һәрбер эшләр юлга салынырга тиеш иде... Минем фаразларым шул иде. Бабайларның өйдәге гакыл базарга ярамый дигән сүзләре тугры чыкты».

Иран революциясеннән соң, Иранның уңай якларын гына яктыртырга теләгән Б. Шәрәфкә аның караңгы якларына да игътибар итәргә туры килә. Ул Иран революциясе тарафыннан иске хөкүмәтнең җимерелүен, аннан соң да тотрыклы яңа тормышның бик тиз булмаячагын аңлап: «Ике-өч ел тәртипсезлек сатуны торгынлыкка, күпме гаиләләрне харап итәргә, вә милләтне ничә елларга кире җибәрергә кифая

итәдер». Хөкүмәттә тәртип сакларлык куәт, хәзер дә күз алдында булмаган бәланең, торгынлыкның тиз арада үзгәрүе күренми»,—дип яза; ул чордагы хәлнең бер сыйныфны да канәгатьләндерелмәгәнлеген хәбәр итә.

Борһан шактый төпле итеп Иран революциясендә катнашкан төрле агымнар, көчләргә үзенчә анализ ясый, анда дүрт агымны аерып күрсәтә. Аларның беренчесе — аксөякләр һәм ханнар. Алар иске дәүләт заманында бик зур дәрәҗәгә, күп милеккә ия булалар. Икенчесе — руханилар; өченчесе — сәүдәгәрләр; дүртенчесе — зыялылар. Бу көчләрнең яхшы һәм яман якларына да анализ бирелә. Борһан Шәрәф белән килешергә дә, килешмәскә дә мөмкин, әмма аның революциядән соңгы чорга — торгынлыкның шактый вакытка сузылу ихтималы булуына биргән бәясенә беркемнең дә шиге юк. Мондый хәл Иран революциясенә генә түгел, барлык сәяси революцияләргә дә хас нәрсә дип карарга кирәк. Торгынлыкның дәвам итүе, аның срогы, масштабы җәмгыятьтә хәрәкәт итүче көчләргә дә бәйле.

Иранда эшчәнлек алып баручы аксөякләргә бәя биргәндә, ул аларны рус дворяннары белән чагыштыра, яңа тормыш җиңгән очракта аларның һәлак булачагын әйтә: «Алар үзләренең наданлыгы һәм ваклыклары белән шактый аерылып торалар. Руханилар — искелекне яклаучылар, бары тик искелекне ныгыту өстендә генә эш итәләр. Алар зур җир иясләре, ә вак руханилар бары тик үзләреннән өстеннәрне генә тыңлыйлар, тик үзләре генә көрәшергә сәләтсезләр. Алар арасында бары тик Җамалетдин Әфгани гына аерылып тора. Аның тарафдарлары яңа конституция өстендә үзләрен аямыйча эшлиләр. Бу революциядә дә руханилар бер кырыйдан гына карап тордылар. Аларның фикеренчә «бу кирәкми торган эш», янәсе. Шәех Фәйзулла кебек үз белдеге белән эш итүчеләрне бары тик дар агачлары гына көтә иде».

Сәүдә торышын Б. Шәрәф түбәндәгечә тасвирлый: «Буталышлар башлану белән сату-алу эшләре азая. Бу чорда байның язмышы билгеле булмаганлыктан, ул кредитны бирми, бу үз чиратында фирмаларны бетерүгә китерә, ә банкроттан сакланып кала алганнары үзләренең эшләрен сүлпәнәйтәләр. Әгәр дә революциягә кадәр аларны шаһ талаган булса, ә революциядән соң, революция тарафдарлары талый. Нәтиҗәдә күбесе үз кәсепләреннән баш тарта, качалар, алтын-көмешне яшерәләр — җиргә күмәләр... Базарда бары тик тиеннәр генә кала»[42].

Мондый хәл, әлбәттә, беркемне дә тынычландыра алмый. Икенче төрле итеп әйткәндә, Б. Шәрәф фикеренчә,

Иранда икътисади һәм сәяси хәл тотрыклы булмаганлыктан, җәмгыятьтә дә таркаулык, озак вакыт торгынлык хөкем сөрә.

Алдынгы карашлы иранлылар бөтен өметләрен милли мәҗлес белән бәйлиләр. Бу мәҗлес 1909 елның ноябрендә җыела һәм Б. Шәрәфкә анда катнашу насыйп була. Ул аннан да репортажын «Вакыт» газетасына җибәрә. Аның «Милли мәҗлеснең ачылуы» дигән репортажында (Вакыт, 1909, 1 декабрь) мәҗлес ачылыр алдыннан һәм мәҗлес эшли башлаган көннәрдә шәһәр урамнарының бәйрәмчә, матур итеп бизәлгәнлеге, халыкның мәҗлесне зур бәйрәмне каршы алган кебек кабул кылуы хакында бәян ителә. Ул унике яшьлек шахиншаһ Әхмәднең тантаналы рәвештә милләт мәҗлесенә килеп, Иран халкына мөрәҗәгатен укуын тасвирлый, аның сүзләрен китерә[43]. «Бу мөрәҗәгатьтәгечә революция ирек яулап алу белән тәмамланды һәм киләчәктә милләтнең үсеше өчен зур мөмкинлекләр ачылды, минем хөкүмәтем (дәүләтем) илдә тәртип урнаштырырга һәм культураның яңа үргә күтәрелүе өчен барысын да эшләячәк. Кайбер урыннарда каршылык күрсәтүчеләр бар, әмма без алардан илне чистартырбыз. Мин бик шатмын — башка илләр белән дә дуслык үсә, ныгый башлады»[44]. Б. Шәрәф Әхмәд мөрәҗәгатенең реформаларга караган өлешендәге бик мөһим урыннарын аерым басым ясап күрсәтә: беренчедән, милли байлыкны үстерү программасы; икенчедән, жандармерия һәм полиция турында; өченчедән, конституцияне ныгыту һәм Иран милләтенең көчен үстерү, ныгыту.

Бу — Борһан Шәрәфнең Ираннан язган соңгы репортажы. Ираннан кайтышлый ул янә Бакуда туктап, монда әдәбиятчы һәм язучы, азәрбайҗан мәдәни агарту өлкәсендә танылган шәхес Хөсәензадә белән очраша, аннан да «Вакыт»ка мәкаләсен җибәрә. Алар төрек-татар мәсьәләсен уртага куеп, төрле проблемалар турында сүз алып баралар. Иран революциясенең Кавказ халкы өчен әһәмияте турында Хөсәензадә: «Иран революциясе безнең милләткә бик зур тәэсир итте һәм киләчәккә өмет белән карарга мөмкинлек ачты. Әгәр дә Иранда, Төркиядә эшләр яхшы икән, безгә дә кулай, безгә дә файдалы». Сүз бердәмлек мәсьәләсенә күчкәч, ул: «Әгәр дә киләчәктә бердәм булыйк дисәк, бер-беребезне аңлыйсыбыз килсә, безнең классик әдәбиятыбыз госманлы телендә булырга тиеш. Әгәр дә сез, Борһан әфәнде, казанча сөйләсәгез, ә мин — азәрбайҗанча, ул вакытта безгә бер-беребезне аңлау авыр булыр иде. Күрәсез, госманлы белән бер-беребезне аңлашып утырабыз[45], — дип җаваплый.

Бүгенге көннәр өчен дә бик гыйбрәтле булган язмалар шулай итеп, ерак Ираннан, Бакудан кайтып, «Вакыт» аша узган еллар авазы булып безгә дә килеп җитә алдылар. Әлбәттә, безнең өчен бу — бик зур байлык. Заманында әлеге материалларга бәя бирү мөмкин түгел иде. «Милләтче», «контрреволюционер», «халык дошманы» булып саналган Борһан Шәрәф турында дөреслек, аның тугры, саф күңелле булуы хакында бер дә язылмады. Бу турыда Б. Шәрәфнең шәкерте Зариф Бәшири тоталитар режимның әле куәтле чорында түбәндәгеләрне яза: «Иран шаһы Мөхәммәтгали тәхетеннән куылган, «Вакыт» газетасы редакциясе аны Иранга хәбәрче итеп җибәрде. Ләкин ул аннан бер генә рәтле нәрсә язмаса да, үзләренең Казандагы җимеш сәүдәләрен үстерү юлында шактый зур эшләрне башкарып кайтты»[46]. Менә сиңа кирәк булса?! Мондый яла ягулар тоталитар режим чорында үз-үзеңне саклауның бер ысулы булмагандыр дип ничек әйтәсең. Шулай булгач Зариф Бәширине дә аңларга мөмкин. Хәер, һәр чорның үз ялагайлары була. Борһан Шәрәфне мактап кына язган очракта аның үзенең дә истәлекләре дөнья күрә алыр иде микән?

Ираннан кайтып беркадәр хәл алгач, Борһан Шәрәф Бохара якларына барып, аннан да төрле чуалышларны, хәл-әхвәлләрне тасвирлап «Вакыт»ка «Бохара мәктүпләре» дигән баш астында хәбәрләр җибәреп тора. Ул монда Абдулкадыйр Мөхетдинов белән элемтәгә кереп, Бохара әмиренә каршы материаллар туплый. Бераздан А. Мөхетдинов, Б. Шәрәф булышлыгы белән «Вакыт» газетасының махсус хәбәрчесе булып китә.

Соңрак бер төркем татар зыялылары Шиһабетдин Мәрҗанинең 100 еллык юбилеен үткәрүгә әзерлек башлап җибәргәч, бу эштән Б. Шәрәф тә читтә кала алмый. Ул «Мәрҗани» дип аталган җыентыкка «Хәзерге яшьләр нәзерендә Мәрҗани. Мәрҗанинең милләтебезгә күрсәткән хезмәтләре» дип аталган язмасын әзерләп бирә. 1911 елда «Шура» журналының 23—24 нче саннарында аның Мәрҗанигә карата фикерләре дөнья күрә. Ул анда Мәрҗанинең эшчәнлегенә югары бәя биреп: «Ул үзенең хезмәтләре белән безнең алдынгы иҗтимагый фикерне, милләтебезнең яшәешен яңарту өлкәсенә зур өлеш кертте»,— ди. «Мәрҗани» җыентыгында басылган мәкаләсендә Б. Шәрәф Ш. Мәрҗани турында: «...Ул исә гыйлемне мәдрәсә почмагыннан чыгарды... Ш. Мәрҗани — безнең танылган «Олуг абыебыз»,— бөек укытучыбыз, милләтебезнең дәвамчысы»[47] кебек юлларны яза.

1914 елда «Вакыт» газетасы хуҗаларының Рәмиевләр

белән мөнәсәбәтләре бозылгач, Б. Шәрәф редакциядән китәргә мәҗбүр була һәм, үзенең әйтүенә караганда, 1918 елга кадәр Оренбургта «Урал» кунакханәсен арендага алып, шуның файдасына көн күрә. Арендатор буларак ул бик уңган эшмәкәр була алмагандыр, чөнки революция башлану белән үк ул барысын да ташлап революцион хәрәкәткә чума. 1917 елның 6 мартында Оренбург мөселманнарының Икенче съездында ул мөселман «Бюро»сы әгъзасы итеп сайлана. Аннан кала әлеге «Бюро»га Фатих Кәримов, Гариф Мутин, Кәлимулла Хәсәнов, Ибраһим Бикчәнтәев, Әхмәт Байтурсунов, Габделгазиз Хәсәнов, Г. Тимербулатов һәм Г. Низабаев керәләр[48]. Борһан Шәрәф мөселман «Бюро»сының рәисе итеп сайлана. 1917 елның 25 июнендә Оренбург губерна идарәсе залында башкорт съездын әзерләүгә багышланган җыелыш була. Монда да рәислекне Б. Шәрәфкә тапшыралар. Бу җыелыш шәһәр думасына 5 нче номерлы исемлек буенча 39 кешедән торган сайлаучылар исемлеген раслый. 30 июньдә Оренбург приказчиклары җәмгыятенең җыелышында шәһәр думасына булачак сайлаулар вакытында тактика мәсьәләсе карала. Мәҗлес Морат Сәгыйтов тарафыннан Коръән укып ачыла. Аннан соң Тимер Шәмсуллаев һәм Мәсгуд Мәрдәншин нотыклар сөйлиләр. Алар мөселманнарның бердәм булып хәрәкәт итүләрен хуп күрәләр. Тимерша Шәмсивәлиев: «Аерым яшәсәк, Алтын Урданы йоткан кебек урыс йотачак»,—ди. Борһан Шәрәф тә тактика мәсьәләсенә кагылып, ассызыклап социалистларны шәһәр думасына сайлаулар вакытында укыту, сәламәтлек саклау мәсьәләләрен дөньяга ашыру өчен көрәшәчәген әйтә. Әмма аның чыгышы «татар секциясе» тарафыннан каршылыкка очрый. Б. Шәрәф чыгышыннан соң шаулашып залдан чыгып китәләр. Кайберәүләр «Бу җыелыш махсус рәвештә бюро әгъзаларының мәнфәгатьләрен күздә тотып җыелган, бу тәртип бозу» кебек сүзләр сөйлиләр. Әмма бюро әгъзалары һәм Б. Шәрәф, солдатлар вәкиле Мәхмүт Таһиров җыелыштан чыгып китүчеләрне Вакытлы хөкүмәт иярченнәре дип атый, ә солдатларның бары тик 5 нче номерлы исемлектәгеләрне генә шәһәр сайлауларына яклап тавыш бирәчәкләре икрар ителә. Бу исә Борһан Шәрәфнең халык арасында зур абруй казануы хакында сөйли. Шәһәр думасында булып узган сайлауларның нәтиҗәсе дә әлеге хәлне ачык чагылдыра, бюро әгъзалары күпчелек тавыш алалар, 12 кеше сайлана: Фатих Кәрими, Борһан Шәрәф, Камил Кәримов, Гариф Мутин, Абубәкер Капкаев, Нургали Надиев, Сәгъди Мостафин, Галимҗан Букәйханов, Гаделша Мишкин, Габ-

делрәшит Фәхретдинов, Гарифулла Кащаев, Шәмбик Сакаев. Башка исемлекләрдән думага мөселманнардан тагын 8 кеше уза: Хәсән Мамин, Шаһимәрдән Еникеев, Кашаф Нуретдинов, Мөбәрәкша Ш., Ш. Абзгильдин, Мөдәрис Мостафин, М. Сыртланов, Ибраһим Ганиев[49].

Оренбург мөселман «Бюро»сы каршында пропаганда бүлеге эшли. Ул кагыйдә буларак атнага ике мәртәбә сәяси хәлләр турында аңлату эшләре башкара. Аны Хәйретдин Вәли җитәкли. Әлбәттә, бу эшләрдә Борһан Шәрәф үзәктә була.

Әлеге сайлау көннәрендә «Бюро» үзенең мөселманнарны берләштерү буенча зур көчкә ия булганлыгын күрсәтә. Соңыннан, 1918 елда Касыйм Туйбахтин үзенең чыгышларында: «Мөселман комитетлары, мөселман «Бюро»лары эш күрсәтә алмады»,— дип тәнкыйтьләве, безнеңчә, Оренбург мөселман «Бюро»сына бөтенләй кагылмый. Әлбәттә, Казандагы Мөселман комитеты (рәисе Ф. Туктаров) артык эш күрсәтә алмый. Әмма Казанның үзенчәлекләре бар. Алар аерым тукталуны таләп итәләр. Шуны да әйтеп узарга кирәк, Казанда июль аенда булып узган Бөтенрусия мөселман солдатлары съездында бу «Бюро»лар бетерелеп, алар урынына милли идарәләр кертелә»[50].

Шул ук вакытта Б. Шәрәф «Оренбург мөселман Бюросы хәбәрләре» дип аталган газетаның мөхәррире булып та эшли. Бу газетаның нибары 10 саны гына чыгып өлгерә. Билгеле булганча, газета битләрендә актуаль мәсьәләләр буенча мәкаләләр дөнья күрә. Шул ук вакытта Б. Шәрәф «Вакыт» газетасы белән дә бәйләнешен өзеп бетерми. 1917 елның апрель аенда Оренбург мөселман оешмалары аны Петроградка делегат итеп Бөтенрусия мөселманнарының киңәшмәсенә җибәрәләр. Монда төп мәсьәлә булып Бөтенрусия мөселманнарының гомуми мәҗлесен җыю мәсьәләсе тора. Шул ук вакытта булачак мәҗлеснең җыелу урыны, аның программасы һәм башка мәсьәләләр дә карала. Бу киңәшмә белән дәүләт думасының мөселманнар фракциясе җитәкчелек итә. Мәҗлестә шулай ук Муса Бигиев, Гаяз Исхакый һәм башка күренекле шәхесләр катнаша. Принципиаль мәсьәләләрне мәҗлес Мәскәүдә җыелачак Бөтенрусия мөселманнары мәҗлесенә калдыра. Б. Шәрәф әлеге киңәшмәдә үк: «Милли хәрәкәт икегә аерылып китүдән куркып эшләнелде»,— ди. Төрле партияләргә, группаларга бүленүдән курку табигый, әмма съезд уздырырлык хәзерлек булмавын искә алырга кирәк. Төрле партияләргә бүленү процессын актуаль мәсьәләләрне бер кырыйда калдырып торып кына бетереп булмый, чөнки бу объектив процесс. Бу

киңәшмәдә унитаристлар, федералистлар, социалистлар, монархистлар, большевиклар да була.

Әлеге киңәшмәдә булачак съездның ничәнче икәнлеген дә тәгаен генә ачыклый алмыйлар: берәүләр I съезд, ә икенчеләре, булган барлык мөселман съездларын искә алып, VI съезд дип атарга телиләр. «Мин үзем бу съездны соңгы, VI съезд дип атарга киңәш иттем, чөнки тиздән милли хәрәкәтнең партияләргә, төрле группаларга бүленәчәген алдан сизендем. Бу шулай булды да — аны тормыш үзе күрсәтте»[51],— ди Б. Шәрәф. Аның тәкъдиме кабул ителми һәм I Бөтенрусия мөселманнарының съездын май аенда Мәскәүдә уздырырга дигән карар кабул ителә.

Шулай итеп Думаның мөселман фракциясе инициативасы белән оештырылган киңәшмә 1917 елның 15—17 мартында съездны чакыру турында бик әһәмиятле карар чыгара.

Әлеге съезд Мәскәүдә 1917 елның 1—11 маенда булып уза. Көн тәртибендә 13 мәсьәлә каралырга тиеш була.

Беренчеләрдән булып хакимияткә мөнәсәбәт мәсьәләсе каралып, Вакытлы хөкүмәткә котлау телеграммасы да җибәрелә. Съезд шулай да хакимиятне Советларга бирү турында карар кабул итми.

Икенче мәсьәлә — милли дәүләтчелек мәсьәләсе. Аның буенча А. Т. Цаликов доклад ясый. Ул Русия мөселманнары өчен милли мәдәниятле автономиянең кулайрак икәнлеген исбат итәргә тырыша, «бу идеяне, икенче төрле итеп әйткәндә, әлеге вариантны тормышка ашыру өчен бөтен Русия мөселманнарының да бер булуы шарт»,— ди. Аныңча Русиянең барлык мөселманнары — бер милләт балалары. Икенче группа федерация идеясен алга сөрә. Федералистлар ягында Г. Ибраһимов, Г. Топчибашев, А. Рәсүл-задә, З. Досмөхәммәтов һ. б. була. Шулай итеп, милли дәүләтчелек мәсьәләсендә башлыча ике агым көрәшә: федералистлар һәм унитаристлар. Бу көрәш турында Б. Шәрәф болай ди: «Милли дәүләт төзү мәсьәләсендә мондагы ике агым федералистлар һәм унитаристлар. Кавказ буе республикалары һәм Урта Азия делегатлары федерация идеясен, ә эчке Русия һәм Себер вәкилләре унитаризм идеясен алга сөрәләр иде»[52],— ди. Б. Шәрәф һәм Оренбургтан килгән вәкилләр дә унитаристларга кушылалар. Аның «Мин ул чакта шундый фикердә идем, әгәр капиталистик системада, болай да артта калган дип исәпләнгән мөселман өлкәләренә федератив төзелеш тәкъдим итсәк, буржуазия моңа ике куллап риза булачак. Нәтиҗәдә урта гасырлар феодализмы урнашачак. Азиат халыкларында хөкем сөргән

феодаль законнарга караганда, Русиянең үзәктән чыгарылган законнары отышлырак, минемчә, бөтен милләт халыклары тигез хокуклыга әверелсә. Мөселман халыкларында да культура һәм хуҗалык эшләрендә алга китеш булачак. Социал-демократлар милли мәсьәләгә кагылышлы якларга игътибар иттеләр, чөнки әлегә кадәр пролетариатның ватаны да, милләте дә юк дип йөртелде. Безгә большевикларның милли политикасы мәгълүм түгел, бары халыкларның үз билгеләнү турындагы гомуми лозунгасы гына таныш», дигән фикере мәгълүм[53].

Уфада булып узган «Милли мәҗлестә» Борһан Шәрәф Оренбург мөселманнары делегаты буларак катнашып, Гаяз Исхакый, Фуат Туктаров, Зәки Вәлиди белән бергә мәдәниагарту «экстерриториаль автономия» идеясен яклап территориаль автономиягә (туфраклы мохтариятькә) каршы чыга. Ул: «Соңрак үзбилгеләнү практикада тормышка ашырыла башлагач (Финляндия, Кавказ буе республикалары, Урта Азия) мин шундый нәтиҗәгә килдем: вак милләтләр өчен Ленинның милли политикасы яраклы дип уйлаган идем. (Моңа бер Б. Шәрәф кенә алданмаган, Солтангалиев М., М. Вахитов h. б. да.— *Р. В.*) Төрле оешмаларда эшләү дәверендә (башкорт, татар институтларында, төрле-төрле түгәрәкләрдә, курсларда, политэкономия, гомумән, иҗтимагый фәннәр укытканда) Ленинның милли политикасын 1922 елга кадәр пропагандаладым. 1922 елны Казанга кайтып төшкәннән соң мин үземә карата совет, партия җитәкчеләре ягыннан бер төрле салкынлык сиздем»,— ди. Казанга кайтыр алдыннан, 1921 елда, махсус оештырылган 20 кешедән торган экспедиция белән ул Урта Азиягә барып кайта. Экспедиция составында шулай ук Фатих Кәрими, Зәки Ишаев, Нурмәд Вәлишев һәм башкалар булалар. Экспедиция белән Оренбург татар институтының директоры Надиев җитәкчелек итә.

Экспедициянең максаты — Урта Азиядәге укыту-агарту эшләрен өйрәнүдән гыйбарәт була. Алар Ташкент, Сәмәрканд, Бохара шәһәрләрендә булып, мәгариф комиссарлары Шәһид Әхмәдиев, Б. Булатов, Кара Юлдашлар белән очрашып укыту-агарту һәм башка мәсьәләләр буенча да фикер алышалар. Б. Шәрәф бу вакытта элеккеге дускаләмдәшләреннән «Бохара» газетасы мөхәррире Зыя Усманов, язучы Садретдин Айни һәм Зәки Вәлиди белән очраша. Экспедиция әгъзаларын Үзбәкстан Халык комиссарлары Советы рәисе Фәйзулла Ходжаев үзенең кабинетында кабул итә. Бу аның белән икенче тапкыр очрашу була. Беренче мәртәбә алар хәрби җитәкче Гариповта кунакта

очрашалар. Мәгариф министры янында алар булачак корылтай делегатлары белән әңгәмә коралар. Әлбәттә, үзәктә конституция кабул итү мәсьәләсе, Бохара республикасының РСФСР составына керү һәм башка проблемалар да карала. Үзбәкстан җитәкчеләре үтенече белән Борһан Шәрәф һәм Фатих Кәрими, Сөнгать Бикбулатов белән бергәләп Конституциянең проектын русчадан үзбәк теленә тәрҗемә итеп бирәләр. Экспедиция әгъзалары, шул исәптән Б. Шәрәф тә Үзбәкстан корылтаеның бер мәҗлесендә катнашу бәхетенә ирешәләр. Әлбәттә, бу аралашу үзара хезмәттәшлеккә кайтып кала.

Соңрак, 30 нчы еллар башында, Б. Шәрәф янә Ташкентка килеп, потребсоюзда бухгалтер булып эшли. Үзенең әйтүенә караганда, ул монда Оренбургта чакта бергә эшләгән Хөсәен Габделхәмид белән очраша, аның белән НЭП буенча фикер алыша, шулай ук тәрҗемәче Р. Сахи, Казан буенча танышы Х. Туляков белән аралаша. «Кызыл Үзбәкстан» газетасының мөхәррире Вәли Галимов белән дә очрашкалап тора. С. Рәхмәти аңа татар-үзбәк сүзлеге төзүнең кирәклеге турында әйтә, Муса Бигиевнең чит илгә качуы турында хәбәр итә. Б. Шәрәф: «Менә нинди жулик! Элек төрек, гарәп паспорты белән йөри иде чит илгә, ә хәзер паспортсыз гына киткән икән»,— ди. Шунда ук кылт итеп танышы Абдулла Сәгыйтовның сүзләре исенә төшә. Абдулла, Муса Бигиевнең (ул чынлап та эзәрлекләүләрдән туеп качкан. Татарлар арасында М. Бигиев ОГПУның Шәрекъ бүлеге хезмәткәре Петросян белән хезмәттәшлектә тора дигән сүзләр йөргән) чит илгә сәяхәте турында «Тагын шуны да истән чыгармаска кирәк, бу юлы аны ГПУ яңадан чит илгә командировкага паспортсыз гына җибәргәндер» дип фаразлый[54]. С. Рәхмәти: «Бик булыр! Ул барысын да булдыра»,— ди. Ихтимал, Б. Шәрәф өчен чит илгә китү «жуликлык», яисә кемгәдер хезмәт итү йөзеннән генә эшләнә торган эш кебек күренгәндер. Теләгән очракта ул да Урта Азиядә яшәр иде. Иске режимга каршы кыю көрәшче булып чыныкканнан соң, Борһанны кулга алулар, күзәтүләр белән куркытып буламы?! Дөрес, ул атылып урамга чыкмый, митинглар да оештырмый; тыныч кына эшли бирә, шул рәвешле кешеләрнең аңын уята, яңа фикерләр сала, ә тоталитар режим өчен моннан да хәтәррәк нәрсә бармы? Юк, әлбәттә.

Очрашулар, хәбәр алышулар, әлеге эшчәнлекнең бер формасы дисәк, ялгышмабыз. Бу аның Шакир Мөхәммәдьяров белән очрашып сөйләшүеннән дә ачык күренә. Ул аңа — мамык институтында эшләүче танышына

«Большевик» журналын күрсәтә, ә анда Шакирның мәктәптәш дусты Баймбетов турында сүз бара. Үзенең ЦИКта ясаган отчетында Е. Ярославский: «Баймбетов сәяси идеалларында ялгыштым дип саный, чөнки «югары»лар — партиялеләр дә, партиясезләр дә буржуаз гамәлләрдән чыгып яшиләр, аларның кеше кайгысында эшләре юк, дип исәпли»,— дип белдерә. Әлбәттә, мондый «башбаштак»ны партиядә калдырмыйлар.

Борһан, Баймбетов турындагы материал белән танышкач, көлемсерәп: «Баймбетов әкәмәт кеше бит ул, һәрвакыт «мөгез чыгарырга» ярата иде. Үзенең хәле турында «Большевик» журналында язып чыгулары белән дә горурлана гынадыр әле»,— ди. Моңа өстәп ул Гаяз Исхакыйның да чит илгә китүе, Архангельск төрмәсендә бергә утырган Пильсудский янында булуы хакында хәбәр итә.

Бу вакытта ул аерым кешеләр белән генә түгел, киң аудиторияләр белән дә очраша. 1930 елда, аерым алганда, Б. Шәрәф узып барышлый Ташкентта укытучылар өчен икътисади география буенча лекция укый.

1923 елда ул Оренбургтагы Шәрекъ пединститутында, башкорт педагогия техникумында һәм төрле курслардагы эшләрен ташлап Казанга кайтырга карар кыла. Гомумән, шушы елдан башлап Б. Шәрәф укыту-агарту эшләреннән бөтенләйгә аерыла. Ул Казанга кайткач шактый авырлыклар аша Наркомфинда оештыручы булып эшкә урнаша һәм анда беренче тапкыр үзенә карата салкын караш тоя, «артык кеше» булуын сизә. Казанда бу вакытта үзара төрле группалар көрәшә, әмма Б. Шәрәфнең аларның берсенә дә катнашасы килми, «мин алар белән бергә эш алып бару түгел, киресенчә, читләшергә тырыштым»,— ди. Әлбәттә, ул бу сүзләрне соңыннан, кулга алынгач әйтә. Ихтимал, бәлки ул уңнарга теләктәшлек күрсәткәндер, чөнки Б. Шәрәф һәрвакыт милләтне кайгырта. Ә ул вакытта уңнар милли мәсьәләләргә күбрәк игътибар бирәләр. Аның нәкъ шулай булуы турында энесе Галимҗан да әйтеп калдыра. Безнеңчә, Казанга кайту белән, мондый шомлы заманда, Б. Шәрәфнең ашыкмыйчарак эш итәргә теләве бик табигый. Шулай кирәк булганлыгын бүген без инде бик яхшы беләбез. 1923 елның 5 мартында бер агентның ЧКга җибәргән хатында да бу хәл ачык күренә. Яшертен грифлы бу документта «Иптәш Бузулуковка», ә астарак «Зәки Вәлидовка, 5 март, 1923 ел, Казан шәһәре» диелгән. Без аның авторын ачык кына әйтә алмыйбыз, чөнки аның кулы куелмаган; шул ук вакытта бу документ — копия. Әмма аны Шәрәфләрне якыннан белгән, алар белән аралашып яшәгән

кеше язган булырга тиеш, чөнки анда Шәрәфләрнең барысына да, хәтта ата-бабаларына да характеристика бирелгән. Әйтергә кирәк, бик яхшы белеп язылган характеристика.

Агент болай яза: «Миңа әле җиде-сигез яшь кенә иде. Менә шуннан бирле, балачагымнан ук мин бертуган Шәрәфләрне белә идем.

Оренбургта «Вакыт» газетасының элеккеге мөхәррире һәм нәшире Борһанетдин Шәрәф, ягъни безнеңчә әйткәндә Борһан Шәрәф, әлеге газетаның җаваплы мөхәррире Фатих Кәримов төрки-ислам идеологиясен матбугат аша уздыруга шактый көч куялар. Шуңа күрә Оренбург өлкәсендә Галимҗан ибне Баруди мулланың дәрәҗәсе үсте. Шул рәвешле ул Бөтенрусия мөселманнарының мөфтие итеп расланды.

Чит илдән, сөргеннән кайткан мулла Галимҗан ибне Баруди-Галиевны, аның идеологиясен яклаучылар күбәйде; алар йөзләрчә. Алар төрек-татар телендә күп кенә әдәби әсәрләр, газета-журналлар чыгарырга тотыналар. Үзләренең язу сәләтен һәм эшлекле икәнлекләрен күрсәтеп өлгерәләр... Барлык ир туганнары арасында да Шәрәф — иң күренеклесеедер. Дөрес шактый популяр һәм көчле рухлы Шәһер Шәрәфнең панисламист идеологиясен дә читләтеп узып булмый. Аннан соң инде Борһан Шәрәф, өченче — Гыйльметдин Шәрәф һәм Галимҗан Шәрәф, соңыннан, бишенче — Шиһабетдин Шәрәфне күрсәтергә булыр иде (Текстта ялгышлык киткән — Сәхабетдин дип язылган,— *Р. В.*)»[55].

Бу хаттагы мәгълүмат Шәрәфләргә карата махсус оешмаларның яшерен эш алып барганлыкларын ачык күрсәтә. Шулай итеп бер рапорт белән Борһанның киләчәгенә кара мөһер сугыла.

Әлеге еллар тотрыксыз чор иде. Большевиклар 1921 елда «Яңа икътисади сәясәт»не (НЭП) гамәлгә ашыра башлагач дөньялар үзгәреп, Б. Шәрәфнең дә тормышы азрак җанлана. Ул да большевикларның «НЭП чын мәгънәсендә һәм озакка хәл ителде» дигәннәренә ышаныч белән Казанга кайта. Башта Борһан китап сатуны яхшыртырга тели, ә аннан соң энеләре белән «Урман» дип аталган берләккә нигез сала. Шәрәфләр тарафыннан бу Совет хөкүмәтенең «Яңа икътисади сәясәт»ен тормышка ашыру һәм үзләренең дә көнкүрешен яхшыга үзгәртергә теләүнең ачык мисалы иде. Монда закон бозуларның эзе дә юк. Татарстан дәүләт архивы хезмәткәре Кочурова тарафыннан КГБның тикшерү бүлеге начальнигына 1957 елның 3 мартында әзерләп бирелгән белешмәдә мондый юллар бар: «1926 елдан башлап «Урман» союзы әгъзасы булып торган. Ул Кооперативный

урамында, 15 йортта урнашкан. Пайщиклар (совладельцы) 10 кеше. Бер еллык доходы 24.600 сум. 1927 елдан алып, иске һәм яңа кәгазьләр белән сату итүгә патенты бар... 1927 елның 1 октябреннән 1928 елның 30 сентябренә кадәр керем 3.340 сум.

1922 елда ул (Б. Шәрәф.— *Р. В.*) «Бродаран Шәрәф» (китап сату) әгъзасы. (Сенная урамы, йорт 27.) Өченче разрядлы патентлары бар. Сатуның әйләнеше... 1923/24 елның беренче яртысында 40.000 сум, икенче яртысында 30.000 сум. Сату буенча әйләнеш гомуми: 200.000 сум, 1.500.000 сум»[56].

Әйтергә кирәк, бу иптәшлек Наркомторг тарафыннан бирелгән документлар нигезендә оештырыла. Шул ук вакытта Б. Шәрәф биржа комитеты әгъзасы буларак, совет дәүләтенең сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә дә эшли, тырыша. Наркомторг аны ликвидкомның әгъзасы итеп тә раслый, ә беркадәр вакыттан соң Наркомторг аны күчмә бюроның сәркатибе итеп үзенә ала. Шул ук вакытта ул икътисадчы (экономист) ярдәмчесе вазифаларын да башкара. Әмма бу озакка сузылмый...

Б. Шәрәфнең әйтүенә караганда, элеккеге сатучының кинәт Наркомторг органнарында хезмәт итүе ят нәрсә була. Шулай, бервакыт сүз куерткända, дәүләт банкы хезмәткәре аны «Наркомторг купецы» дип игълан итә. Менә шуннан соң инде ул эштән китәргә мәҗбүр була. Шушы вакыйга алдыннан аны Наркомторгның урынбасары үзе янына чакырып ала һәм үз теләге белән эштән китүен таләп итә. Ул аңа: «Сез — элеккеге кеше»,— дип белдерә. Әмма Б. Шәрәф моны татарларга каршы поход дип саный, чөнки Наркомторгта «руслардан «элеккеләр» күп иде, аларга тимәделәр»,— ди.

1922—1923 елларда ук астыртын рәвештә Шәрәфләрнең барысына каршы һөҗүм башлана. Ачык рәвештә 1924 елда Б. Шәрәфне сайлауда катнашу хокукыннан мәхрүм итәләр, ә 1931 елда хәтта аның химия технология институтында укучы студент кызын — Сараны да, әтисе сатучы булган дип, сайлау хокукыннан мәхрүм итәләр. 20 нче елларның ахырында, ачыктан-ачык кулга алулар башлангач, Шиһап, Борһан, Гыйльметдин, Шәһер Шәрәфләр утлы табага баскан хәлдә калалар. Казанда «шәрәфизм» белән киң колачлы көрәш җәелдерелә... Аларның кайберләрен партиясезләрнең юлбашчысы итеп карыйлар.

Менә шундый катлаулы чорда Борһан, өметләр баглап, янә Ташкент якларына юлга чыга.

«АҢА МИНИМУМ БИРЕРГӘ»

Кемнәр генә, кая гына качмады ул елларда? Берәүләр чит илләргә: Кытайга, Америкага, хәтта Австралиягә киттеләр, икенчеләре исә Урта Азия якларына, Мәскәүдән ераграк, тынычрак почмакларга сыендылар. Тик Б. Шәрәф үзендә туган илдән бөтенләйгә аерылырлык көч тә, дәрт тә таба алмый. Урта Азияне үзенең туган якларыдай белгән Борһанда, Ташкентка килү юллары газаплы булса да, өметләр туа. Әлеге казах далаларында, Ташкент, Наманган якларында күпме кеше котылып кала?! Әмма ЧК иярченнәре тик ятмый, алар Шәрәфләрне бик җентекләп эзәрлеклиләр. 1932 елның 21 маенда Ташкент шәһәрендә Б. Шәрәф беренче тапкыр кулга алына. 20 көннән соң аны гаепләү кәгазе белән таныштыралар. Бу документка түбәндәгеләр язылган:

Карар
(Гаепләне фаш итү һәм чара күрү)

1932 елның 10 июне, көндезге сәгать. Ташкент шәһәре. Мин, Чепиго, Урта Азиядәге 00 САВО һәм ПП ОГПУның 4 нче бүлек оперуполномоченные, 3290 номерлы гаепләнүче Борһан Шәрәфкә тагылган гаепләүне игътибарда тотып, түбәндәгеләрне бәян итәм.

Борһан Шәрәф 1929 елның азагында Казаннан Ташкентка килә, максаты — Советка каршы элементлар белән ныклы элемтә урнаштыру. Ул аеруча интеллигенция арасыннан чыгучыларга игътибар итә, качак кулаклар, сәүдәгәрләр, татар һәм башкорт мөселманнарыннан 1930—1931 елларда революциягә каршы группа туплый. Бу хәл 1932 елның маена кадәр дәвам итә. Аның үз фатирында җыелалар, Совет властена каршы көрәшкә әзерләнәләр. Ерак Көнчыгыштагы вакыйгалар уңаеннан ул фикердәшләренә Япония белән СССР арасындагы сугышның кичектергесез икәнлеген әйтә. Бу сугышта Совет власте тар-мар ителәчәк, ди Борһан Шәрәф; шул рәвешле үзе тирәсендәге кешеләрнең рухын төшерә, шунлыктан түбәндәге карар әзерләнә:

Борһан Шәрәфкә 51 яшь, милләте — татар. Килеп чыгышы буенча Татарстан АССРның Буа районы, Аксу авылыннан. Аңа УК УЗ СССРның 67 нче маддәсе буенча гаеп тагыла. Тикшерү һәм судтан читләшкәне өчен аны кулга алырга. Урта Азиянең ПП ОГПУ ДРЗсына ябарга[57].

1932 елның 29 июнендә Борһан Шәрәфне әлеге документ белән таныштыралар һәм ул аңа ачык итеп яза, шунда ук аның кулы да куелган: «Миңа карар ирештерделәр, тик бу

җинаятьләрдә үземнең катнашым юк икәнлегенә ачыклык кертәм»,— диелгән.

Сораулар алу вакытында ул турыдан-туры тикшерүчеләргә үзенең фикерләрен әйтә, кайбер хаталары турында да җиткерә. «Иң зур хатам,— ди ул,— башкалар белән сөйләшкән чагында мин Совет дәүләтен тәнкыйть итә торган идем. Кагыйдә буларак ул тәнкыйть сүзләре патша хөкүмәте режимы белән көрәшкән өлкән буын вәкилләре белән очрашканда ычкына иде. Бу буын кешеләре үзләрен чагыштырмача иркен тоталар иде. Алар Совет дәүләтенең яшәешен кабул итмәсәләр дә, НЭП, шушы ирекле тормыш аларга шактый мөмкинлекләр ачты. «Советлар булсын; кешеләр өчен, хуҗалык итүдә кысулар булмаска тиеш, шулай ук көчләп кулакларны куулар, көчләп бер урыннан икенче урынга күчерүләрне булдырмыйча, колхозга керү өчен кирәкле чараларны күрергә — кирәк» диючеләр иде алар»[58].

Әмма Борһанның эше моның белән генә тәмамланмый. Урта Азиянең ОГПУ уполномоченные Гринберг 3290 номерлы эшне карап, СССР ЦИКы каршында Б. Шәрәфнең эшен карау срогын озайту турында үтенеч хаты яза. Нәтиҗәдә, А. Енукидзе тарафыннан Б. Шәрәфнең эшен карауны 10 октябрьгә кадәр озайтырга рөхсәт ителгән кәгазь килеп җитә. ОГПУ хезмәткәрләре дә тик ятмыйлар. Гринберг үз алдына яңа бурыч куя — Б. Шәрәфнең Урта Азиядәге «кыңгыр» эшен, аның элемтәләрен фаш итү, янәсе.

Тиздән сорау алулар да башлана. Б. Шәрәфкә әдәпле мәктәп укучысы кебек барысын да сөйләргә туры килә. Архив папкаларында аның тарафыннан язып калдырылган шактый гына кызыклы материаллар сакланып калган. Алар арасында Б. Шәрәфнең 1932 елның 3—5 августындагы күрсәтмәләре үзенә җәлеп итә. Бу документлардагы фикерләр бүгенге көн өчен дә кызыклы һәм гыйбрәтле, шуңа күрә без аларны архивтагыча, тулы килеш китерергә уйладык.

«1. Иң әүвәл,— дип яза ул,— Октябрь революциясенә кадәр минем аңлы тормышым — кыерсытылган, изелгән татар халкы язмышына битараф калмау иде. Мин әле ул чакта капиталистик системада калган дип исәпләнгән милләт өчен марксизм идеяләренең мәгънәсен аңлап бетермәгәнмен. Капитализмның югары үсеш стадиясеннән соң социализм тәгълиматлары җиңәчәк дип ышанганмын. Бу ялгыш минем үземнеке генә түгел, бик күпләр шулай ялгыш уйда булдылар. Әнә шулай уйланып, мин социалистик тәгълиматны ныклап өйрәнмәдем һәм аңлату эшләре дә алып бармадым.

2. Кыерсытылган халыклар арасындагы Социалистик

хәрәкәтне һәм аның мәгънәсен сизеп алгач та, Коммунистлар партиясе сафына кермәдем, сәяси аңымны үстерү өлкәсендә дә тырышмадым. Кыскасы, партиячел тәрбия алмадым.

3. Казанга кайткач татар группаларыннан читләштем, шулай да дөрес юлны эзләп газап чикмәдем, партиянең төп линиясеннән читләштем һәм НЭП сазлыгына кереп чумдым.

4. Сәяси аңым шул дәрәҗәдә генә булгач, партия үткәргән чараларда тәнкыйть сүзләре әйтергә дә тартынмадым. Үз-үземә таләпчән булмауданмы бу, белмим, югыйсә советча яшәргә теләп тә, үз дигәнебезчә ирешә алмыйбыз.

5. Черек либерализм идеяләре белән мавыгып, Советка каршы чыгышлар ясаган кайбер кешеләрне фаш итмәдем»[59].

Нәтиҗәдә яңа документ пәйда була. Анда тоткын турында болай диелә: «Борһан Шәрәф үз тирәсенә Совет властена каршы эш алып баручы татар-үзбәк интеллигенциясен туплады; элек тә аларның эшчәнлеге бер-берсенә тыгыз бәйләнгән булса, хәзер дә шулай. Эмиграциядәге кешеләр белән дә хәбәрләшеп яшиләр.

Борһан Шәрәф тарафыннан төзелгән группа ачык рәвештә үзен Совет власте тарафыннан кыерсытылды дип исәпли. Аларга партиянең үткәргән чаралары, кулак-мунтагайны эзәрлекләүләре ошамый. Тикшерү барышында ачыкланганча, Б. Ш. 1929 елның азагында Ташкентка килеп, анда яшәүче татарлар белән элемтәсен яңарта. Үзбәк әдәбиятчылары белән якыннан аралаша. Ерак Көнчыгышта хәлләр куерган чакта 15 кешедән торган татар-үзбәк интеллигенциясе милли төркем булып оеша. Дөрес, рәсми рәвештә бу төркем игълан ителми, ә менә Советлар Союзында хәлләр кирегә үзгәреп китсә, бик тиз генә берләшеп куячаклар.

Әгәр капиталистик дәүләтләр һөҗүм итсә, Совет власте өчен гадәттән тыш авыр шартлар туса... буржуаз республика яңадан үз хәленә кайта калса, Совет властена каршы көрәшкә тупланган әлеге группа бик тиз рәсмиләштерелер иде».

Язмаларның авторлары Чеботарев, Димантеман Б. Шәрәфнең эшен махсус киңәшмәгә тапшырырга дигән карар да кабул итәләр. 1932 елның 4 декабрендә 1078 нче номерлы эш махсус киңәшмәгә җибәрелә. Шунысы кызыклы: документлар тутырылган папканың тышына кемдер карандаш белән «И. Алмаев, минимумга кадәр эшләргә» дип язып куйган. Нәтиҗәдә, Б. Шәрәф өч елга хезмәт белән

төзәтү лагерена (ИТЛ) хөкем ителә һәм Карагандага озатыла.

Менә шулай итеп, Ташкент эпопеясы тәмамлана. Әле аның беренче кулга алынуы, беренче тапкыр лагерьлар белән танышуы. Алда исә аны яңа кулга алынулар, нахакка рәнҗетелүләр, кыйналулар, үлем җәзасы көтеп тора. Үзенең дә йөрәге нидер сизенә, шулай да күңеле нәрсәгәдер ышана, өметләнә...

5815 нче НОМЕРЛЫ ЭШ

Караганда лагерьларында беркадәр «төзәлеп», вакытын тутырып, Б. Шәрәф Казанга кайтып төшә. Монда азрак вакыт узганнан соң шактый авырлыклар белән «Электропром»да монтаж бюросында статист булып урнаша. Ул инде ректә дә тыныч күңел белән яши алмый, бөтен абыйэнеләренең, якын дусларының кулга алынуы хакында белә. Һәркөн яңадан кулга алынудан шикләнеп яшәгән татар зыялыларының һәркайсы өчен бик авыр, күңелсез көннәр була бу. Борһан бөтен тәне, күңеле белән гаделсезлекнең хакимлеген тоеп яши. Шулай булса да фикер йөртүдән туктамый, алай гына да түгел, тоталитар режимның нәрсә икәнлеген ачыктан-ачык әйтә килә. Патша хөкүмәте, Вакытлы хөкүмәт белән аяусыз көрәш алып барган Борһан Шәрәфнең статист булып кына калырга теләмәгәнлеге безгә мәгълүм. Газета-журналлардан, китаплар язудан, хәтта гарәпчә укудан да мәхрүм ителгән татар зыялысына тагын ни кала: кайда мөмкин шунда эчен бушатырга, яисә бөтенләй телсез калып яшәргә. Мондый тормыш белән Б. Шәрәф холкы килешә алмый — ул язарга, укырга, сөйләргә тиеш. Аның бар теләге шул — ничек кенә булса да кешеләрнең «күзен ачу». Борһан Шәрәф үзе дә язучы, журналист. Караганда каторгаларында өч ел гомерен уздырып Казанга кайтып төшкәндә, Казан халкының үзенең хәле дә бик мөшкел була.

1923 елның 9—12 июнендә Мәскәүдә яшерен рәвештә РКП ҮК тарафыннан уздырылган IV киңәшмәдән соң[60] Мирсәет Солтангалиев һәм аның хезмәттәшләре, дуслары, туганнары, ә тора-бара бөтен татар зыялылары, хәтта Сталинның, партиянең ялагайлары, шулар белән беррәттән башкорт зыялылары, Урта Азиядәге фикер ияләре өчен кыямәт көннәре башлана. Күп очракта бу афәтнең үзәге булып Казан кала. Мәскәү киңәшмәсенең материаллары 1923 елның 19 июлендә Казанда, өлкә комитетының махсус

киңәшмәсендә карала, «оештыру эшләре» буенча төрле-төрле чаралар күрелә башлый. Бу киңәшмәдә Живов, Мөслимов, Нигъмәтҗанов, Чанышев, Усманов, Әхмәдиев, Ганиев, Рәхмәтуллин, Габидуллин, Вәлидов, Фәсхетдинов, Якупов, Мансуров, Енбаев, Николаев, Шәймәрданов, Галл, Кручев, Бренштейн, Ибраһимов, Шварц, Бикчәнтәев, Ендаков, Блудау, Бурундуков, Сабиров, Палютин, Кальченко, Башкиров (Буа шәһәре), Новиков, Семенов һәм Камалетдинов чыгыш ясап, махсус резолюция кабул ителә. Бу резолюциядә Солтангалиев эшенә карата: «Киңәшмә карарларын тулысы белән хупларга, Солтангалиевнең җинаятьчел эшен фаш итәргә һәм ТАССРның бөтен коммунистларын Солтангалиевчеләр сөременнән, милләтчелектән аралау өчен көрәшкә тупларга, үзебезнең төпле пролетар элементлар арасыннан интернациональ кадрлар үстерүгә игътибарны юнәлтергә, меньшевистик-буржуаз милләтчеләргә каршы көрәшергә, милли тигезсезлекне бетерергә»,— диелә. Шунда ук махсус комиссия дә төзелә. Аның составына Шварц, Мохтаров, Әхмәдиев, Бурундуков, Сәгыйдуллин һәм Әхмәтшин кертелә. Киңәшмәнең ахырында В. И. Ленинның «данлыклы булышчысы ип. Сталинга» телеграммасы да юллана, анда «бүгенге көннән башлап (Татарстанда.— *Р. В.*) «уңнар» да «суллар» да булмаячак, ә бары тик «бердәм әгъзалар» булачак» диелә[61]. Икенче төрле итеп әйткәндә, «син яшәсәң, безгә рәхәт, мәңге яшә Сталин» шигаре.

Көрәш яңадан куера башлый. 1930 елда ул тагын бер баскычка күтәрелә. Шул ук елда Казанда Уфа шәһәре белән тыгыз бәйләнештә торган «контрреволюцион» әдәби оешма «Җидегән» һәм шулай ук педагогия институтында Газыйм Касыймов җитәкчелегендәге «контрлар оешмасы» «фаш ителә». Әлеге вакыйгаларның дәвамы булып 1937 елгы дәһшәтләр килеп кушыла. Казанда көн саен диярлек партия җыелышларында, газета-журнал битләрендә «фаш ителү»ләр, кулга алулар, кешеләрнең югалулары кагыйдәгә әверелә. Кыскасы, Б. Шәрәф, образлы итеп әйткәндә, «шпионнар, диверсантлар, яшерен идән асты контрреволюцион оешмалар, троцкийчылар, солтангалиевчеләр, милләтчеләр мыжгып торган» Казанга кайтып төшә.

Татарстан өлкә комитеты секретаре Разумов җитәкчелегендә Үзәкнең теләсә нинди күрсәтмәләрен тормышка ашыру өчен барысы да эшләнә. Ул бөтен көчен татар әдәбиятын примитив әдәбиятка әйләндерүгә юнәлдерә. Бу гамәл эшче образын калку итеп күрсәтүгә ашкынудан гыйбарәт. Шул максаттан чыгып, 1930 елда «Атака» журналы чыгарыла башлый. Аның мөхәррире итеп Кави Нәҗми билгеләнә.

Шәрәфетдин белән Гайнелнәвал (әти-әниләре) һәм уллары Гыйльметдин. 1909 ел.

Утырганнар: Зыя Булатов һәм Зифа Шәрәф, уллары Хәмзә һәм кызлары Наҗия. Баскан — Шәһер Шәрәф. 1910 ел.

Халисә Шәрәфкә 1910 елда бирелгән шаһадәтнамә.

Свидѣтельство.

№ Канцелярия Инспектора Училищ

Предъявительница сего, дочь крестьянина Халиса Шарафутдиновна Шарафъ въ теченіи 2 лѣтъ обучалась въ Казанской школѣ для обученія татарскихъ дѣвочекъ Министерства Народн. Просвѣщенія мусульманскому вѣроученію, русской грамотѣ (чтенію, письму и ариѳметикѣ) и рукодѣлію и въ 1910 году, успѣшно выдержавъ установленное испытаніе, окончила курсъ указанной начальной школы 20 августа 1910 г.

Инспекторъ нар. училищъ г. Казани [illegible]

Почетная Блюстительница

Учительница Л. Фейзъ-Ханова *Вѣроучительница* Музаффарова

Халисә Шәрәф (Галимҗан Шәрәфнең сеңлесе) тугыз яшендә. 1908 ел.



Гыйльметдин Шәрәф хатыны Рәхимә белән. 1910 ел.

Ильяс Алкин — реаль училище укучысы (Б. Солтанбековның «Сталин и «татарский след» (1995) китабыннан).

Галимҗан Шәрәф — реаль училище укучысы.

Галимҗан Шәрәф (уңда) студент дуслары белән.



Галимҗан Шәрәф. Реаль училище-да укыган еллары.

КАЗАНЬ.
Въ пятницу, 1-го марта (н. с.) 1918 г. въ 3 ч. дня
НА ТЕАТРАЛЬНОЙ ПЛОЩАДИ
имѣетъ быть
ТОРЖЕСТВЕННОЕ ПРОВОЗГЛАШЕНІЕ
ФЕРМАНА (Универсала)
ОБЪЯВЛЕНІЯ АВТОНОМІИ
ИДЭЛЬ-УРАЛЬСКОЙ
РЕСПУБЛИКИ
какъ федеративной части Россійской Совѣтской
Рабоче-крестьянской республики.
ГРАЖДАНЕ—русскіе, чуваши, черемисы, евреи и др. народы! На нашемъ знамени написано братство народовъ—въ этотъ историческій день подайте намъ братскую руку.
ГРАЖДАНЕ! Ознаменуйте этотъ историческій день.

Идел-Урал республикасы мөхтарияте игълан ителү (Б. Солтанбековның «Сталин и «татарский след» (1995) китабыннан).

Шәһер Шәрәф хатыны Фатыйма белән. 1918 ел.

Шиһап Шәрәф гаиләсе. 1920 ел.

Әниләре Гайнелнәвал оныгы (Борһан Шәрәфнең олы кызы) Сара белән. 1923 ел.

Шиһап Шәрәф кызы Фәйрүзә белән. 1923 ел.



Шәһер Шәрәф кызы Асия белән. 1923 ел.

Галимҗан Шәрәф хатыны Әсма белән. 1925 ел.



Галимҗан Шәрәф эксперименталь фонетика лабораториясендә. 30 нчы еллар башы.

Татарстанның Галимҗан Шәрәф тарафыннан төзелгән этнографик картасы.

ЕСКОЙ РЕСПУБЛИКИ.
Масштаб 20 километров в дюйме (18,7477 или 18¾ версты)
С.
Агрыз
Елабужская
Елабуга
Челны
Бугульма
Ю

Галимҗан Шәрәфнең төрки халыкларда латин шрифты кертү мәсьәләләренә багышланган хезмәтенең тышлыгы. 1926 ел.


ГАЛИМДЖАН ШАРАФ

К ВОПРОСУ
О ПРИНЯТИИ ДЛЯ ТЮРКСКИХ НАРОДНОСТЕЙ
ЛАТИНСКОГО ШРИФТА



Халисә һәм Кәрим Сәгыйтовлар кызлары Энҗе һәм уллары Җанбак белән. 1926 ел.



Гыйльметдин Шәрәф хатыны Рәхимә, кызы Шәфика һәм улы Үзбәк белән. 1928 ел.

Борһан Шәрәф хатыны Закирә Кәримова-Шәрәф белән. 1927 ел.

Риза Шәрәф (Шиһап Шәрәфнең улы) хатыны Рабига белән. 1935 ел.



Борһан Шәрәф хатыны Закирә һәм кызы Рауза белән. 1935 ел.



ПОСТАНОВЛЕНИЕ.

1924 года, июля 14 дня, Я, Уполномоченный III-го Спец Отделения СОЧ Татотдела ОГПУ - ТЕРЕГУЛОВ, рассмотрев агентурный материал о контр-революционной подпольной организации татар "УЧАК" - НАШЕЛ:

Татарская контр-революционная организация "УЧАК" была организована в 1913-15 г.г. в Петрограде татарским студенчеством, организаторами коей являлись: Илиас АЛКИН, Галимджан ШАРАФ, Гени АББЯСОВ, Усман АКЧУРИН, Галей Рахим, Саид ЕНГАЛЫШЕВ и - что данная организация продолжает до настоящее время функционировать нелегально в Казани и куда примыкают ряд ответственных советских работников татар с националистическим уклоном, потому - ПОСТАНОВИЛ:

Производство дела " УЧАК" признать агентурным и продолжать его под кличкой " НАЦИОНАЛИСТ".

УПОЛНОМОЧЕННЫЙ

СОГЛАСЕН: НАЧАЛЬНИК ОТДЕЛЕНИЯ

УТВЕРЖДАЮ: ВРИОВ. Н А Ч С О Ч

«Учак» оешмасына карата кузгатылган җинаять эшен тикшерүне дәвам итү турындагы карар.



Галимҗан Шәрәф — НКВД тоткыны. 1937 ел.

Гыйльметдин Шәрәф — НКВД тоткыны. 1938 ел.



Садри Вәлитов (Җәләл) — НКВД тоткыны.

Ильяс Алкин — НКВД тоткыны. 1937 ел (Б. Солтанбековның «Сталин и «татарский след» (1995) китабыннан).



Гали Габдрәхимов — НКВД тоткыны.

Нәвар Шәрәф-Ганиева (Шәһер Шәрәфнең кызы). 1937 ел.

Сания Шәрәф (Шәһер Шәрәфнең кызы). 1949 ел.



Нәвар Шәрәф-Ганиева ире Әхмәтхан Ганиев белән. 1959 ел.

Сания Акҗитова ире Ибраһим Акҗитов белән. 1960 ел.

Әсма Шәрәф (Галимҗан Шәрәфнең хатыны) улы Арслан Шәрәф белән. 1987 ел.

Татар телендә чыккан бөтен газета-журналларга һәм матур әдәбиятка һөҗүм көчәйтелә. Бу өлкәдә бигрәк тә «Чаян» журналы активлык күрсәтә. Партия өлкә комитеты секретаре Разумов матбугатта, пленум-конференцияләрдә даими рәвештә татар әдәбияты мәсьәләләрен (үзе татарча укый белмәсә дә.— *Р. В.*) кузгатып тора. Аның чыгышларында төп ике тезис ярылып ята: 1. Үткәндәге әдәби мирасны (Г. Тукай, Дәрдмәнд һ. б.) бастырып чыгарганда марксистик күзлектән чыгып эш итәргә; 2. Татар язучылары арасында эшче-крестьян катлавыннан чыгучылар санын күбәйтергә.

Ике тезиста да бик күп кенә мәсьәләләр ачыкланмаган хәлдә кала. Тукай, Дәрдмәнд әсәрләрен бастырганда марксистик күзлектән карау төгәл генә нәрсәне аңлата? Әдәбиятка эшчеләр, крестьяннар түгел, бары тик иҗат итәргә сәләтле булган, талантлы кешеләр генә килергә тиеш бит?! Разумов анысына кагылмый. «Әдәбиятка — эшчеләр!» лозунгы матбугат битләрендә үзен сиздерә. Дәрдмәнд, Тукай, Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Кәрим, Г. Исхакыйлар тудырган нәфис әдәбият урынына тупаслык һәм сыйфатсызлык кереп тула. Әлеге шартларда татар язучылары арасында «контрреволюцион» «Җидегән» турындагы хәбәрләр тарала[62]. Утызынчы елларның ахырында, бигрәк тә 1936—1937 елларда «Җидегән» мәсьәләсе аерым язучыларга кизәнү өчен күсәк ролен уйный, чөнки «җиденче»не эзәрлекләү еллар буе дәвам итә. Менә архивлардан алынган бер дәлил. 1937 елның 25 июлендә Мөхәммәтҗановның «бик яшертен» грифы астында «Ип. Ельшинга» дип җибәрелгән язмасында: 1. «НКВД архивларында язучыларның контрреволюцион оешмасы «Җидегән» эшен актарып табуыгызны һәм, анда катнашучылар хакындагы материалларны файдаланып, кирәкле белешмә төзеп бирүегезне үтенәм. Шул ук вакытта аларга нинди чаралар күрелүен дә күрсәтегез; 2. Язучы Кәрим Тинчуринга караган материалларны да җыеп бирүегезне үтенәм», диелә. Бу — өлкә комитетының идеология секретаре язган хат[63]. Әлеге эшләрнең НКВД белән берлектә эшләнгәнлеге дә бик мәгълүм. Нәкъ шушы «язу» дөньяга килер алдыннан гына Казанда берничә язучыдан, дәүләт эшлеклеләреннән НКВД хезмәткәрләре сорау алу үткәрәләр. Мәсәлән, 1937 елның 3 һәм 8 июлендә Борһан Сафадан, 4 июльдә Шамил Усмановтан һәм Фатыйх Сәйфидән сорау алалар. Бу исемлектә шулай ук Исхак Рәхмәтуллин, Г. Баһаветдинов, Хафиз Палютин, Зәки Гыймранов, Вәли Шәфигуллин, Исхак Казаков, Миңгәрәй Сәгыйдуллин, Сәлах Атнагулов, С. Мортазина һәм Газыйм

Касыймов та бар. 8 июль көнне Борһан Сафаны Гомәр Әлмөхәммәдов белән күзгә-күз очраштылар.

Әлеге вакыйгаларны Татарстан өлкә комитетының 1930 елда киң колачлап башлап җибәргән «хезмәтләренең җимеше» дип карау урынлы булыр. Ул — алдынгы фикер йөртүче татар-башкорт зыялыларына карата мәрхәмәтсез сәясәтнең нәтиҗәседер[64].

Әлбәттә, татар язучыларын бер Татарстанда гына эзәрлекләмәделәр, аларга бөтен Русиядә дә урын калмаган иде. Эзәрлекләүләргә шулай ук Уфа, Мәскәү, Ленинград һ. б. шәһәрләрдә яшәүче язучылар һәм зыялылар да дучар булдылар.

Шундыйларның берсе — үз вакытында бертуган Шәрәфләр белән аралашкан, татарның шөһрәт казанган талантлы язучысы Мәхмүд Галәү. Аңа карата булган мөгамәлә әлеге вакыйгаларга кадәр үк үзгәрә, «Иван баҗай» дигән пьесасы тәнкыйтьләнә, ә «Канлы тамчылар» исемле романын нәшер итүдә каршылыклар килеп туа. Хәтта Г. Гали, Ш. Усманов, С. Җәләл, А. Әхмәдиев, М. Максудовларның рецензияләре дә искә алынмый. Шамил Усманов бу әсәрләргә югары бәя биреп: «Бу революцион рухтагы роман буларак аяусыз сыйнфый көрәшнең эчтәлеген төпле итеп күрсәткән әсәр»[65], — дип яза. Шулай булуга да карамастан язучыга карата субъектив карашлар өскә чыга. 1929 елда Татиздат тарафыннан кабул ителгән әсәре төрле сәбәпләр белән планга кертелми, ә язучы матди яктан бик авыр хәлдә кала. Аның Татарстан өлкә комитетына язган хатында түбәндәге юллар бар: «Көчкә-көчкә ач хәлемдә әдәби гонорарларга яшим... Менә инде мин ничә ел дәверендә ниндидер серле һәм сихри божра эчендә яшим кебек. Бөтен җаваплы хезмәткәрләр мине әйләнеп узарга телиләр сыман, алар мине язучы буларак ачык рәвештә инкарь итәләр... Менә инде мин җиденче ел бер социаль роман өстендә эшлим. Романның каралама варианты бөтенләй тәмамланган, ә беренче томы «Канлы тамчылар» исеме белән, күләме 25 табак, күптән нәшер итәргә әзер... Әмма баш редактор Әхмәд Фәрхи, рецензентларның фикере белән санашмыйча нәшер итүгә кабул итүдән баш тартты... Шулай да мин эшемне дәвам итәм һәм ач торам диярлек»[66].

Бәхетсезлеккә каршы, аның язмышы тора-бара тагын да кыенлаша. Безгә мәгълүм булганча, ул 1937 елның 9 апрелендә НКВД хезмәткәрләре Ачаклян һәм Адарчук кулына килеп эләгә. Алар бертуктаусыз аннан «идән асты контрреволюцион оешманың әгъзасы» буларак сораулар алалар.

«*Сорау:* Сез кайчан, кайда, нинди шартларда Совет властена каршы эшләүче оешмага кушылдыгыз?

Җавап: 1925 елның көзендә Фатих Кәримов Оренбургтан Мәскәүгә килгәч, Ишмаметов Хафиз (үлде) фатирында. Кәримов һәм мин пантюркистик уйларымнан баш тартмадым. Ул: «Шушы эшне дәвам итү өчен Мәскәү пантюркистлар оешмасының ячейкасын төзергә кирәк, ә аның үзәге Казанда»,— диде.

Сорау: Сезнең пантюркистик оешмагыз нинди максат һәм мәсьәләләр куя?

Җавап: Пантюркизм оешмасының төп максаты — Совет хакимиятен җимерү. СССРның төрек-татар милли республикаларында һәм өлкәләрендә Төркия протектораты астында пантюркистик дәүләт төзү. 1926—33 еллар дәверендә безнең оешма төрле мөмкинлекләрдән файдаланып, агитация-пропаганда эшләре алып барды. Мәсәлән, мин үзем «Моһаҗирлар» дип аталган китабымда пантюркизмны тәнкыйть иткән булып, әдәби герой аша пантюркизм идеяләрен мактадым...»

Аның тарафыннан Татарстандагы төркемнәргә бирелгән характеристика да кызыклы. (Әлбәттә, монда сүз әдәби төркемнәр турында гына бармый.) Ул аларны өч өлешкә бүлә. Аның уйлавынча, беренчесе Галимҗан Ибраһимов җитәкчелек иткән «сул» эсерлар төркеме. Анда, М. Галәү фикеренчә, Зәки Мөхсинов, Сәлах Атнагулов, Борһан Сафа, Гомәр Әльмиев, Ризванов, Гафуров, Муса Йосыпов, Исхак Рәхмәтуллин, Г. Нигъмәти, Исхак Еникеев, Зәки Гыймранов керә. Икенчесе — Мингәрәй Сәгыйдуллин төркеме. Монда Хөсәен Терпищев, Шамил Усманов, Азанова (Сәгыйдуллинның хатыны), Галимҗан Әминев, Шаһиәхмәтов керә. Өченчесе — Толымбайский төркеме. Монда Гомәр Гали, Гомәр Шаһиәхмәтов (Толымбайский), Кави Нәҗми, Риза Ишморат, Хәсән Туфан, Фатих Кәрим (яшь шагыйрь), М. Әмиров, Салих Баттал (Мәскәү шәһәре), Фәтхи Бурнаш, Кирьянов һәм Ф. Сәйфи керә. Бу төркем, аның уйлавынча, өлкә комитеты секретаре Абдуллин канаты астында эшләгән. Әлбәттә, бу НКВД агентларына яхшы гына «табыш» булгандыр. Мондый «табыш»ны тоткыннардан бары тик каты җәза, куркытулар һ. б. алымнар белән алынганлыгы безгә мәгълүм. Агымдагы эшләргә боларның йогынтысы гаять зур булган. Шушы ук сорау алу вакытында М. Галәү Салих Баттал тарафыннан Хәсән Туфанның «Ант» поэмасына югары бәя бирелгәнлеген дә искә төшерә.

Галимҗан һәм Борһан Шәрәфләргә карата түбәндәге сорау һәм җавап бирелә:

«Сорау: Мәскәүдә, Казанда, Уфада сезнең пантюркистик оешмагызга кемнәр керә иде?

Җавап: Безнең пантюркистик оешманың үзәге Казанда иде. Башлыча ул партиясез Казан зыялыларыннан тора. Аның юлбашчысы Казан вузларының профессоры Галимҗан Шәрәф иде. Оешма әгъзаларыннан журналист Борһан Шәрәф, Тарихчы Гали Абдрахманов (Гали Рәхим), Кәрим Тинчурин... Тинчурин безнең оешманың әгъзасы буларак Г. Шәрәф, Б. Шәрәф, Заһид Норкин һәм Абдрахмановлар белән тыгыз элемтәдә тора иде»[67].

Менә шулай итеп, әле кулга да алынмаган Б. Шәрәфкә һәм инде тугыз ай дәверендә Казан төрмәсендә интегүче Г. Шәрәфкә карата яңадан-яңа мәгълүматлар килә һәм алар «җинаять эшләре»нә теркәләләр. НКВД хезмәткәрләре зур «уңышка» ирешә. Алар алдынгы дип исәпләнгән тоталитар режим алдында тезләрен чүкми кыю фикер йөрткән ир-егетләрне зинданнарга урнаштырып, аларның милләткә, кешелек дөньясына булган ышанычларын сындырырга омтылалар. Барысы да бер калыпка салына — әлеге шәхесләр «милләтчеләр, контрреволюцион милли оешма әгъзалары, Германия шпионнары» сыйфатында төрлесе төрлечә хөкемгә тартылалар.

Мәгълүм булганча, И. Сталин нәкъ менә 1937 елда яңа концепция төзи. Аның фикеренчә, социализмга барган саен сыйныфлар көрәше көчәя, кискенләшә бара икән. Мәсьәләнең болай куелуы Берия, Ежов кебек авантюристларга бик кулай була. Шуннан файдаланып алар репрессияләрне тагын да көчәйтәләр. Татарстандагы хәлләргә килгәндә, монда да Г. Маленков һәм Л. Каганович үз өлешләрен кертәләр. 1937 елның августында партиянең Татарстан өлкә комитеты пленумы була. Менә шушы пленумга Маленков җитәкчелегендә бер группа килеп, ул репрессия эшләрен киң җәелдереп җибәрә. Үзенең чыгышында Маленков репрессияләрнең кирәклеген әйтә. Нәтиҗәдә, бик күп коммунистлар, совет хезмәткәрләре, партиясезләр дә, шул исәптән өлкә комитеты секретаре А. Лепа, Татцик рәисе Г. Байчурин, ТАССР Халык Комиссарлары Советы рәисләре К. Абрамов, Н. Дәүләтьяров, аларның урынбасарлары А. Хәкимов һәм А. Новоселов, райком секретарьлары Р. Ю. Алкин, З. Г. Гильметдинов, З. А. Баскин, Г. Н. Тикк, язучылар Г. Ибраһимов, К. Тинчурин һ. б. кулга алына. Кагановичның күрсәтмәсе буенча әлеге исемлеккә Казан тимер юлы начальнигы һәм башкалар да өстәлә[68]. Казан тимер юлы, янәсе, япон шпионнары кулында икән. И. Сталин, Г. Маленков, Л. Кагановичларның яңа ялчысы Александр Алемасов партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре булгач, республикадагы хәлләр тагын да

кискенләшә. Шул чорда өлкә комитетында эшләгән һәм шулай ук репрессиягә эләккән А. Тарасов болай ди: «1937 елда Татарстан партия оешмасын тар-мар итүдә Маленков зур өлеш кертте... Маленков Казаннан киткәннән соң Алемасов республикада каты террор режимы урнаштырды, меңләгән коммунистлар кулга алынып юк ителде»[69].

Казанга кайтып бер ел эшләү дәверендә Б. Шәрәфнең хәлләре тагын кыенлаша, аны төрмә сагалый. 1937 елның 27 декабрендә аның фатирына НКВД хезмәткәре килеп, 366 нчы номерлы ордер күрсәтеп, фатирның астын-өскә китереп тентү ясый. Шулай итеп, Б. Шәрәфне янәдән кулга алалар. Ул инде тагын «җинаятьче» булып санала. Беренче көнне үк Ивин һәм каты куллы Әхмәтов сорау алалар. Тагын шуны да әйтеп китәргә кирәк: шул ук Әхмәтов, параллель рәвештә, Борһанның туганы Галимҗан Шәрәфтән дә сорау алган. Мәсәлән, Борһанны кулга алыр алдыннан гына ул 19 һәм 20 декабрьдә, шулай ук 3, 8, 9, 14, 17, 18, 20 январьда Г. Шәрәфтән сорау ала. Г. Шәрәф «Татар учагы», Милли мәҗлес, «уңнар» һәм «суллар» көрәшен, «82»ләрнең хатын әзерләшеп бирүен тасвирлый, әмма Б. Шәрәф һәм башкалар турында бер сүз дә әйтми.

Б. Шәрәфтән сорау алу түбәндәгечә бара:

«*Сорау:* Сезнең бертуган абый-энеләрегез бармы, алар хәзер кайда? (Әйтерсең лә үзе белми.— *Р. В.*)

Җавап: Без биш бертуган, барыбыз да Өчлек тарафыннан хөкемгә тартылдык, хәзер барыбыз да тоткынлыкта.

Сорау: Сез соңгы көннәргә кадәр панисламистлар, милләтчеләр агымына тартылгансыз, бу тикшерү барышында билгеле. Сез моны раслыйсызмы?

Җавап: Юк расламыйм. Минем беркайчан да панисламист булганым юк.

Сорау: 1923 елдан 1932 елга кадәр сез СССРның төрле районнарында спекуляция белән шөгыльләнгәнсез, бу тикшерү барышында ачыкланды. Әлеге сорау буенча күрсәтмәләр бирегез!

Җавап: Спекуляция белән шөгыльләнмәдем, әмма раслыйм: мин ачык рәвештә эш кылдым, моңа минем патентым бар иде...

Сорау: Кем ул Фатих Кәримов?

Җавап: Фатих Кәримов миңа туган туры килә. Ул минем хатынымның абыйсы.

Сорау: Фатих Кәримовның күренекле пантюркист икәнлеге, аның белән бергә сезнең дә берөзлексез революциягә каршы пантюркистлар хәрәкәте белән бәйләнештә булып, бу хәрәкәткә кушылуыгыз мәгълүм. Боларны сез раслыйсызмы?

Җавап: Фатих Кәримов белән тыгыз бәйләнештә булуымны раслыйм, мин аның белән туганнарча бәйләнештә идем, әмма ул да, мин дә бернинди пантюркистлар хәрәкәтендә дә катнашмадык.

Сорау: Сез дөрес күрсәтмәләр бирмисез, сез революциягә каршы милли пантюркистлар агымына кушылу гына түгел, ә пантюркизм идеясен пропагандалагансыз. Менә шушы эшләрне башкару өчен төрле-төрле элемтәләргә дә кергәнсез. Менә шулар турында күрсәтмәләр бирегез!

Җавап: Мин моны катгый рәвештә кире кагам.

Сорау: Сез Татарстанның һәм Башкортстанның кайсы эре милләтчеләрен беләсез һәм кайсылары белән элемтәдә торасыз?

Җавап: Мин эре милләтчеләрдән Һ. Атласов, Г. Исхаков, Корбангалиев, М. Солтангалиев турында хәбәрлемен. Гаяз Исхаковны якыннан, ә башкаларын газеталардан, аларның хезмәтләре аша гына белә идем. Алар үз эшләрен еллар дәвамында нәшер итеп килделәр.

Сорау: Тикшерү буенча билгеле, сез тоткынлыктан кайткачнан соң Совет властена каршы пропаганда эшен туктатмагансыз. Үзегез белән аралашкан кешеләр арасында революциягә каршы пропаганда алып баргансыз. Сез хакимлек итүче милләт тарафыннан милли республикаларның хокуклары кимсетелүе турында ялган сүзләр сөйләп йөргәнсез. Бу сорау буенча күрсәтмәләр бирегез.

Җавап: Мин үземне гаепле дип санамыйм, чөнки мин бернинди дә революциягә каршы милләтчелек эше алып бармадым.

Сорау: Сез Шәфиев Абдрахманның үзен күреп беләсезме?

Җавап: Юк, беркайчан да күргәнем юк.

Сорау: Сез дөрес күрсәтмәләр бирмисез, тикшерү буенча мәгълүм, 1930 елны Шәфиев А. Казанга килгән һәм сезнең туганыгыз Галимҗан белән очрашкан. Дөрес күрсәтмәләр бирегез! Сез юкка гына барын да ялганлыйсыз, тикшерүгә мәгълүм ки, Шәфиев А.—немец шпионы. Ул СССРда разведка эшләре алып барган һәм шуның өчен Казанга килгән дә инде. Ул сезнең энегез Галимҗан белән очрашкан. Ни өчен сез моны бик тырышып кире кагасыз?

Җавап: Мин сезгә тагын бер кат әйтәм: мин аны белмим, бары тик энем Галимҗаннан ишетеп кенә беләм.

Сорау: Тикшерүгә мәгълүм, сез үзегезнең тирәдәге кешеләр арасында Советларга каршы милләтчелек эше алып баргансыз. Расмы?

Җавап: Мин моны расламыйм.

Сорау: Сез монда берни дә сөйләмисез, тикшерү эше сезгә үз интересларыгыз өчен дөрес күрсәтмәләр бирергә тәкъдим итә. Үзегезнең Совет властена каршы эшегез турында сөйләгез!»

Менә шушында кадәр Борһан Шәрәф барысыннан да баш тартып килә, әмма тора-бара нидер була. Ихтимал, бу тикшерүчеләрнең «махсус» алымнар куллана башлавы нәтиҗәсендәдер. Алтмыш яшьлек, вакытыннан алда картайган, бөтен аңлы тормышында бертуктаусыз эзәрлекләнгән Б. Шәрәф сорау алуларны авыр кичергәнлеге мәгълүм, төрмәгә эләккәнче үк докторлар тарафыннан аның инвалид икәнлеге расланган була. Шулай булса да, өзлексез сорау алулар вакытында ул соңгы чиккә кадәр көрәшә, бирешми. Әмма бераздан түбәндәге документ дөньяга килә: «Әйе, мин дөресен сөйләргә булдым. 1928 елда мин үз мәнфәгатьләремне канәгатьләндерә алмадым, сәүдә итүне тыйдылар, шуңа күрә Совет властена бик рәнҗимен. Минем ачуым Ташкент шәһәрендә, үз тирәмдәге кешеләр белән аралашканда, Советка каршы тагын да артты. Нәтиҗәдә кулга алынып өч ел төрмәдә утырдым.

Концентрацион лагерьдан кайткач, бөтен ир туганнарымның да Советка каршы эш алып барганнары өчен кулга алынганнарын белдем. Ачуым тагын да кабарды. Бу хакта Казанда «Электропром» хезмәткәрләре алдында ачыктан-ачык әйттем.

Сорау: Үзегезнең Совет властена каршы сүзләрегезне «Электропром» хезмәткәрләренең кайсына әйттегез?

Җавап: Күбесенчә Советка каршы сүзләремне ачыктан-ачык итеп гадәттәгечә баш бухгалтер урынбасары М. Садовскийга, Зоя Максимовнага, Нестеров Иван Петровичка һәм «Электропром»ның башка хезмәткәрләренә әйтә идем.

Сорау: Сезнең Советка каршы эшләрегез нидән гыйбарәт иде?

Җавап: Минем Советка каршы эшләрем 1936 елның ахырына — 1937 елның башына туры килә. Бигрәк тә икмәк әзерләү, промышленность товарлары белән авырлыклар килеп чыккан чакларда. Мин үзем ачыктан-ачык әйтә идем: икмәк мәсьәләсендә хөкүмәт махсус рәвештә җитешсезлекне ясый. Мин бөтен гаепне хөкүмәттән күрдем. Моннан тыш мин Совет хөкүмәте тарафыннан оештырылган репрессияләр һәм Югары Советка сайлауларга әзерләнүләрнең тәртибен тәнкыйть иттем. Мин болайрак уйлый идем: «Совет дәүләте яңа демократик Конституция эшләде, шулай булса да сыйнфый дошманның эшчәнлеге көчәюдән шүрли. Югыйсә, Конституция нигезендә аларга демократик ирек

бирелүе хакында әйтелә. Югары Советка сайлаулар вакытында шикле дип табылган кешеләргә — элеккеге офицерларга, алпавытларга, сәүдәгәрләргә һ. б. карата мәрхәмәтсезлек күрсәтелә».

Бик күп уйланулардан соң, элеккеге сәүдә эше өчен Совет власте органнары тарафыннан кулга алынудан куркып, соңгы вакытта Советка каршы фикер әйтүдән тыелдым.

Сорау: Сез үзегезне берничә ел рәттән, советларга каршы уйда булган кеше буларак революциягә каршы эш алып баруда гаепле дип таныйсызмы?

Җавап: Әйе, мин үземне тулы рәвештә гаепле дип саныйм».

Әлеге документка ул үзенең кулын куеп калдырган. Ниһаять, көчләп картның «гаебен таныткач» Б. Шәрәфнең эше ТАССР НКВДсының Өчлегенә тапшырыла. Тикшерүчеләр Әхмәтов һәм Ивинның явыз эше архив документларыннан ачык күренә. Заманасы шул: кемдә көч, шунда «дөреслек»!

1937 елның 30 декабрендә Өчлек үзенең утырышында Борһан Шәрәфне 10 елга лагерьга (ИТЛга) җибәрергә дигән карар да чыгара. Татарстанның эчке эшләр комиссары урынбасары Шелудченко тарафыннан тиздән яңа документ әзерләнә. Икенче төрле әйткәндә, Б. Шәрәфнең эше яңадан кузгатыла. Бу документ түбәндәгеләрдән гыйбарәт: «Шәрәф Борһан Совет властена каршы оешкан милли «Идел — Урал» җәмгыятендә әгъза булып тора. РСФСР Җинаять Кодексының 17, 58-2, 58-10/1 б., 58-11, 158 һәм 175 нче маддәләренә таянып, җинаять эше буенча түбәндәге карар туа:

Карар

Шәрәф Борһан Свияжскийның 8 нче номерлы ИТК ОМ 3 НКВД төрмәсеннән 1 нче номерлы ОМЗ төрмәсенә күчерелә. Тагын РСФСР Җинаять Кодексының 17, 58-2, 58-10/ 1 б. һәм 58-11 маддәләре буенча хөкем ителә.

Шәрәф Борһан таныштырылды»[70].

Б. Шәрәфне янә Казанга алып кайталар һәм 1937 елның 21 мартында яңадан сорау алулар башлана. Аңа яңадан бөтен узган гомерен исенә төшерергә, тикшерүчеләргә бәйнә-бәйнә сөйләп чыгарга туры килә. Ул «Казан мөхбире»ндә, «Әхбар»да эшләвен, Октябрь революциясеннән соң беркадәр вакыт Габдерахман Вахитовның тире заводында эшләвен, ә аннан соң Оренбургта төрле курсларда укуын, ә 1923 елда Казанга кайтуын искә ала. Әлбәттә, тикшерүчеләргә мондый «әкиятләр» генә ошап бетми, алар-

га — «шпион», «халык дошманы» эзләүчеләргә башкачарак мәгълүматлар кирәк. Шул сәбәпле бу юлы сорау алулар тагын да кырысрак, куркынычрак төс ала. Сорау алулар берничә тәүлек туктаусыз дәвам итә. Тоткын барысына да түзә, ә тикшерүчеләр түзә алмый, алар алмашып эш итәләр. Монда Б. Шәрәфкә сорау алуларның төрле формалары белән танышырга туры килә: «басу» дип аталганы — тәүлекләр буе аяк өстендә тору; шулай ук ачлык белән интектерү, куркытулар, кыйнаулар һ. б. Бу юлы да аңа советларга каршы көрәшүче яшерен милли оешманың әгъзасы дип яла ягалар. Әмма ул: «Юк, мин үземне гаепле дип санамыйм, мин бернинди оешманың да әгъзасы гына түгел, аның барлыгын-юклыгын да белмим»,— ди. Аңа куркытулар тәэсир итә алмыйлар, ул янә үзен гаепле дип танымый. Барып чыкмагач, аны Мәхмүд Галәүнең 1937 елның 20 октябрендә сорау алган вакытында биргән күрсәтмәләре белән таныштыралар. Мәхмүд Галәү аның турында түбәндәгеләрне белдерә: «Шәрәф Борһан 1920—1921 елларда иң беренче булып Коръәнне татар теленә тәрҗемә итте. Үзе үк Керенский катнашында дәүләт киңәшмәсендә (август, 1917 ел.— *Р. В.*) катнаша. Актив эшчәнлеге өчен хөкемгә тартыла. Утырып чыккач Казанда яңадан Советка каршы актив пропаганда алып бара. Хәтта кибет чиратларында, татар халкы күп җыелган урыннарда үз оешмасы заказларын үти, халыкны үз ягына аудара. Мәскәүдә еш булган. Төгәл директиваларын Кәримовка тапшыра, Мәскәү филиалы һәм Казан Үзәк оешмасы арасында арадашчы ролен үти».

Әлбәттә, бу юлларны укыгач азрак гаҗәпләнерлек урын булса да, инде күпне күргән, тикшерүчеләрнең махсус алымнарын татыган Борһанга монда шаккатарлык нәрсә булмый. Ул тыныч кына җавабын ирештерә:

— Мин Галәүне чама белән 1914 елдан бирле беләм. Аның белән Оренбургта танышкан идем. Ул вакытта Мәхмүд Галәү галантерея товарлары белән сату итәдер иде. Фатих Кәримовны мин 1908 елның ахырыннан беләм, ул минем хатынымның абыйсы, сезнеңчә нәрсә, шурин буламы инде?

— Телеңә салынма... сөйлә! — дип җикеренә тикшерүче.

Борһан дәвам итә:

— Кәримов Фатих 1914 елга кадәр редактор, ә мин тәрҗемәче идек. ...Казанда кулга алыныр алдыннан М. Галәү белән очрашкан идем. Гражданин начальник, Галәүнең күрсәтмәләрен әйтәм: анда кайбер дөрес хәбәрләр дә бар бит. Мәсәлән, мин 1916—1917 елларда Коръәнне та-

тарчага тәрҗемә иткән идем, әмма ул датасын, дөресрәге елларын бутый. Мин чыннан да, Дәүләт киңәшмәсендә булдым, әмма мин анда бары тик журналист буларак, «Вакыт» газетасыннан килгән идем. Минем тавыш-фәлән бирергә хокукым да юк иде. Ә инде нинди дә Советларга каршы милли оешмалар булуы турындагы күрсәтмәләре уйлап чыгарылган нәрсә. Аның авторы Галәү булуына да шигем бик зур.

— Ә Үзәк белән мөнәсәбәткә ни дисез инде?—ди тикшерүче.

— Ни дип әйтергә дипме? Әлбәттә, юктан уйлап чыгарылган уйдырма, дим. Бернинди филиалны да, Казан Үзәген дә мин белмим. Бернинди яшертен оешма турында ишеткәнем юк,—ди тоткын.

Нигәдер бу юлы тикшерүче дәшми. Нәтиҗәдә, 12112 нче номерлы эшне шуның белән тәмамлап, 1939 елның 26 мартында ТАССР эчке эшләр комиссары урынбасары Новиков, дәүләт куркынычсызлыгы капитаны түбәндәге карарны раслый: «Шәрәф Борһанга карата кузгатылган җинаять эше турындагы материалларны 12112 нче номерлы кенәгәдән алырга һәм эшне туктатырга.

ТАССР НКВДсы каршындагы Өчлек тарафыннан 1937 елның 30 декабрендә хөкем ителгән Шәрәф Борһанны янәдән җәзасын күрергә җибәрергә»[71].

Шулай итеп, Б. Шәрәф ике елдан соң янә (башта 1937 елның 30 декабрендә, ә аннан соң инде икенче тапкыр 1939 елның 26 мартында) 10 елга хөкем ителә. Бу хәл Борһан Шәрәфнең һәм аның хатынының 1937 елның 14 мартында Халык комиссары Бериягә хат язуларыннан соң каралган булырга тиеш. Бу турыда «эш»тәге кечкенә генә язма сөйли. Анда «22 апрель, 1939 ел. Эшне карау туктатылды» диелгән. Иренең эшен яңадан карап, гадел хөкем итүләрен сорау барысы да юкка була. Закирә ханымның хатында күрсәтелгән тәртипсезлекләр, яла ягулар, иренең саусыз инвалид икәнлекләре берсе дә искә алынмый. Өчлекнең әмере тагын бер кат элеккеге карар белән раслана.

Лагерьдан лагерьга, төрмәдән төрмәгә йөри торгач, Борһан Шәрәф бөтенләй каты авырып китеп, 1942 елның 28 декабрендә 69 яшендә Раифә колониясендә дөнья куя.

Шушы вакыйгадан соң 14 ел узгач, Закирә Шәрәф янә Борһан Шәрәфнең эшен карау турында эчке органнарга хат язып җибәрә. Аның хатында 21.XI.1956 ел датасы тора.

Бу эш Татарстан дәүләт куркынычсызлыгы комитетының тикшерү бүлеге җитәкчесе урынбасары подполковник Әминевкә тапшырыла. Ул аны җиренә җиткереп башкарып

чыга, Михаил Садовскийны һәм Иван Нестеровны эзли, әмма аларны таба алмый. «Электропром»да эшләүче В. А. Мягков аларның берсен дә, шулай ук Зоя Максимовнаны һәм Борһан Шәрәфнең үзен дә хәтерләми.

Тикшерә торгач Борһан Шәрәфнең гаепсезгә хөкем ителгәнлеге мәгълүм була. Озак эзләнүләрдән һәм тикшерү материалларын өйрәнгәннән соң Әминев нәтиҗә ясап, түбәндәгеләрне яза: «Шәрәф Борһан ТАССР НКВДсы тарафыннан 1937 елның 28 декабрендә кулга алына, нәрсәгә нигезләнеп аны ирегеннән мәхрүм итүләре мәгълүм түгел. Белешмәдән күренгәнчә, «Шәрәф тоткынлыктан кайткач та, соңгы көнгәчә Советка каршы эшчәнлеген туктатмый, үзе тирәсендәге кешеләр арасында агарту эшләре алып бара». Болар барысы да уйдырма, аны дәлилләгән материаллар Шәрәфне кулга алганда бөтенләй булмаганнар».

1957 елның 12 июнендә Әминев тарафыннан әзерләнгән әлеге йомгаклау материалы ТАССР Куркынычсызлыгы комитеты рәисе П. Семенов тарафыннан шул ук елның 14 июнендә раслана.

1957 елның 6 июлендә ТАССР прокуроры Югары Совет президиумына протест хаты юллый. Анда ТАССР НКВДсы каршындагы Өчлек тарафыннан Б. Шәрәфкә карата 1937 елның 30 декабрендә чыгарылган карарына карата «Гаепләре булмау сәбәпле эшне туктатырга» диелә. 1957 елның 18 июлендә Югары Совет президиумы Өчлекнең әлеге карарын гамәлдән чыгара[72].

Менә шулай итеп, бу эш тә тәмамлана һәм Борһан Шәрәфнең дә бернинди гаепсезгә рәнҗетелүе, тоталитар режимның корбаны икәнлеге исбат ителә. Хәзер инде язылыларыбыз мәкаләләрен, китапларын язганда Галимҗан Ибраһимов, Зәки Вәлиди, Фатыйх Сәйфиләр янында Борһан Шәрәфне дә санап китәрләр, аңа да үзенең лаеклы урынына кайтырга булышырлар дип уйлыйсыбыз килә. Ул моңа бик лаеклы.

СҮНМӘС ЙОЛДЫЗ

«МӘСКӘҮЛӘР ТОТСА ЯКАҢ...»

Рәхимә ханым, йокыдан торып, чәйләп кенә бетереп килә иде, кемдер каты итеп ишек шакыды. «Әллә Гыйльметдинем кайттымы? Түгелдер лә, ул алай шакымый иде. Чыгып киткәндә июль башларында гына Казанда булырмын дигән иде бит»,— дип уйлап куйды ул.

Аннары ишек янына килеп:

— Кем бар? Гыйльметдин, син түгелдер бит?— диде.

— Ачыгыз, НКВД! Хуҗа кайда?— диделәр тышкы яктан.

Йөрәге тетрәп китсә дә, Рәхимә ханым сер бирмәде, ишекне киң итеп ачып җибәрде.

Ишек алдында дүрт ир-ат басып тора иде. Икесе НКВД киемендә. Өс-башлары пөхтә, чиста, йөзләре бик җитди. Калганнары шаһитлар булса кирәк...

Ордерны күрсәткәч, өйгә уздылар.

— Без сезне тентергә мәҗбүрбез. Минем фамилиям Фролов,— диде җирән чәчлесе.

— Нишлисең инде... Тентегез, тентегез. Элек жандармнар Гыйльметдин абыегызның теңкәсенә тияр иде, инде хәзер НКВД Фролов дисеңме әле, улым? Гыйльметдин абыегызның тентерлек әйберләре бик күп түгел шул. Элек китап бастыра торган булса, 1918 елдан бирле ул бәхеттән дә мәхрүм... Өйдә булса бер хәл, әмма абыегыз өйдә юк бит... «Урман» компаниясе эшләре белән командировкага киткән иде, әле тиз генә кайтмас,— дип сөйләнде Рәхимә ханым, үз өендә утырырга урын таба алмыйча.

— Кайтыр, бездән котыла алмас,— дип өзде аны Фролов.— Ә жандармнар, НКВДлар турындагы фикерегезне кабатласагыз, эшне бәлки сездән үк башлап җибәрербез...

Тентү озакка сузылмады. Киштәдәге китаплар, өстәлдәге язмалар, шкафтагы шәраб та аларны кызыксындырмады.

«Нәрсә эзлиләр икән соң болар»,— дип уйлап куйды Рәхимә ханым.

Шулчак Фролов:

— Менә, менә, таптым! — дип кычкырып җибәрде.

Барысы да тәрәзә төбенә җыелдылар.

— Менә ул...

Фролов тәрәзә төбендә, әле революциягә кадәр үк җыелып килгән, беркемнән дә яшерелмичә ята торган көмеш тәңкәләрне портфеленә себереп төшерде. Калганнары аңа булышты. Аннан соң алар бик зур эш эшләгән кыяфәт белән беркетмә дә төзеп тормыйча, китеп бардылар.

«Әллә инде болар бандитлар гына булдылар? — дип уйлады Рәхимә ханым.— Ордерларын юньләп укымадым... Гомер буе шулай булды инде, юкка-барга борчылып, бар кешегә дә ышанып... Вәт бит, ә. Өеңә кереп бар әйбереңне себереп алып чыгып китсеннәр инде. НКВД шундый була микәнни?»

Бу вакыйгадан соң өйдә шомлык урнашты, курку хисе керде.

7 июльдә кабат ишек шакыдылар. Ишек төбендә ире — Гыйльметдине басып тора иде. Ул:

— Әссәламегаләйкем, әнисе,— дип, Рәхимәсен кочып та алды.

Рәхимә аңа тентү ясаулары, көмешләрен алып китүләре турында әйтте. Юлдан арып-талып кайткан Гыйльметдин өчен бу хәбәр башына күсәк белән суккан кебек булды.

— Ярый, әнисе, кайгырма, әйдә өйгә керик,— диде Гыйльметдин хатынын тынычландырып.

Өйдә һәрвакыттагыча чиста, пөхтә, җанга рәхәт иде. Асрау кыз Нәгыймә инде өстәлгә чәй дә китереп куйган. Ипи, чәй, пары чыгып торган бәрәңге, әстерхан селедкасы янына командировкадан алып кайткан җиләк-җимеш, казылыклар да өстәлгәч, табын тагын да баеп китте. Өйгә бәйрәм төсе керде. Балалар гына мәктәптән кайтып җитмәгән иде.

Гыйльметдин сүзсез генә ашады, эчте. «Арып-талып кайтканнан соң, мунча кереп, бер-ике көн ял итеп алсаң, әйбәт булыр иде»,— дип уйлап куйды ул. Шулчак юлда ишеткән бер мәзәк исенә төшеп, елмаеп куйды.

«Казах, азәрбайҗан һәм татар мактанышып утыралар ди.

Казах:

— Безнең якта Байкал күле бар, бик зур күл. Минем абый атка атланып бер атна эчендә генә әйләнеп кайтты,— ди икән.

Азәрбайҗан:

— Каспийны белсәгез иде сез. Минем абый дөягә ат-

ланып ярты ел эчендә генә әйләнеп кайта алды,—дигән.

Инде безнең татарга чират җитә. Ул аптырап калмый, сөйли башлый, әмма казах белән азәрбайҗан көлә башлыйлар:

— Сезнең Кабан күле сасып беткәндер, әллә шуның белән мактанмакчы буласыңмы?—диләр.

— Бездә дә бер «черек» күл бар, минем абый аны әйләнеп кенә чыгам дип киткән иде, әле дә кайтып кергәне юк,—дигән татар».

Ашап-эчкәч, ул өйдән чыгып китте. Урамда кызу иде. Халык аз. Гыйльметдин йорт чатында берәүнең арты белән борылып тәмәке тартып торганын гына шәйләп калды. Ул аңа әһәмият бирмичә турыдан гына Дзержинский урамы ягына китте. «Койрык» та аңа иярде. Реакция елларында «койрык»ларга өйрәнеп беткән Гыйльметдинне ул куркыта алмады, әмма аны киләчәгенең билгесезлеге борчыды.

ГПУның имән ишекләре киң ачылды. «Черек күл» егетләре аны якты чырай белән каршы алдылар. Ишектән кереп, сул яктагы тар гына бер бүлмәгә алып кереп: «Күп сөйләшеп торырга вакыт юк, Гыйльметдин Шәрәфетдинович, 11 июльдә тагын безгә рәхим итегез»,—дип чыгарып та җибәрделәр. Әйтерсең лә, теге мәзәкне ишетеп, аның кересен эшләделәр.

Тик шом, курку кергән күңел тынычлана аламыни? Дзержинский урамына чыккач ул, кай якка китәсен белмәгән кеше кебек, бер мәлгә тукталып калды.

Аннары: «Галимҗанны күреп чыгыйм»,—дип уйлап куйды һәм энесе яшәгән якка юл алды. «Койрык» та калышмады... Бәхеткә каршы, Галимҗан өйдә үзе генә иде. Хатыны Әсма баласы белән урамга чыгып киткән. Гыйльметдин, энесен кочаклап алып:

— Менә, төрмәгә урнашырга йөрим бит әле,—дип шаяртырга тырышты һәм булган хәлләрне сөйләп бирде.— Әле менә «Черек күл»дән кайтып киләм, сине күреп китим дидем. Белеп булмый аларны, ябып та куюлары бик мөмкин.

Галимҗан өчен монда артык яңалык юк иде югын. «Тик тентү булганын Рәхимә җиңгәсе ни өчен аңа әйтмәде икән соң? Әле теге җомгада гына очрашканнар иде бит, бергәләп чәй эчеп утырдылар. Балалар күп иде, күрәсең шуңа күрә сөйләмәгәндер»,—дип уйлады ул.

— Абый, минемчә без барыбыз да бер юлдан, һичшиксез, һәлакәт юлыннан барабыз. Менә укы әле бу нәрсәне,— диде Галимҗан һәм абыйсына машинкада русча язылган берничә бит кәгазь бирде.

Гыйльметдин күзлекләрен рәтләп, текстны алып караугa, анда «Глубокоуважаемый И. Сталин...» дигән сүзләрне күрде.

— Бу нәрсә, Галимҗан, хатмы, мөрәҗәгатьме, әллә листовка кебек нәрсәме? — дип сорады ул энесеннән.

— Хат бу, абый, хат! — диде Галимҗан. — Аз булса да моңа ышаныч бар әле. Монда телебез, әдәбиятыбыз, гомумән алганда татар мәдәнияте, татар милләтенең киләчәге турында сүз бара. Монда мин гарәп шрифтын саклап калу турында яздым, шуның өчен көрәшәчәкмен дә. Бакуда 1926 елда булып узган фәнни конференциядә ясаган докладым турында сиңа сөйләгән идем инде. Аннан соң шушы мәсьәләләргә багышланган китабымны да хәтерлисеңдер. Бакудагы чыгышым матбугатта басылып чыкмады, ул бары тик чит илләрдә, мәсәлән, Төркиядә Бари Баттал әфәнде тарафыннан тәрҗемә ителеп дөньяга чыгарылды. Минем чыгыш: «Выслушав доклад Агамалы Оглы о плохой орфографии и недостатках арабской системы и принятии латинской системы шрифта, Ленин задал Агамалы Оглы вопрос: «А как относятся крестьяне к этому делу?» После ответа Агамалы Оглы о доброжелательном отношении крестьянства к этому вопросу, он кратко произнес: «Это — революция на Востоке». Здесь политический анализ и заключение по этому вопросу т. Ленина заключается не в последней краткой фразе, а в вопросе Ленина: «А как относится к этому делу крестьянство?» Разрешите спросить, отвечая т. Ленину о благожелательном отношении крестьянства, т. Агамалы Оглы не был ли сам введен в заблуждение, как об ожидаемых выгодах от нововведения и об отношении крестьянства к данному вопросу». Шул урында туктап, Галимҗан кухняга чәй куярга кереп китте.

— Мин үзем сине хуплыйм, энекәш, — диде Гыйльметдин, язма белән танышып чыккач. — Күрәсең, эш шрифтта гына түгел. Хәзер инде минем үземә дә аңлашыла башлады синең борчылуың, чыннан да, ялгыш юлга кереп барабыз икән шул. Болай булса безнең эшләр хөртиләнә. Безгә бик авыр булачак, әмма түзәргә кирәк, бирешмик!

Абыйсының фикерен хуплап, Галимҗан Тукайның шигъри юллары белән җавап бирде:

Ни кылырсың... абзый, тотса мәскәүләр якаң?
Как ты будешь отвечать там, тотса мәскәүләр якаң?

Сыгмас ирден киң җиһанга, малыңа мәгърур булып,
Даже в тюрьму сыярсың, тотса мәскәүләр якаң.

Тукай иҗатын Шәрәфләр барысы да яхшы беләләр иде.

— Безнең «сул» булып йөрүче, Мәскәү указларын тормышка ашырырга ашкынып торган «горур латинист» Фатыйх Сәйфиләр, философ Мингәрәй Сәгыйдуллиннар, Шамил Усмановлар бу өлкәдә зур уңышларга да ирешүләре мөмкин,— диде Галимҗан, абыйсына карап.— Аның бит әле Мингәрәен «татар Бухарины» дип тә йөртәләр. Кызганыч, шушындый талант ияләре үзләренең көчләрен юкка сарыф итәләр...

Язмыштан узмыш юк диләр бит. Нәкъ ун елдан соң Казан төрмәсендә латинист Мингәрәй Сәгыйдуллинны арабист Галимҗан Шәрәф белән күзгә-күз очраштырырга алып киләләр. Хәзер инде аларны бер берсенә халык дошманнары итеп очраштыралар... Менә бит ул язмыш.

Бераз сөйләшеп утырганнан соң бергәләп урамга чыктылар. Арып-талып командировкадан кайткан Гыйльметдингә тизрәк өйгә кайтып егылу бик кирәк иде. Галимҗан аны Кекиннар йортына кадәр озатып та куйды, абыйсы борылышка кергәнче бер урында басып көтеп торды. Менә Гыйльметдин борылышка җитте һәм энесенә кул селтәде. «Бу соңгы күрешү булмасын,— дигән уй узды Галимҗанның башыннан.— Дөнья хәлен белеп булмый...»

«Черек күл» егетләре 11 июльне көтеп тормадылар. 9 июльдә үк Гыйльметдиннең фатир ишеген шакыдылар. Кабат тентү ясаганнан соң аны үзләре белән үк алып киттеләр. Бу көтелмәгән хәл иде. Иртәгесен, 10 июльдә ТОГПУның өченче бүлек хезмәткәре Мозаффаров бу хакта мондый мәгълүмат калдырган: «Тентү вакытында бернинди шикле әйбер табылмады. Гыйльметдин Шәрәф үзен тыныч, әдәпле тотты һәм аның мондый тәртибе кулга алыначагын алдан сизенгәнен белдерә». Бу фикерне шаһит Гыйниятулла Кашшаф та раслап, «чыннан да, аның фатирында бернинди дә компрометирующий материал табылмады», ди. 16 июльдә кабат тентү була. Тентү вакытында шаһитлар Хөсәен Сәлахов, Краснов, Власов дигән кешеләр дә булалар. Тентү тагын бернинди нәтиҗә бирми. Ярый әле тентүчеләр үзләре берәр нәрсә кертеп «тапмыйлар».

КЕМ СОҢ УЛ, ГЫЙЛЬМЕТДИН ШӘРӘФ?

Ул Буа өязендәге Аксу авылында 1885 елда дөньяга килә. Казанга килеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә һәм аны бик уңышлы тәмамлый, югары белем ала. 1906 елда өлкән абыйлары Шәһретдин, Борһанетдин Шәрәфләр белән берлектә беренче татар типографиясен

ачып җибәрә. Бу «Матбагин Шәрәф» соңрак «Мәгариф» исеме белән атала. Ул тиздән алдынгы типографияләр рәтенә баса һәм күбесен узып та китә. Әмма беренче көннәрдән үк типография һәм аның редакторы эзәрлекләүләргә дучар була. Гыйльметдин Шәрәфнең әйтүенә караганда, 1908—1913 еллар эчендә генә дә типография 4 мәртәбә ябыла. Шул ук вакытта бертуган Шәһер, Борһан, Гыйльметдин Шәрәфләр артыннан яшерен күзәтү оештырыла. Аларны Казан, Оренбург, Саратов жандармнары эзәрлекли. Гафур Коләхметов, миллионер З. Рәмиев, бертуган Хәсәновлар, бертуган Аитовлар, бертуган Шәрәфләр даими күзәтчелек астында яшиләр. Аларның хатларын укып, кайда булуларын, кем белән очрашуларын күзәтеп, тиешле урынга хәбәр итеп торалар. Типографиядән чыккан китапларда, чыннан да, беренче революцион язмалар, рус идарәсенә каршы, патша хөкүмәтен хурлаган материаллар дөнья күрә.

Берничә ел дәвамында типография үзенең атамасын үзгәртеп В. Казаков, Саинов типографиясе исеме белән дә йөри. Әлбәттә, чынлыкта аның җитәкчесе Г. Шәрәф була. Өр-яңадан «Мәгариф» 1913 елда ачыла. Бу юлы да ул Шәрәф фамилиясе белән аталмыйча, М. А. Мостафин исемендә була. И. Корбангалиев һәм Г. Камал пайчылар булып тора, ә чынлыкта аның оештыручысы һәм пайчысы Гыйльметдин Шәрәф була. Әбрар Кәримуллин мәгълүматларыннан күренгәнчә, типография 1906—1913 еллар эчендә 348 исемдә 2 миллион данә татар китабын дөньяга чыгара. Фәнни-популяр темаларга һәм инкыйлабка багышланган әсәрләр байтак була. Алардан тыш басмаханә мөселман халыкларны рус һәм чит ил язучыларыннан И. Куприн, Л. Андреев, Д. Мамин-Сибиряк, И. Тургенев, Н. Гоголь, Л. Толстой, А. Конан-Дойл, Жан Жак Руссо, Даниел Дефо, Байрон, Мольер һәм башкаларның әсәрләре белән таныштыра. Типографиянең иң изге эше — татар язучыларын пропагандалау, аларны олы юлга чыгару. Әйтергә кирәк, Габдулла Тукайның, Мәҗит Гафуриның һәм башка язучыларның әсәрләре бу типографиядә беренче булып дөнья күрә.

Тукайның «Мәгариф» белән беренче танышуы, мөгаен, анда чыккан китаплар, брошюралар аркылы булгандыр. Бигрәк тә Гыйльметдин Шәрәфнең «Шигърият китапханәсе» дигән сериясе яшь шагыйрьнең бәгыренә сеңеп, аның күңелендә яңа хисләр уята. «Ни өчен шулай?» дигән сорауга Габдулла Тукайның кыска гына вакыт эчендә Гыйльметдин Шәрәф исеменә биш хат язып җибәрүендә җавап табабыз. Бәлки башка хатлары да булгандыр, аны-

сын киләчәк күрсәтер. Аның 1907 елда Гыйльметдин Шәрәфкә язган хаты, Энҗе Сәгыйтова тарафыннан әзерләнеп, «Дружба народов» журналында (1967, № 8) тулы килеш бирелгән. Анда Тукай үзенең шигырьләр җыентыгын бандероль белән җибәрүен яза. Ул үзенең дә килү ихтималы хакында хәбәр итә һәм, шуңа күрәдер, Гыйльметдиннән 50 сум акча җибәрүен үтенә; хатын «Китабымны сезгә тапшырам, ничә тапкыр бастырырга теләсәгез, шуның кадәр бастырыгыз, миннән рөхсәт. Җавап көтәм, языгыз. Сезнең тыңлаучан ялчыгыз Габдулла Тукаев» дип тәмамлый. Шулай итеп «Мәгариф» матбагасы һәм татарның булачак классик шагыйре арасында тыгыз элемтәләр урнаша. Бер ай тулып җитми, Г. Тукай үзенең шигырьләрен хатка салып җибәрә. «Сезгә тагын «Шүрәле» һәм «Балалар тәрбияләү» шигырьләремне җибәрәм»,—дип яза шагыйрь. «Китмибез»не җыентыкның башында урнаштыруны үтенә. Бу шигырь татар интеллигенциясенә чакыру булып яңгырый.

Г. Тукайның шигырьләр җыентыгы басылып чыккач, Фатих Әмирхан үзенең рецензиясендә: «Шәрәф матбагасының шигырь мәҗмугалары нәшере белән әдәбиятымызга киткән хезмәте—эш, әһле кулында булганда, никадәр файда китерә ала икәненә дөрес бер мизандыр»,—дип яза[73].

Әлбәттә, Тукай белән Гыйльметдин Шәрәф арасындагы үсеп барган дуслык, иҗади бәйләнешләр, киң дөньяга чыгып килүче җыентыклар яшь шагыйрьне тагын да канатландыра, туган якларга тарта.

ОЧРАШУЛАР

1907 елның октябрь башлары була. Г. Шәрәф типографиягә килеп почтаны, яңа килгән хатларны, телеграммаларны карап чыга, әмма шаккатырлык нәрсә күренми. Шулвакыт матбага конторасына ике егет кереп:

— Гыйльметдин әфәнде, безгә матбаганы карап йөрергә рөхсәт бирсәгез иде,—дип сүз кушалар.

Мондый сорауларга күнегеп беткән Гыйльметдин:

— Әйдәгез, әйдәгез, әфәнделәр, узыгыз! Үзем күрсәтеп йөрермен,—дип урыныннан торып, егетләрне типография буйлап алып китә һәм үзе күрсәтеп йөри.

Эшне бетереп, матбагадан чыгып барганда аларның берсе: «Менә сезгә Уралскидан Камил Мотыйгый «Яңа тормыш» газетасына абуданә дәфтәре җибәргән иде»,—дип дәфтәр суза. Шул вакытта Гыйльметдин аңа карап:

— Сез Уральскидан Габдулла Тукаев түгелме?—дип сорый.

— Әйе, шул булам,— ди Тукай, Гыйльметдингә кул сузып.

Менә шулай итеп, шагыйрь белән китап чыгаручы Гыйльметдин Шәрәф очрашып, танышып та китәләр.

Тукай матбага хуҗасына, елмая-елмая, үзенең монда ничек килеп чыгуын сөйли:

— Менә, авылдан килеп төшеп «Болгар» кунакханәсенә урнаштык та, призыв эшләре белән кереп чыккан идек. Чәй эчкәнче мәҗмугамның хәлен белеп кайтыйм дигән идем,— ди ул.

Шатлыгын кая куярга белмәгән Гыйльметдин егетләргә карап:

«Әйдәгез, монда гына чәйләп алыйк алайса»,— дип конторасының арткы ягына кереп тә югала.

— Шулай итеп солдат тормышыннан да котылдыгызмы?— ди Гыйльметдин Тукайга карап һәм,— әйдәгез, менә минем кечкенә генә кунакханәмә,— дип чәй эчәргә алып керә.

Әлбәттә, сүз әдәбият дөньясына кереп китә.

— Әссәламегаләйкем, әфәнделәр,— дип Борһан Шәрәф тә килеп керә.

Гыйльметдин:

— Таныш булыгыз, менә бу Габдулла Тукаев була инде, ә менә бусы Мотыйгый әфәнде, ә бусы Борһан Шәрәф — минем бертуганым,— дип таныштыра.

Борһан Шәрәф белән сөйләшү шигърият дөньясына алып китә. Алар Лермонтов, Пушкин әсәрләре турында фикер алышалар.

— Виссарион Белинскийны әйтәсезме,— ди Тукай, Борһан Шәрәф белән әңгәмәгә керешеп.— Әйе, бик кызык адәм, тәнкыйтьче, ишеткәнем генә бар. Кызганыч, бер әсәрен дә әле укыганым юк.

Г. Шәрәф Тукайның вафатыннан соң язган истәлекләрендә: «Берәр сәгать чамасы сөйләшеп утырган идек. Менә шул минутлардан без Габдулла әфәнде белән таныш һәм соңгы көннәренә кадәр икебез дә Казанда булган вакытта бик еш күрешә торган, Казан теле белән әйтсәк, кашыклы аштан калмый торган дус, иптәш булып китәбез»,— дип искә ала.

Тукай белән Шәһер арасында да зур дуслык урнаша. Ул аннан төрек әдәбияты тарихы турындагы беренче дәресләрен ала. Ш. Шәрәф бу хакта түбәндәгеләрне язып калдырган: «Күп нәрсә сораша, бу нәрсәләрне бик яратып тыңлый вә шуларны тәфсыйләте белән беләсе килә иде... миннән төрек әдипләренең байтак китапларын алып укыды.

«Госманлы әдәбияты нәүмунәләре» исемле китапны укыгач: «Бу китапта миңа ярарлык нәрсәләр бар икән», дигән иде»[74].

Бу иҗади дуслык шагыйрьнең соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. Шәрәфләр аның вафатыннан соң да аның иҗатын пропагандалыйлар, төрек-татар дөньясына һәм рус халкына җиткерәләр. Бу өлкәдә яшь Галимҗан зур өлеш кертә. Ул, рус язучысы Радимов белән бергәләп, Тукайның «Шүрәле»сен, «Кәҗә белән сарык» һәм башка әкиятләрен русчага тәрҗемә итә.

Габдулла Тукай Галиәсгар Камал, Сәгыйть Рәмиев, реаль училищеда укып йөрүче Галимҗан Шәрәф һәм башкалар белән таныша-аралаша башлый. Әлбәттә, шагыйрьнең күңелендә урын алган яңа дуслары аның шигырь юлларына да кереп калганнар. Габдулла Кариевка 1907 елның 30 декабрендә юллаган хатында ул болай дип яза: «... мин дә менә Казанны вә туган җирем булган Казан арты авылларын күреп, күп гыйбрәтләр вә хиссиятләр алдым. Мин хәзер Казанда инде. Уральскида вакыт шуны сөйли-сөйли авыз суларым кибеп бетте вә шунда бару хакында шигырьләр яздым Казанда инде!

Әлхәмделиллаһи! Монда күңелле. Дус-иш, зыялылар күп, сөйләшәбез, көлешәбез, укыйбыз»[75].

Абыйлары аркылы булса кирәк, Галимҗан да Г. Тукай белән якыннан аралаша башлый. Яшь егеткә Тукайның тәэсире зур була. Галимҗан үзе дә шигырьләр, хикәяләр яза.

Шәрәфләрнең уллары, кызлары, оныклары шул чорның истәлекләрен изге ядкарьләр итеп саклыйлар. Әсма Шәрәф, Сания Шәрәф, Җәвад Тәрҗеман, Габбас Тәрҗеман, Энҗе Сәгыйтова, А. Әминова һәм башкалар бу хакта язып чыктылар. Милләтнең киләчәге өчен үз тормышларын аямыйча көрәшүчеләргә һәйкәл куелса, бертуган Шәрәфләр дә моңа бик лаек.

Шәһретдин Шәрәфнең кызы Сания шактый гына кызыклы материаллар саклап кала алган. Аларга килгәч, Тукайлар, Шәрәфләр дөньясына кергәндәй тоела. Ул алар турында әтиләреннән ишетеп калганнарны түкми-чәчми сөйли, еш кына: «Менә бу урындыкка Тукай утырган, Сез эчә торган чынаяктан Тукай эчкән»[76],— ди.

Шәһер Шәрәф тарафыннан язылган Мәрҗани биографиясен һәм аның башка китапларын кулга алабыз. Нинди сихри юллар... Гомер буе кириллицада эш йөрткәнлектән бик акрын укыла: «Мәрҗани», «Асхаб кирам» ... Узган тарихыбыз гарәп хәрефләре белән язылган, ә без аны

юньләп укый дә белмибез. Бу — олы фаҗига. Галимҗан Шәрәф 1926 елда, ә абыйлары әле XX гасыр башында ук шулай булачагын исбатлаганнар иде. Бүген исә тагын латинчалык белән саташучылар юк түгел. Имеш, анда латин бит, тегендә латин... Цивилизациядән артта калабыз... Бәлки, яңадан Шәрәфләрнең киңәшен тыңлап карарга кирәктер?

РЕВОЛЮЦИЯ ҺӘМ ЯЗМЫШ

1917 елның 1 марты. Кояш шактый кыздыра. Яз җилләре белән Петроградтагы хәбәрләр дә Казанга килеп җиттеләр. 2 март көнне театр мәйданында студентлар, эшчеләр җыелган иде. Казанда да кызу көннәр башланды. Революция ташкыннары бик күпләрне мәйданга чыгарды. Милли азатлык, ирек өчен көрәш башланды.

Шәрәфләрнең хыялы — төрек-татар мәмләкәтен төзү иде. Гыйльметдиннең матбагасы да шул юнәлештә эшләп килде. Революция фаҗигаме яисә без белмәгән берәр яңа цивилизациягә илтүче юлмы? Бу сорау күпләрне кызыксындырды, ә кызыксынмаганнары сукырларча бөтен кайгысын, теләген һәм өметен революция белән генә бәйләде. Нигә шатланмаска, нигә бу шатлыктан кул чапмаска? Патша хөкүмәте мәңгегә мәтәлде бит. Татар халкы өчен бу зур шатлык иде, әлбәттә. Әле Тукайлар, Ямашевлар белән бер түгәрәкләргә йөргән чакларда ул мәсьәләләр уртага салып сөйләшенде.

Гыйльметдин Шәрәф өчен барысы да ачык иде. Кайда эшләргә, кемнәр белән барырга икәнен ул инде күптән хәл иткән. Абыйсы Шәһәргә баргач та ул бу турыда сүзне кыска тотты:

— Мин бер партиянең дә әгъзасы булырга теләмим, синең фикер ничегрәк, абый? — диде ул, өлкән абыйсына сүз кушып.

— Берсе дә пәйгамбәрләр дөньясыннан түгел, энем,— диде Шәһәр Шәрәф.— Аллаһ да син үзең уйла, аннан «абый әйтте», дип тегенди-мондый сөйләнүләр булмасын. Тарих укытучысы, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең җитәкчесе дөрес фикер йөртә, әмма ул авыр юлга, большевиклар белән көрәшү юлына илтәчәк иде.

Партияләр белән генә түгел, патшаның үзе белән дә тартышкан Гыйльметдин шикләнмәде, үз көченә ышанды. Әмма булачак дәүләтнең татар дөньясы өчен патша хөкүмәтеннән дә явызрак булачагын ул чакта абайламадылар.

Гыйльметдиннең күңелен бер нәрсә борчый иде: ничек итеп халыкны бердәм итәргә һәм яңа көрәшкә күтәрергә? Шушы мәсьәлә аны 7 мартта мөселманнар җыелышына китерә. Анда «мөселман эшләрен башкару өчен» Казан Мөселман комитеты төзелә. Аңа әгъзалар булып Газиз Гобәйдуллин, Нәҗип Хәлфин, М. Корбангалиев белән Гыйльметдин Шәрәф тә сайлана. Әлеге демократик оешма: «Бөтен җирләрне халык кулына түләүсез бирергә!» дигән карар чыгара. Шулай ук катгый рәвештә сугышны бетерүне таләп итәләр. Әлеге оешманың эшендә Гыйльметдин Шәрәф актив катнаша, киңәшләшә.

Казанда, Мөселман комитеты белән бергә диярлек, 10 мартта Мөселман хәрби комитеты да төзелә. Шушы чордан башлап Г. Шәрәф М. Вахитов, Ш. Әхмәдиев һәм башка актив революционерлар белән аралаша, сүз көрәштерә. Аның күңелен гел бер нәрсә борчый: «Нигә төрле партияләргә бүлгәләнергә, безнең көчебез бердәмлектә бит. Безгә милли азатлык кирәк, ә аннан соң үзара аңлашырбыз»,— дип уйлый ул. Әйтергә кирәк, ул гына түгел, алдынгы татар интеллигенциясенең күп кенә вәкилләре шул фикерне алга сөрә, әмма күпчелек бүгенгелек күзлегеннән карап, сыйнфый көрәш белән мавыгып, «сул» партияләргә иярә. Аяныч хәлләр Гыйльметдинне нык борчый. Шушы борчылулар аны 16—17 августта Казан губернасы Милли Шурасына китерә. Ул анда үзенең фикердәшләре Газиз Гобәйдуллин, Нәҗип Хәлфин, Фуат Туктаров, М. Корбангалиев, Х. Сафиуллин, Касыйм хәзрәт Салихи белән бергә Милли Шураның төп бүлегенә сайлана.

Милли Шура, Мөселман комитеты кебек үк, бер мәсьәләне уртага куя: берләшергә, көрәшергә, ирек яуларга.

Казанда шактый дан казанган Приказчиклар союзы, Мөселман социалистлары комитеты, Хәрби комитет үз юллары белән китеп Мөселман комитетына түгел, большевикларга, «сул» эсерларга кул сузалар. Җәй буе оешмалар арасында «Милли фонд»ның акчасын файдалану турында көрәш бара. Әлбәттә, Мөселман комитеты аны бөтен милләт мәнфәгатьләре өчен генә файдаланырга тырыша. Ләкин аңа каршы үтә кырыс эчтәлекле мәкаләләр басыла. Мәсәлән, М. Вахитов болай ди: «И совести у вас нет, и чувств гражданских не имеете! Не социалисты разъединяют мусульман, их разъединяете вы — рабы богачей! Ваши действия — глубокое неуважение по отношению к крестьянам и самый большой позор для демократии.

Чтобы покончить, вырвав с корнем, с произволом и обидами, Мусульманскому комитету необходимо переиз-

брать свой состав на демократических основах, ввести туда людей из народа, а фонд, именующий себя «националь-ным», должен перейти в ведение демократии»[77]. Әлбәттә, эшчеләр белән крестьяннар милләт мәнфәгатьләренең иҗтимагый мәнфәгатьләрдән өстенрәк булулары турында-гы озын-озын аңлатуларга караганда кыска һәм ачык итеп әйтелгән шигарьләрне тизрәк кабул итәләр. 1917 елның көзендә күпчелек большевиклар, социалистлар сул эсерлар ягына авыша. Шуңа күрә Мөселман комитетының да, Милли Шураның да эшләре бик авырлаша. Ноябрь аенда Казан Мөселман комитеты инде бөтенләй җимерелү хәлендә була. Ф. Туктаров үзен рәислектән алуларын сорый, ә Гыйльметдин Шәрәф, Н. Хәлфин һәм башкалар бу комитеттан чыгулары турында игълан итәләр.

Әлбәттә, кемнең дөрес юлда булганлыгын без бүген әйтә алабыз. Дөреслек ул бер генә кеше тарафыннан әйтелсә дә, дөреслек булып кала. Моңа Гыйльметдиннең милләт мәнфәгатьләре өчен алып барган көрәш тарихы да бер мисал булып тора. Бәхетсезлеккә каршы, әлегә кадәр бу тарихны без өйрәнә алмадык. Бу хакта язылган калын китаплар, зур мәкаләләр бер яклы гына булып, милләт өчен булган көрәшне «национализм» сүзе белән генә очлап куйдылар.

Нечкә күңелле, сизгер кеше буларак Гыйльметдинне бу таркаулык нык борчый: милләт мәнфәгатьләре икенче, өченче планда калып, бөтен ышаныч Советларга күчә. Ул Вахитовлардан, Якубовлардан аерыла, ә күңеле белән большевикларга, эсерларга, социалистларга ышана алмый. Бу, әлбәттә, табигый иде, чөнки Гыйльметдин төпле, зур акыл иясе буларак, интуицияле кеше була. Тәҗрибәсе дә бай һәм күпкырлы иде. Әлбәттә, гади кеше буларак, ул Ленинның, большевикларның үзбилгеләнү шигаренә ышангалап куя, әмма бу сукыр ышаныч булмый. Г. Шәрәф моңа тыныч, салкын караш белән карый. Ильяс Алкин, Фуат Туктаров, Садри Максуди һәм башка эшлекләләр белән большевикларның санашмаулары, татар социалистларының, эсерларының алар белән исәпләшмәүләре аның шикләрен үстерә, ныгыта төшә.

Шулай итеп мөселман, татар-башкорт дөньясында берничә агым барлыкка килде: берәүләр большевикларга иярде — «интернационал» дип кычкырды, икенчеләре — «милләт-милләт» дип сөрән салды. Милләт мәнфәгатьләрен алга сөрүчеләр һәм партиясезләр соңгысына сыендылар. Беренчеләр диктатура юлы белән милләткә, үзләренә үзләре каршы киттеләр, ә икенчеләре демократия

юлын сайладылар. Әмма диктатура булган җирдә демократиягә урын юк. Шуңа күрә диктатура ныгый башлау белән милләтнең шушы ике юл белән китүче асыл егетләре бер юлда очраша башлады. Ул төрмә, лагерь юллары иде. Диктатура аларны «оештырды», бер агым итеп кабергә озатты.

Революциянең шулай китәчәгенә ишарә ясаган Фуатка, Гыйльметдингә һәм Газиз Гобәйдуллинга нигә баш имәскә?

Фактлар юк дияргәме?

Менә беренчесе: 1918 елда, 1906 елдан бирле милләт мәнфәгатьләрен кайгыртып килгән, Тукайны зур юлга әйдәгән «Мәгариф» нәшрияты ябыла. Типография дә, Гыйльметдин һәм башкалар да диктатурага кирәкми иде инде.

Икенчесе: абыйсы Шәһер Шәрәф эшләгән данлыклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе яшәүдән туктатыла. Башкалары белән дә шулай эшләнә.

Өченчесе: акрын гына мәчетләр ябыла бара. Аларның бигалары төрле остаханәләргә, складларга бирелә.

Дүртенчесе: Гыйльметдин Шәрәф, аның абыйлары Шәһер, Борһанетдин һәм энесе Галимҗан Шәрәфләрнең тормыш юлы, фаҗигале үлемнәре.

Гыйльметдин Шәрәфнең революциядән соңгы тормыш юлын күздән кичерик.

Ул югалып калмый, төрле профессияләрне өйрәнә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә бәйрәмгә әзерләмәделәр, ә тормышның үзен җитәкләргә өйрәтәләр иде. Барысы да ярап куя. 1921 елда Гыйльметдин Шәрәф тәэминатчы булып эшли, ә 1922 елда Казанда татар әдәбиятын бастыру эшләрен җитәкли. Озак та үтми республика хөкүмәте аны яңа өлкәгә күчерә. Ул татар банкын төзү өлкәсендә эш башлап җибәрә. Татар банкы ачылгач, аны Мәскәүдә акционерларның гомуми җыелышында бертавыштан банкның идарә әгъзасы итеп сайлап куялар. Монда аңа 1926 елга кадәр эшләргә мөмкинлек бирелә. Шушы чорда Гыйльметдин шактый изге эшләр дә эшләп өлгерә, шул исәптән туган авылы Аксуда мәктәп ачуга зур өлеш кертә.

Шушы чорда ук инде Гыйльметдин Шәрәфкә карата ГПУда шактый гына материаллар тупланган була. Аларның берсе «Совершенно секретно» грифы астында «Ип. Бузулуковка» дип адресланган. Бу рапорт формасындагы документ тулысынча Шәрәфләр гаиләсенә багышланган. Анда Гыйльметдингә карата мондый юллар бар: «Гыйльметдин Шараф, будучи также весьма образованным молодым представителем фамилии Шараф... проявлял необыкновенные способности и знания в этом деле (нәширлек

эшендә.— *Р. В.*). Г. Шараф состоял сотрудником у многих периодических изданий и газет. ... становясь более и более самостоятельным в области материальной, в настоящее время его можно уже видеть в полном смысле этого слова — «книжным нэпманом»[78].

Бу — Гыйльметдиннең генә түгел, ә бөтен ил өстендә сталинизм күләгәсе җәелә башлаган вакыт. Әлеге чор Гыйльметдин өчен яңа тентүләр, кулга алулар белән башлана. Әле 1922 елда ук Тат. ОГПУ начальнигы П. Журавлев үзенең «Татарлар арасындагы совет дәүләтенә каршы группировкалар һәм мөселман буржуазиясендә национализм тенденцияләре» дип аталган «хезмәтендә»: «В общем и целом в данный момент ТР находится в первой стадии нарастающего национального движения. Последнее, не находясь под руководством тактического единого центра, проявляется сейчас в условиях ТССР в отдельных шагах со стороны социальных групп татарской буржуазии и духовенства, направленных к захвату идейного влияния на массы»,— дип яза[79]. Башка белешмәдә исә болай диелә: «Необходимо по возможности устранить из руководящих постов лиц, вредящих нашей идеологии, вроде Шараф Г., Бикуллов Ибрагим, Норкин Загид, используя их лишь в техническом направлении»[80]. Шулай ук түбәндәге юллар сакланган: «Связь татарской интеллигенции с духовенством осуществляется главным образом через братьев Шараф, связанных родственными узами, начиная от рядовой муллы до муфтия ЦДУ Фахретдинова включительно»[81].

Әлеге документларда Гыйльметдиннең нигә кулга алынуы һәм төрмәгә озатылуы ачык чагыла.

Шәрәфләрнең «гаебе»н милләт мәнфәгатьләрен генә кайгыртуга әйләндереп калдырсак, дөрес булмас. Һичшиксез, алар сталинизмның канлы шәүләсен, аның мөселманнарга карата аяусыз икәнлеген беренче булып сизгәннәр. «Шәрәфлек»не юкка чыгару — ул милләтне юкка чыгару сәясәте.

«МИНЕМ СУДЬЯМ ХАЛЫК БУЛЫР...»

Үз гомерендә алдарга өйрәнмәгән, бисмилласыз эш башламаган Гыйльметдин сорау алулар вакытында да дөресен сөйләде, чөнки аның кыңгыр эшләре юк иде. Бар тырышканы милләт өчен, гаилә өчен, дус-иш, туганнар өчен булды. Башка милләтләргә дә каршы бармады, сөйләмәде. Акча махинацияләрендә ул үзен гаепле дип санамады, чөнки

1922 елның апрелендә чыккан Совет декреты акчаны саклауны тыймый иде. Аның студентларга да бернинди стипендияләр биреп торганы юк иде. Бу гаепләүләрнең урынсыз икәнлеге көн кебек ачык булгангадыр, аңа карата булган мөгамәлә дә әле бик үк кырыс булмаган кебек тоела, әмма ГПУ аңа «бүләкнең» бик зурын әзерли: ничек кенә булса да аны Казаннан куарга!

Башта йомшак җәяләр. Сораулар да гадәттәгечә—сорау алу формасында гына бара. 1927 елның 14 октябрендә хәтта ике көнгә, Галимҗан Шәрәф җаваплылыгына тапшырып, иреккә дә чыгарып торалар. Аннары инде конвой белән Мәскәүгә ОГПУның Бутырка төрмәсенә озаталар.

Татарстандагы сталинизм ялчылары, Мәскәүгә озаткач та, Гыйльметдин Шәрәф язмышы белән кызыксынуны дәвам итәләр. ОГПУның бүлек начальнигы вазифаларын үтәүче Николаев өлкә комитетының беренче секретарена, ОКК президиумына, ОГПУның Шәрекъ бүлегенә Г. Шәрәф турында даими хәбәр итеп тора. Ул: «Эре коммерсант Г. Ш. фатирында шактый алтын-көмеш акчалар табылды һәм тартып алынды»,—ди. «Имея громадное денежное состояние и пользуясь большим авторитетом,—дип яза Николаев,—Шараф имел сильное влияние на татарскую интеллигенцию, восстанавливая таковую против сов. власти и ВКП (б). С этой целью он поддерживал материально по 50 руб. обращавшихся к нему за помощью. Кроме того, имеет большие связи с видными антисоветскими личностями, в частности с мусульманством; являясь родственником муфтия ЦДУ, он вел беспрерывную работу и на этом фронте против политики компартии и т. п. Вообще характеризуя личность Шарафа как элемент, враждебно настроенный по отношению к сов. власти, необходимо подчеркнуть, что проживание его на свободе было бы крайне нежелательно, тем более учитывая обстановку в настоящий момент... Со стороны отдельных членов ВКП (б) поступили ходатайства с просьбой об освобождении Г. Шарафа на свободу под их поручительство». Николаев бик пөхтә итеп ул коммунистларның исем-фамилияләрен, эш урыннарын яза. Менә ул курку белмәс кешеләр: Гали Вәлиев, Закир Исхаков, Исмәгыйль Ибраһимов, Сабирҗан Саттаров, Сәлах Вәлиев. Әлбәттә, Г. Шәрәфнең башка язучылары да булган, алары да безгә мәгълүм. Эш очраклы рәвештә генә ҮК ка барып җитми. Милләт мәнфәгатьләрен кайгыртучылар, намуслы коммунистлар, партиясезләр аның тормышы өчен көрәшәләр.

ОГПУны да, өлкә комитетын да «Бертуган Шәрәфләрне

ни эшләтергә?» дигән сорау борчый. Менә шуны дәлилләүче бер документ.

«Бик тә яшерен»
Күчерелмә
ВКП (б) Өлкә комитеты
ТССР 0101ц
1927, 8 октябрь ВКП (б) ҮК ип. Молотовка
ОГПУ ип. Менжинскийга.

Монда, Казанда, ОГПУның Татарстан бүлеге тарафыннан урындагы буржуаз милләтче даирәләренең иң күренекле вәкиле Шәрәф кулга алынган иде. Ул кешедән алты пот авырлыгында алтын һәм көмеш акча алынды.

Аның кулга алынуы татар буржуаз даирәләре арасында төрле сүзләр, дулкынланулар кузгатты.

Бу мәсьәлә буенча миңа бик күп мөрәҗәгать итүләрдән соң, мин ип. Габидуллиннан (бу вакытта ул Халык комиссарлары Советы рәисе), Шәймәрдәновтан (Татарстан үзәк Башкарма Комитеты рәисе); Әхмәтшиннан (ОКК рәисе) һәм Панютиннан (прокурор), ОГПУның Татарстан бүлеге начальнигыннан бу эш турында бергәләп тыңлауларын һәм үз фикерләрен әйтүләрен сораган идем. Алар, аны тыңлап, кулга алу һәм сорау фактын дөрес дип таптылар.

Хәзер монда «Мәскәүдә аны азат итәргә җыеналар икән», дигән мәгълүматлар килә башлады.

Мәскәүнең бу эшчәнлегеннән урындагы органнарның дәрәҗәсен төшерүдән башка берни дә килеп чыкмаячак. Бөтен Печән базары буенча (татар буржуазиясенең тупланган урыны) «урындагы властьлар Шәрәфне ялгыш кулга алганнар, ә Үзәк аны азат иткән» дигән хәбәр таралачак. Бу даирәләр Шәрәфне кулга алу Өлкә комитеты секретаре шәхесенә бәйле, ягъни минем директива буенча эшләнгән дип исәплиләр. Чынлыкта исә андый хәл булмады: мин бу эштән читтә торырга тырыштым.

Әгәр Мәскәү, чыннан да, Шәрәфкә мөнәсәбәттә шундый миһербанлык һәм йомшак күңеллелек күрсәтергә уйлый икән моның урындагы органнар өчен бик уңайсыз хәл китереп тудырачагын исәпкә алуыгызны үтенәм.

Ком. сәламе белән, ВКП (б) ның Татарстан Өлкә комитеты секретаре Хатаевич М.»[82].

«Карга карганың күзен чукымый» дигән мәкаль дөрестер. Казан каргаларын Мәскәү каргалары да бик яратып тыңлыйлар. Нәтиҗәдә казанлыларның теләге гамәлгә ашырыла, Г. Шәрәфкә карата бернинди дә миһербанлык күрсәтелми. Бу исә «Гаепләү»дә дә бик ачык күренә. Анда болай диелгән:

«1927 г. 1 ноября, уполномоченный 2 го отделения ОГПУ Бирн, рассмотрев следственное дело № 49616 по обвинению Шарафа Гыйльметдина Шарафетдиновича, нашел, что распорядитель лесопромышленного т-ва «Урман» обвиняется в антисоветской деятельности, направленной к срыву нашей экономической политики в Татарии, используя для этого целый аппарат Тат. гос. банка, в котором являлся членом коллегии и участвовал в руководстве интеллигенцией и духовенством в борьбе против Советской и партийной практики в Татарии.

В последнее время антисоветская деятельность Шарафа приняла такие размеры, что ряд работников выступил в печати о том, что «шарафизация» как бы то ни было должна прекратить свое влияние в Татарии, по сему.

ПОЛАГАЛ БЫ

дело за № 49616 по обвинению Шарафа Гыйльметдина Ш. в преступлениях, предусмотренных статьями 58 п. 10-11 и 58 п. 10-11 и 58 7 ч. 1 УК, передать на рассмотрение Особого Совещания при Коллегии ОГПУ.

Справка: Обвиняемый содержится в Бутырской тюрьме с 18/10 1927 г.

Уполномоч. 2 отд. ВО: Бирн

Согласен нач. 2 отд. Алмаев

Утв. Нач. ВО ОГПУ Петросян»[83]

Бу документка мондый резолюция салынган: «Дело просмотрено, обвинение, предъявленное Шарафу, материалами дела не подтверждаются. Пом. прокурора Верховного суда СССР 4.11.27 г.»

Шуңа да карамастан, 18 ноябрьдә бу эш Махсус киңәшмәдә тикшерелә. Анда түбәндәге карар кабул ителә: «Выслать в Орловскую губернию сроком на три года, по амнистии от 6 ноября 27 г. срок наказания сократить на одну треть.

Войти с ходатайством в Президиум ЦИК СССР о конфискации отобранных ценностей. Дело сдать в архив»[84].

Конфискациягә эләккән байлык шуннан гыйбарәт була: 965 сум алтын акча, 4.667 сум көмеш тәңкә. Бу суммаларны конфискацияләүне сорап язган документ январь аенда раслана.

Сөргендә, ГПУ хезмәтчеләренең доносларына караганда, Гыйльметдин кешеләр белән элемтәгә кермичә генә яши. Советларга каршы көрәшүдә гаепләрлек «фактлар» турында Үзәккә хәбәрләр килеп тора.

Шәрәфләр, бигрәк тә Гыйльметдиннең язмышы ОГПУның Татарстандагы әһелләренең игътибар үзәгендә

була. ТООГПУ начальнигы Кандыбин ОГПУның Мәскәүдәге Шәрекъ бүлегенә хат җибәрә:

«По имеющимся у нас сведениям, в скором времени кончается срок ссылки административно-высланному в 1927 г. по постановлению коллегии ОГПУ — Шараф Гильмутдин Шарафутдинович.

Шараф Гыйльметдин является *наиболее опасным элементом из числа всей татарской буржуазии Т. Р. и к числу равных ему по своей степени опасности едва ли кого можно отнести.*

Опасность Гильмутдина Шарафа велика еще и потому, что он связан в ТР родственными узами с представителями всех антисоветских прослоек общества. Поэтому *национальная интеллигенция превратила Шарафов в узловые пункты, откуда она черпала и распространяла дальше все выдвигаемые национальными элементами моменты.*

Исходя из всего изложенного Тат. отдел ОГПУ ходатайствует о вхождении в коллегию ОГПУ с соответствующим ходатайством о лишении прав проживания в пределах Тат. республики Гильмутдина Шарафа по окончании срока ссылки.

Нач. ТООГПУ Кандыбин.

Нач. III отд. ОГПУ Музаффаров».

Казан ялчыларының үтенече ОГПУ коллегиясе тарафыннан бу юлы да хуплап каршы алына һәм 14 июньдә шушындый карар кабул ителә. Анда: «Гыйльметдин Шәрәфне өч елга Татарстанда һәм Башкортстанда яшәүдән мәхрүм итәргә»[85] диелгән.

Бу юлы ул Ленинградка юл тота. Монда Гыйльметдин каравылчы, бухгалтер, тәэминатчы булып эшли. Казандагы Хатаевичлар, Кадушиннар, Кандыбиннарның «техник өлкәдә генә файдаланырга» дигән күрсәтмәсе урындагы властьлар тарафыннан бик төгәл үтәлә. Аңа беркайда да тынычлык бирмиләр. Бер эштән икенче эшкә күчәргә туры килә: я штатлар кыскартуга эләгә, яисә конторааларын бөтенләй ябалар... Шуңа күрә ул 9 ел эчендә 15 эш урыны алмаштырырга мәҗбүр була.

ЗИНДАННАН ЗИНДАНГА

Менә инде тугыз ел Гыйльметдин Шәрәф патшалар яшәгән шәһәрдә михнәт чигә. Татар халкының мәшһүр китапчысы өчен яшәү чиге көннән-көн кыскара. Әмма күңел нәрсәгәдер, кемгәдер ышана, яшәү рухы сүнми.

1938 елның 23 марты. Шәрәфләр өчен аның төне дә көне дә бер—караңгы һәм кайгылы. Менә нәкъ 1937 елның 23 марты төнендә Казанда Галимҗан Шәрәф кулга алынган иде бит. Инде бер ел узды. Шәһер белән Борһан да елдан артык Уфа һәм Казан төрмәләрендә газап чигәләр...

«Ленпромстрой» бухгалтеры Гыйльметдин Шәрәф, Почта авылыннан кайтканда, исәп-хисапларны онытып, үзләренең авыр язмышлары, милләт язмышы турында уйланды. Күз алдында туган авылы Аксу, әтисе, әнисе, бала чаклар... Күпме гомер узган. Әйтерсең лә кичә генә әтисе Шәрәфетдин белән сөйләшеп утырганнар. Өчәүләшеп бергә Казанда чагында карточкага төшкәннәр иде.

Ул беркемгә дә игътибар итмичә өенә атлады. Артына әйләнеп карамады. Ул белә, инде күптән аның артыннан җентекләп күзәтәләр...

Рәхимәсенең тәмле ашларын, чәйләрен эчеп, ятып йоклап кына китә башлаган Гыйльметдинне уяттылар.

— Тор, Гыйльметдинем, тагын килделәр ахрысы, хәзер ишекне ачам,— дип Рәхимә ханым ишек төбенә узды.

Ишек ачылуга аны-моны сорап тормыйча НКВД киеме кигән ике кеше эчкә узып, Гыйльметдин янына ук килеп бастылар. «Без өйгә кергәндә гел аяк киемнәрен салып керә идек»,— дип уйлап куйды Гыйльметдин.

— Рәхим итегез инде, әфәнделәр. Нәрсә, көндез килеп булмас идеме?—диде ул тыныч кына.— Качып йөрергә без бит җинаятьчеләр түгел...

— Күп сөйләнмәгез! Минем фамилиям Пономарев, менә сезне кулга алу һәм тентү ясау өчен рөхсәт кәгазе,— Ул Гыйльметдингә ордер сузды. Анда «№ 4 (449) 21 марта 1938. Сотруднику управления госбезопасности УНКВД по ЛО Пономареву на производство обыска и ареста Шарафа Гильмутдина Шарафетдиновича. Ул Шкапина, д. 18, кв. 12. Нач. УНКВД по ЛО подпись, Нач. 2 отд. подпись»[86] дигән юлларны шәйләп була иде.

Рәхимә ханым, кызы Шәфика һәм А. Н. Бабанин бу вакыйганың шаһитлары булдылар.

— Әйдә, тентеп карагыз,—диде сүлпән генә Гыйльметдин.— Күрерсез 21 ел эчендә (революциядән соң) абыегызның ничек баеганын.

Бөтен өйнең астын өскә китергәннән соң Пономарев бер фотоальбом һәм берничә хатны гына сумкасына салды.

— Менә шулай, әфәнделәр, хәзер абыегызның бөтен милке шул инде, анысы да сезнең кулда.

— Атла,—дип җикеренде Пономарев, а то...

Кызы Шәфикане, хатыны Рәхимәне тиз генә икесен бергә

кочып үпте. Хушыгыз, кадерлеләрем! Әйтер сүзләре бугазда буылып калды. Әйтә алмады. Өчесенең дә күзләреннән мөлдерәп яшьләр ага иде. Бу юлы аерылышу бик авыр булды...

Кулга алуның өченче көне дигәндә, 26 мартта, беренче допрос уздырдылар. Аны шул ук Пономарев алып барды. Бик авыр сөйләшү булды бу көнне.

— Йә, тагын эләктегезме, татарская контра,— диде Пономарев Гыйльметдингә карап һәм беренче сорауны да бирде.

«*Сорау:* Сез Ленинградка кайчан килдегез?

Җавап: Мин Ленинградка Орелдан 1934 елда куылу срогым беткәч килдем.

Сорау: Сез Ленинградта яшәүче татарлардан кемнәр белән аралаштыгыз?

Җавап: Ленинградта мин Кәрим Сәгыйть белән аралаштым. 1936 елның җәендә ул НКВД тарафыннан репрессияләнде, ә аннан соң Гыйззәтуллин Фатыйх белән... ул да 1937 елның җәендә кулга алынды. Башка бәйләнешләрем булмады.

Сорау: Сезгә Кәрим Сәгыйтьнең узган тормышы турында нәрсә мәгълүм?

Җавап: Миңа шунысы мәгълүм, ул Татарстанда милли хәрәкәттә актив катнашты. Гаяз Исхакыйны яхшы белгән кеше... шуны да әйтергә кирәк, Кәрим Сәгыйть мөселман Учредительный мәҗлесенең вәкиле иде (Милли мәҗлес.— *Р. В.*).

Сорау: Кәрим Сәгыйть белән бәйләнешегезнең үзенчәлеге турында сөйләгез.

Җавап: Безнең бәйләнеш туганлык бәйләнеше генә...

Сорау: Сез дөресен сөйләмисез, безгә билгеле, сез аның белән контрреволюцион эш алып бару өчен бәйләнештә торгансыз. Дөресен сөйләгез!»[87]

Шушы сүзләреннән соң Пономарев кинәт кенә каты итеп зур йодрыгы белән Гыйльметдинның битенә китереп сукты. Гыйльметдин урындыгыннан егылып идәнгә төште. Акрын гына яңадан тора башлаган иде, следователь күн итекләре белән көчле итеп тибеп җибәрде. Авызыннан кан китте, һушсыз килеш Гыйльметдин беркадәр ишек төбендә ятты. Бик озакка сузылган «стойкалардан» соң тоткынның хәле бик авыр иде. Түзәрлек түгел... Нишләргә?

Аңына килгәч тә тактиканы үзгәртергә теләп: «Әйе, мин үземнең контрреволюцион эшләремне... яшерергә теләдем. Мин чыннан да контрреволюцион группа белән бәйләнештә тордым, бу эшкә мине 1935 елда ялладылар. Бу оешмада

Кәрим Сәгыйть, Даут Еникиев, Вәли Зәбиров, Фатыйх Гыйззәтуллиннар да бар иде. Мин Татарстанның бәйсезлеге өчен көрәштем. Соңрак мин Япония һәм Германия разведкасы файдасына эшләдем, Свирьская ГЭСын шартлатмакчы идем...» дип язылган кәгазьгә кул куярга булды. Әлеге сүзләр Пономарев тарафыннан алдан әзерләнеп килгән протоколда язылган иделәр инде, алар белән килешү генә иде бу. Пономарев бу юлы җиңде.

Әмма Гыйльметдин дә тиз генә бирешә торганнардан түгел иде. 1938 елның 11 декабрендә, беренче сорау алудан соң озак вакытлар узгач яңадан допроска алып киткәч, ул тыныч кына: «Мин бернинди дә контрреволюцион эшләр эшләмәдем, Совет дәүләтенә каршы көрәшү өчен беркемне дә ялламадым. Мин 26 мартта язылган протоколны ялган диеп саныйм»,— ди. Тикшерүченең «Ул вакытта ни өчен ялган күрсәтмәләр бирдегез?» — дигән соравына ул: «Следователь шушы фактларны гына раславымны көч кулланып таләп итте... ул мине кыйнады, сәгатьләр буе аяк өстендә тотты, ә күрсәтмәләремне мин ярым һушлы хәлемдә раслаганмын»,— дип җавап бирә. Шушы көннән башлап Г. Шәрәф НКВД белән көрәш юлына ныклап баса. Январь аенда булган (1939) сорау алуларда да ул бу фикерен кабатлый, әмма Абдулла Килдишевны, Гаяз Исхакыйны, Вәлидхан Таначевны, Гали Рәхимне, Ибраһим Мозаффаровны, Мөхетдин Корбангалиевны, Гаяз Максудовны, Зәки Вәлидине һәм Садри Максудины белгәнлеген яшерми. Бары тик Ильяс Алкинны якыннан белмәгәнлеген әйтә. Ул вакытлар өчен болары да зур кыюлык таләп итә иде. Гыйльметдин курыкмый...

Казанда нәкъ шушы көннәрдә тикшерүче Әхмәтов Ибраһим Мозаффаровтан сорау ала.

> *Тарихи белешмә:*
> Мозаффаров И. Ш. 1894 елда Казанда туган, ТАССР НКВДсы тарафыннан 1937 елның 26 декабрендә кулга алына. Өчлекнең карары белән 1937 елның 29 декабрендә атылуга хөкем ителә. Өчлекнең карары 1938 елның 26 августында 22 сәг. 30 мин. гамәлгә ашырыла[88].

Әлеге сорау алу вакытында И. Мозаффаров түбәндәге күрсәтмәләрне бирә: «Мин фронттан Казанга 1917 елны ноябрь ахырларында кайттым. Галимҗан Шәрәфнең «Милли Шураның» әгъзасы булганы һәм ул татар интеллигенциясе арасында зур абруй казануы миңа ул вакытта билгеле

иде инде. Г. Шәрәф 1917—1918 елларда «Идел-Урал штатын» төзү буенча зур эш алып барды. Шәрәф 1918 елны, аен хәтерләмим, егермәләп Казан купецларының кызларын җыеп алтын ука белән «Идел-Урал штатының» яшел төстәге флагына ярым ай һәм йолдызлар чиктерде.

1918 елда Ш. Галимҗан «Милли Шура» җитәкчесе Фуад Туктаров белән һәрвакыт аралашып торды. Соңыннан Ф. Туктаров эмиграциягә китте. Казанда «Болак арты республикасы» булганда аның бер җитәкчесе Ильяс Алкин иде. Ш. Галимҗан ул вакытта Болак арты республикасы территориясендә иде (ул вакытта Галимҗан абыйсы Гыйльметдин фатирында тора.— *Р. В.*), ул бөтен татарларны «Болак арты республикасы»на булышу өчен берләштерү өстендә эшләде».

11 январьда ул тикшерүче Батуллинга әйтә: «Мин Галимҗан Шәрәфнең абыйлары Борһан, Гыйльми, Шәһерләрне якын дуслар буларак беләидем. Шулай ук милли интеллигенция арасында да танышларым алар белән тыгыз бәйләнештә булганга, бигрәк тә Борһан, Гыйльми, Шәһерләрнең сүзләренә караганда, Галимҗан әле революциягә кадәр үк контрреволюцион юлга баскан һәм Совет властена каршы булган»[89]. Әлеге документ шулай ук Казаннан Ленинградка китерелә һәм Гыйльметдиннең эшенә беркетелеп куела. Өстәп шуны да әйтергә кирәк: сораулар хәтта кызы Шәфикадән дә, аны белгән П. Рогозиннан һәм Әмин Моракаевтан да алына, әмма аларның берсе дә Г. Шәрәф турында начар сүз әйтә алмыйлар.

1939 елның 14 январенда Г. Шәрәфкә тикшерү эшенең тәмамлануы хакында хәбәр итәләр. Аның эше Ленинград өлкәсе Хәрби трибуналына җибәрелә. Документ белән танышканнан соң ул судка Ф. Гыйззәтуллинны, И. Мозаффаровны һәм Гали Рәхимне чакыруны таләп итә, чөнки «гаепләү» башлыча аларның күрсәтмәләренә нигезләнгән була.

> *Тарихи белешмә:*
> Бу вакытта И. Мозаффаров инде күптән атылган. Шул сәбәпле ул судка килә алмый. Фатыйх Зиннәтулла улы Гыйззәтуллин 1903 елда Татарстанның Әлки авылында туган. 1937 елның 20 июнендә ул Германия файдасына шпионлыкта гаепләнә һәм 1937 елның 8 декабрендә атыла. Аның да килә алмаслыгы тикшерүчегә мәгълүм була, Гали Рәхим үзенең күрсәтмәләреннән баш тарта.

Соңрак аларның барысының да гаепсез икәнлекләре расланды. Шуңа да карамастан бернинди гаебе булмаган

Гыйльметдин Шәрәфкә карата булган «Гаепләү» 1939 елның 21 январенда раслана. Әлеге документны тулысынча бирү урынлы булыр:

«Утверждаю
Нач. управления НКВД ЛО
комиссар ГБ 2 ранга Гоглидзе

21 январь, 1939 год.

ОБВИНИТЕЛЬНОЕ ЗАКЛЮЧЕНИЕ
по делу № 44075238 г по обвинению Шарафа Гыйльметдина Шарафетдиновича.

Расследованием данного дела установлено, что Шараф Г. Ш. в 1936 году состоял участником контрреволюционной националистической группы в Ленинграде, созданной агентом японской разведки Каримом Сагидом.

В 1936 году в Ленинграде был завербован для разведывательной деятельности в пользу Германии агентом германской разведки Гиззатуллиным Фатыхом.

Являясь агентом германской разведки за период 1936—37 гг. собрал и передал через Гиззатуллина Ф. германской разведке секретные сведения о Свирьской ГЭС.

В 1936 году принял задание германской разведки организовать диверсионную группу на Свирьской ГЭС и в момент возникновения войны Германии с Сов. Союзом вывести из строя основные участки ГЭС.

На основании изложенного обвиняется:

Шараф Г. Ш. 1885 г. рождения, урож. Тат. АССР, Буинского района, по происхождению из крестьян, б/п, татарин, гражданин СССР, гл. бухгалтер стройтреста № 16, в том, что на протяжении ряда лет занимался шпионской деятельностью в пользу Германии, т. е. в пр. ст. 58-6 УК РСФСР.

Виновным себя в начале следствия признал, а в последствии от своих показаний отказался. Изобличается показанием Гиззатуллина Ф., Музаффарова И. Ш.

ПОЛАГАЛ БЫ

Следственное дело № 44075—38 г. по обвинению Шарафа Г. Ш. направить на судебное рассмотрение в Военный трибунал ЛВО.

Обвинительное заключение составлено в Ленинграде 4 января 1939 г.

Пом. опер. уп. IV отд. Пашков
Нач. IV отд. сержант Райхем

«Согласен»: зав. нач. II отд. УНКВД ЛО мл. лейтенант Кулаков.

Справка:

1. Обвиняемый Шараф Г. Ш. содержится в тюрьме № 1 с 23 марта 1938 года.

2. Вещественных доказательств по делу нет.

3. Личные документы обвиняемого Г. Ш. Шарафа сданы в 1-й спец отдел УНКВД ЛО. Список лиц, подлежащих к вызову в суд...

Пом. опер. IV отд. Пашков».[90]

Тиздән Хәрби прокуратура хезмәткәрләре Гыйльметдин Шәрәфнең эшен СССР НКВДсы каршындагы Махсус киңәшмәгә тапшыру өчен кире кайтаралар. Әлбәттә, ялган фактларга таянып төзелгән «гаепләү»дән шикләнгән хәрби прокурор Шмулевич эшне астыртын гына «очлау» нияте белән эшне судка бирми. Нәтиҗәдә аларның теләге тормышка ашырыла һәм 1939 елның 2 июлендә Махсус киңәшмә утырышында Г. Шәрәфнең эше карала. Ул эш белән төзәтү лагерьларына (ИТЛ—*Р. В.*) 8 елга хөкем ителә. Нәтиҗәдә «халык дошманы» дип аталган Г. Шәрәф Себергә озатыла. Ул үзенең соңгы елларын (1940—1942) Красноярск краенда Решеты станциясеннән 12 чакрым ераклыкта уздыра. Монда килеп беркадәр вакыт узгач (1940 елның 4 апрелендә) ул СССРның эчке эшләр министры Л. Бериягә хат яза. Ул анда Махсус киңәшмә тарафыннан үзен гаепсезгә, ялган фактлар нигезендә хөкем итүләре хакында хәбәр итә. Тикшерү органнарының закон бозып эш итүләре турында да язарга курыкмый. Соңыннан чыннан да Шәрәфне эзәрлекләгән Ленинград өлкәсенең УНКВД начальнигы Перельмутр югары суд тарафыннан хөкемгә тартыла, Пономарев эшеннән куыла. Бу бары тик 50 нче елларның ахырында гына була әле.

Г. Шәрәфнең хатына бернинди дә җавап алынмый. Хат аның эшенә тегелеп куела, хәзер ул безгә дә мәгълүм.

Красноярск янындагы лагерьда Гыйльметдин якташы, кодасы Хәмит Хәкимов белән очраша. Хәмит ага И. Сталин үлгәннән соң (1955 елда) туган якларына кайту бәхетенә ирешә һәм Гыйльметдин Шәрәфнең үләр алдыннан әйтеп калдырган васыятен үти. Ул Гыйльметдин Шәрәфнең кызы, Ленинградта яшәүче Шәфика Гыйльметдиновнага ике хат язып җибәрә. Аларда Г. Шәрәфнең соңгы көннәре һәм фаҗигале үлеме бәян ителә. Без әлеге хатлардан өзекләр тәкъдим итәбез.

Беренче хат

«Многоуважаемая Ш. Г.!

Я в период с 1940 по 1942 гг. был близким другом-приятелем Вашего покойного отца Гыйльметдина абый; он скончал-

ся 5/1—1942 г. в Красноярском крае, на лагерьном пункте, находящемся в 12 км от ст. Решеты и похоронен на кладбище для заключенных; смерть наступила на пятый день с начала болезни, наименование болезни—пиллагры...

Гыйльми абый пользовался уважением среди всех заключенных, работу он выполнял посильную в соответствии с здоровьем, особенно не голодал.

Что же еще Вам рассказать о нем; помню, что задолго до смерти он получил письмо от сына, т. е. от Вашего брата.

Я свое маленькое послание пишу по просьбе Гыйльми абый, который мне говорил: «Хамит, если сохранишь жизнь, то обязательно расскажи обо мне... я чувствую близость своей кончины...»

И так, разрешите Вам сообщить в двух словах о себе; я сел 13.V.1937 г. и освободился 13.IV.55 г.

До заключения жил в Казани, хорошо знал семью Булатовых и братьев Шараф (Галимзян и Бурган).

С получением сего письма прошу Вас уведомить о получении. На интересующие Вас вопросы могу ответить.

С приветом Хамит. 4.III.1956 г.»

Икенче хат

«Здравствуйте, Шафика Гильмеевна!

Ваше письмо от 26 марта сего года получил, за что большое спасибо.

С Гыйльми абый я познакомился летом 1940 г. Как-то проходя мимо одного барака, за долгое время впервые услышал говор на родном языке, около барака сидели двое: Ваш отец и т. Вахитов Габбас Нуриевич—доцент кафедры ботаники КГУ.

Вот с этого дня мы стали неразлучными друзьями, пока нас не разлучили, а эта разлука случилась, приблизительно X или *XI/41 г., т. е. Гыйльми абый отправили в инвалидный лагерный пункт (с начала этот лагерный пункт назывался «третьим инвалидским», затем «десятым», «шестым» и наконец «первым» ОЛП Краслага МВД СССР) где он и скончался от пеллагры...*

Гыйльми абый до своей смерти ровно один месяц работал хлеборезом и заболел 31.XII.41 г. и скончался 5.I.42 г. (умирающий уходит от жизни при полном сознании, у больного бывает нормальная температура...)

Мне о смерти Гыйльми абый сообщили наши общие дру-

зья — старики-узбеки, которые лежали с ним в одной палате и Ваш отец этих узбеков просил, чтобы они о его кончине сообщили мне, а я — Вам.

Вами полученная бумага о диагнозе и дате смерти не правдоподобная, ибо в те годы смертность была очень большая (в том лагпункте на 650—700 чел. контингента ежедневно умирало 35—40 чел., поэтому своевременно и правильно не успевали устанавливать диагноз и часто случалось, что спустя несколько дней или даже месяцев писали акт о смерти, а диагноз брали с потолка, при том зав. больницей была молодая и неопытная женщина и она могла ошибаться).

Гыйльми абый в Краслаг приехал из Котласа; с того этапа сохранились люди, которые Вашего отца знали. Например, еще помню фамилии: Пенсон Рахильд Давыдович, Роза Львовна Загленд, Певзнер Хая Исаковна (первые две — врачи, где-то в Москве или в Киеве работают).

Осенью 1941 г. у Гыйльми абый украли хороший пиджак. Зная даже кто украл, он об этом не мог донести, а лишь переживал внутри.

Очень интересовался событиями: положением на фронте; когда немец начал бомбить Ленинград, он однажды из сундука вынул письма от Вас, перечитав кое-какие из них, мне показал фото (снимок Вашей матери за семейным столом) и тогда он рассказывал что Вы живете около Балт. вокзала на 7 этаже.

Около 41 г., когда его отправили на другой лагпункт, мне вручили письмо от узбека, адресованное отцу; письмо было написано в походных условиях, когда студентов их института отправили в зап. направлении, я это письмо переотправил по назначению, но ответа от Гыйльми абый не получил.

Вот, пока все, что запомнил о Вашем отце. Ваш адрес сообщала моя родная сестра из Казани, ее муж Риза; к сожалению я его фамилию не помню, но знаю, что он приходится Вам дядей, выходит, что мы «кода-кодагый».

Шафика Гильмеевна, жива-ли тетя Зифа и ее дочери и сын; ведь мы с ними общались. Мне как-то в Краслаге рассказали, что в Канском, на лагпункте находился Галимзян Шараф и там якобы скончался...

С приветом Хамит. 18.IV.1956.»[91]

Шушы вакыйгалардан соң, тормыш-дөньялар уңай яккарак үзгәрә төшкәндә, 1957 елның 8 маенда Г. Шәрәфнең кызы Шәфика Шәрәф (хәзер ул астрономия профессоры,

Петербургта яши.— *Р. В.*) Ленинград шәһәре прокуроры исеменә мөрәҗәгать итә. Ул үзенең хатында: «Минем әтием гаепсезгә хөкем ителгән иде. Бу хакта аның турындагы документлардан да ачык күренә,— дип яза. Аның хатын юстиция полковнигы Игонин Ленинград өлкәсенең УКГБсына җибәрә һәм Г. Шәрәфнең архивтагы эшен өйрәнергә кирәклеген яза, хәбәр итә. Нәтиҗәдә 1958 елның маенда Хәрби трибунал яңа карар чыгара. Анда «Махсус киңәшмә кабул иткән (2 июль, 1939 г.) карарны юк дип санарга, ә эшне, җинаять составы булмаганлыктан, туктатырга»,— диелә[92].

Милләтебезнең асыл улы, курку белмәс көрәшчесе, Тукаебызның остазы Гыйльметдин Шәрәф шулай гаепсезгә берничә тапкыр хөкемгә тартыла. Ул зинданнан зинданга күчеп, төрле авырлыклар кичереп вафат була. Хәзер Гыйльметдин Шәрәф Татарстанга әйләнеп кайтты. Аның халык хәтерендә мәңге сакланачагына шик юк.

Г. Тукайның бер шигыре искә төшә:

Күңел берлән сөям бәхетен татарның
Күрергә җанлылык, вакытын татарның.
Татар бәхете өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Кара көчләр аны юкка чыгарырга, халыкның рухын сындырырга теләделәр — бу барып чыкмады. Соңга калып булса да гаделлек өскә чыкты. Уянып, савыгып килгән татар милләте үзе, киләчәге өчен җаннарын фида кылган улларын мәңге хәтерендә саклар, онытмас, аларга һәйкәлләр куяр.

ЯЗМЫШМЫ, ЯЛГЫШМЫ?

ДӘҺШӘТЛЕ КӨЗ

Шиһап Шәрәф, 1934 елда лагерьлардан кайткач, гел борчылып, түзәлмәслек авыр шартларда яши. Гаиләсе таралган, хатыны вафат, туганнары белән Галимҗан кулга алынганнар һәм ул аларның язмышы турында берни дә белми. Шәһер Шәрәф исә 1938 елның 17 июнендә Уфада ДУМЕС (Европа һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте) эше буенча атылган иде инде. Шиһап үзенә бәла якынлашканын тоеп яши. 1938 елның 30 сентябрендә Калинин урамындагы 30 нчы йортның 2 нче фатирына аны НКВД хезмәткәре Хәбибулла Кузюмов кулга алырга килә. Бу аңа авыр булмый. Шиһап исә бернинди дә каршылык күрсәтми.

Кулга алуны ТАССР НКВДысының район бүлеге начальнигы Карпов әзерли. Ул республика НКВД начальнигына Шиһап Шәрәфне кулга алуның зарурлыгы турында документ җибәрә. Анда түбәндәге юллар бар: «Мин Татарстан НКВДсының Буа районы бүлеге начальнигы Карпов 1875 елда Тат. АССРның Буа районы Аксу авылында туган, милләте татар, партиясез, элек мулла булган, контрреволюцион эшчәнлеге өчен моңарчы хөкемгә тартылган, хәзер Казанда яшәп Роскинода каравылчы булып эшләүче Шиһап Шәрәфкә кагылышлы материалларны карап чыккач, Шиһап Шәрәф күп еллар буе чит илләр белән бәйләнешле Советка каршы милли оешмада катнаша, Совет властен корал кулланып бәреп төшерүгә юнәлтелгән эш үткәрә, дини хорафатларны файдаланып, үз тирәсендәге кешеләр арасында фетнәчел рухтагы агитация алып бара, ягъни РСФСР Җинаять кодексының 58-2, 58-10 һәм 58-11 маддәләрендә каралган җинаятьләр эшләүдә фаш ителә, шуның өчен Җинаять процессуаль кодексының 128,145, 146, 158 маддәләренә таянып, Шиһап Шәрәфне РСФСР Җинаять кодексының 58-2, 58-10-1 һәм 58-11 маддәләре буенча гаепләргә һәм, аны кулга алып, беренче төрмәнең...нче камерасына ябарга дигән карар чыгардым. Бу карарның копиясен ТР НКВДсының Дәүләт иминлеге идарәсе бүлеге начальнигына һәм кулга алырга санкция сорап прокурорга җибәрергә кирәк.

ТАССР НКВДсының Буа районы бүлеге начальнигы Дәүләт иминлеге лейтенанты (Карпов).

Килешәм: Татарстан НКВДсының Дәүләт иминлеге идарәсендәге дүртенче бүлекнең вакытлыча начальнигы Дәүләт иминлеге өлкән лейтенанты Морголин»[93].

Бу документны 2 сентябрьдә ТАССР Эчке эшләр халык комиссары урынбасары Шелудченко раслаган.

Шиһап Шәрәф эше буенча 17 кеше үткән: Габдрахман Сәгыйтов, Динмөхәммәт Бикмуллин, Нуретдин Әбүәлханов, Фәйзрахман Җаббаров, Мөҗип Хәбибуллин, Сафиулла Хәмидуллин, Сибгать Галиев, Әхмәтҗан Әхмәтов, Бакый Солтанов, Камил Бәширов, Камалетдин Салихов, Зәки Бакиев, Рәфыйкъ Хөсәенов, Җәләл Таһиров, Мифтах Гаделшин, Мингали Бикмуллин[94]. Аларның күбесе аңарчы да кулга алынган була.

Беренче сорауны да Карпов ала. Сорау алу беркетмәләреннән Шиһап Шәрәфнең барлык «гөнаһларын» инкарь итмәве күренә. Башта ул үзенең Советка каршы «Идел-Урал милләтчелек оешмасы»нда катнашканын әйтә. Аннары ВКП(б)га һәм Совет властена каршы көрәштем, ди. «Идел-Урал» оешмасына кайчан һәм кем тарафыннан тартылдың?» дигән сорауга Шиһап 1918 елда ук энесе Галимҗан белән очрашуларда «Идел-Урал штатлары» проекты барлыгын ишеткәнен әйтә. «Идел-Урал штатлары» файдасына агитация алып барганда, имеш, ул, большевиклар татар халкының тормышына аз үзгәреш керттеләр, татарлар үзләренә милли үсешкә бернинди хокуклар да алмадылар, һаман руслар табаны астында яшиләр, бу хәл Советлар власте бәреп төшерелгәнче шулай булып калачак һәм шуңа күрә мөстәкыйль Идел-Урал буржуаз милли дәүләте төзеләчәк, дигән. Аннары ул Советка каршы мифик «Идел-Урал» оешмасының составына кергән кешеләрне телгә алып, Мингалиев Шәвәлине, Бикмуллин Динмөхәммәтне, Бикмуллин Мингалине, Әбүәлханов Нуретдинне, Җаббаров Фәйзрахманны атаган.

Бу һәм башка күрсәтүләр, әлбәттә, хакыйкатькә туры килмиләр. Аларны тикшерү органнары хезмәткәрләре тыелган ысуллар кулланып алган булганнар. Хәтта ТАССР Эчке эшләр халык комиссары урынбасары Шелудченконың үзенең дә кешеләрне кабинетында кыйнавы һәм шул ук гамәлне үзенә буйсынучылардан да таләп иткәне ачыкланды. Ул сорау алу беркетмәләрен үз куллары белән төзәтеп, андагы «буяуларны» үзенә ничек кирәк, шулай куерткан. Кулга алынучыларның күрсәтүләре гадәти юл белән түгел, кыйнап-җәберләп алынган. Йончыган 60 яшьлек авыру Ши-

һап Шәрәфтән дә теләгән җавапларны алу авыр булмаган. Ул шул җаваплары нигезендә тулысынча «фаш ителеп» РСФСР Җинаять кодексының алда лейтенант Карпов санап үткән маддәләре буенча Советка каршы милли «Идел-Урал оешмасы»нда катнашучы, Советка каршы панисламлык коткысы үткәрүче, оешмага яңа әгъзалар тартучы кеше буларак, хөкем ителергә тиеш дип табыла. Ләкин, эш буенча өстәмә тикшерү кирәк булуны игътибарга алып, тикшерү срогы инде беткәнгә күрә, Җинаять процессуаль кодексының 105, 116 нчы маддәләренә таянып, тикшерү срогын тагын бер айга, ягъни 1939 елның 3 мартына кадәр озайтырга дигән карар кабул ителә.

СИКӘЛТӘЛӘР

Кем соң ул фетнәче Шиһап Шәрәфетдинович Шәрәф? Ул — Баруди җитәкчелегендәге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган югары белемле мулла булган. 1929 һәм 1931 елларда Советка каршы эшчәнлеге өчен дип кулга алынган. 1932 елда Җинаять Кодексының 61 нче маддәсе буенча 8 елга ирегеннән мәхрүм ителгән.

Гаепләүгә нигез булган күп кенә сорау алу материаллары тулысынча сакланмаганнар. Сакланган материалларга караганда, Октябрь революциясеннән һәм Гражданнар сугышыннан соң, 20 нче еллар башыннан 1939 елда үлгәнче Шиһап Шәрәфнең тормышы сикәлтәләр аша үткән.

Шәрәфләрнең барысына да октябрьгә кадәрге тормыш та җәннәт булмаган. Җандармерия идарәсе Казан губернасындагы һәм үз тәэсирләрен Казанда гына түгел, Оренбург, Уфа һәм башка калаларга да җәелдергән актив мәгърифәтче туганнарны күз уңаеннан ычкындырмаган. Бу аеруча «Мәгариф» типографиясендә һәм «Вакыт» газетасында актив эшләгән Гыйльметдингә һәм Борһанга кагыла. Шиһап исә мулла вазифаларын үтәгән, бераз сәүдә иткән һәм игенчелек белән шөгыльләнгән. Бу аңа ярыйсы ук хәлле көн итәргә, гаиләсен ач утыртмаска, фәкыйрь авылдашларына кулыннан килгән кадәр булышырга мөмкинлек биргән. Совет властена мәхәббәте сизелмәгән, әмма, һәммәсен вакыт үзе хәл итәр, дип аңа каршы көрәшмәгән.

Ләкин ул чорда элек мулла булган яки сәүдә белән шөгыльләнгән кеше киләчәгенә өмет баглаудан мәхрүм иде. Мәсәлән, 1922 елда Шиһап Шәрәф, гәрчә ул Тәтеш өязенең җир идарәсенә сайланган азык-төлек комиссары булса да, сайлау хокукларыннан мәхрүм ителә. Авыл җәмәгатьчелеге

Шиһапны мәгълүматлы мулла булганы өчен генә түгел, авылда мәктәп төзүне башлап йөргәне өчен дә хөрмәтли. Шиһап кредит, май чыгару заводы, мелиорация ширкәтләрен оештыручыларның берсе була. Болардан тыш ул үзәге Аксу авылына урнашкан кооперативлар челтәрен дә оештыра. Әлбәттә, аңа туганы — ТАССР Дәүләт банкында эшләгән Гыйльметдин Шәрәф тә булыша. Яңа икътисади сәясәт шартларында Шиһап тормышта күпмедер җиңеллек тоя. Ләкин Аксуда гына түгел, тирә-күрше авылларда да гаять зур тырышлык куеп ирешелгән нәрсәләр акрынлап юкка чыгалар. Бу хосусыйчылыкны кысрыклау сәясәтенең нәтиҗәсе була. Ул процесс коллективлаштыруны тормышка ашыру барганда аеруча көчәя. Мәсәлән, 1928 елның 26 гыйнварында расланган «Авылда эшләү турында»гы резолюция проектында «1929 елның язына ярлыларның барысын да кооперациягә тартырга», һәм ары китеп, «Татарстан Республикасында, бигрәк тә татар халкы арасында колхоз хәрәкәтенең кирәк кадәр үсмәвен күздә тотып, агымдагы елда ул хәрәкәтне үстерү һәм ныгыту юнәлешендә күп кенә чаралар үткәрү аеруча катгыйлык таләп итә», диелгән. Күп кенә урыннарда масса төсендә коллективлашу алдыннан крестьяннар советлар сәясәтенә канәгатьсезлек белдерәләр.

Митингларда хөкүмәт һәм партия үткәргән сәясәт җентекләп тикшерелә. Крестьяннар аңарда 20 нче елларның башында алынган юнәлештән тайпылыш тоялар. Алар аны Ленинның үлеме белән бәйле итеп һәм Ленин үлгәннән соң хөкүмәтнең аграр сәясәтне бозуында күрәләр. Крестьяннарның халәте турында Тәмте авылы крестьяны Седовның сүзләре гыйбрәтле. Ул: «Безнең муенга сигез сәгатьлек эш, айлык ял, курортлар, яхшы хезмәт хакы яулаган эшче атланды... ә крестьяннар зур салымнар түлиләр. Ул үзенең шундый тормышка крестьяннар аша ирешүен онытты, әгәр без аңа икмәк бирмәсәк, ул яши алмас иде. Безгә уянырга кирәк, әгәр безгә җирле органнар игътибар итмәсәләр... югарыга барырга кирәк — алар игътибар итәр. Владимир Ильич крестьяннар турындагы мәсьәләне алай куймаган. Безгә: Ленин үлде, ленинизм яши, диләр. Ә мин, Ленин табутта ятканда ук инде ленинизм җирләнгән иде, дим»[95], — ди.

Республикадагы крестьяннардан күпләр тагын да кыюрак чыгышлар көтәләр. Республикада туган хәлне, республикадагы гына түгел, бөтен илдәге хәлне анализлау һәм крестьяннар мәнфәгатенә җавап бирә торган сәясәт үткәрү урынына крестьяннарны кулга алулар башлана. Аларны яклап чыккан аерым коммунистларның чыгышлары да

уңыш китерми. Мәсәлән, Аксу авылында 1925—1927 елларда кулакларны сыйныф буларак юк итү турындагы сәясәт белән үзенең килешмәвен белдергән партия әгъзасы Шәйхи Мөлеков Бухаринны мактый. Мәсьәләгә шулай якын килүне крестьяннар хуп күрәләр. Шиһап Шәрәфкә дә Шәйхи Мөлеков ошый.

1929 елда, масса күләмендә ирексезләп колхозларга кертү чорында «башкача фикер йөртүчеләрне» төрле эшләрдә катнашудан читләштереп кенә калмыйлар, кулга да ала башлыйлар. Шул рәвешчә Шиһап Шәрәф 1929 елда беренче мәртәбә кулга алына, әмма җиде айдан соң, тикшерүчеләр гаебен таба алмагач, иреккә чыга. Аннары ул, өченче төркемгә теркәлеп, раскулачивать ителә. Шул сәбәпле аның гаиләсен ниндидер күрше авылга күчерергә тиеш булалар, ләкин Шиһап, үзенең әйтүенә караганда, авылына кайтмый.

Шиһап Шәрәфнең хуҗалыгына килгәндә, ул башка хуҗалыклардан бернәрсәсе белән дә аерылып тормый.

1930 елның 5 июлендә мәсьәлә Буа кантонының Урта Балтай волосте Башкарма Комитеты президиумында карала һәм Шиһап Шәрәфне раскулачивать итәргә карар бирелә. Ул чакта аңа 58 яшь, гаиләсендә эшкә яраксыз 9 җан була. Раскулачивать иткәндә конфискацияләнгән милек барлыгы 1000 сумга җыела. Кирпеч келәт — 500 сум, ихатадагы башка каралтылар — 170 сум, сабан — 30 сум, ат — 250 сум; авыл хуҗалыгы салымын 1927/28 еллардан 6 сум, 1928/29 елларда 6 сум 18 тиен, 1929/30 елларда — 178 сум түләгән. Сайлау һәм сайлану хокукларыннан мәхрүм ителгән, ул хокуклар аңа яңадан кайтарылмаган[96].

Шиһап Шәрәфнең хәзер Казанда яшәүче кызы Сөембикә Садыйкова: «Без 2, 5, 8, 13 һәм 15 яшьләрдәге биш бала бернинди яшәү чарасыз ач-ялангач калдык. Ишле гаилә саналсак та, берничә тапкыр безне өебездән куып чыгарырга тырыштылар. Әтине кулга алганнан соң әни бик нык авырды һәм 1932 елда үлде...» — дип искә ала.

Үзе кулга алынгач, крестьян Шиһап Шәрәфнең гаиләсе, башка бик күп гаиләләр кебек үк, тарала башлый. Өлкәнрәк балалары Апаска Бибинур апалары янына күчәләр. Риза Шәрәф Урта Азиягә, Фәйрүзә белән Әминә Казанга китәләр. Шиһап Аксу авылына бүтән кайтмый. 1938 елда кулга алынганга кадәр Казанда яши. Шул рәвәшчә аның тормышында яңа дәвер башлана. Игенче үз эше белән шөгыльләнү мөмкинлегеннән читләштерелә. Аңа бәхет эзләп Урта Азия якларын да айкап кайтырга туры килә, әмма Шәрәфләрне кайда барсалар да күздән югалтмыйлар, кайда да табалар. Бәлки моңа 1927 елның 7 маенда КГПИ укытучы-

сы Галимҗан Шәрәфнең Сталинга язган хаты да сәбәпче булгандыр. Ул Сталинга, татар язуын гарәп шрифтыннан латин шрифтына күчерү татар мәдәниятенә зур зыян китерәчәк, дип язган була. Галимҗан озакламый андый күчерүнең татар мәдәниятенә зарарлы булачагын фәнни нигезләп махсус китап та яза. Галим шулчакта ук инде ул күчешнең мәдәниятебезгә, аеруча тарихыбызга һәм телебезгә торгынлык китерәчәген сизә. Шиһап Шәрәф 1931 елда Әндижан шәһәрендә кинәт кулга алына һәм Казанга кайтарылып тугыз ай буена төрмәдә тотыла. Аны анда артык тотарга нигез булмый, чөнки гаебен тапмыйлар. Икенче мәртәбә Шиһапны 1932 елда кулга алалар. Бу юлы ул дәүләт салымнарын түләмәүдә гаепләнә һәм сигез елга хөкем ителә. Ләкин ике ел ярымнан соң срогыннан элек иреккә чыгарыла. Төрмәдән ул 1934 елның ахырында азат ителә.

ҺӘЛАКӘТ

Менә 1938 елның бәлале көне килә. Төрмәдә Шиһап бик нык хасталана. 1939 елның 15 февралендә язылган белешмәдән күренгәнчә, аның уң ягын паралич суга, ул үзлегеннән көчкә йөри. Моңардан тыш Шиһап йөрәге авырту белән һәм хроник ревматизмнан җәфалана.

Сорау алганда Шиһапны якташлары — Ташкичү авылы мулласы Мөҗип Хәбибуллин, Сафиулла Хәмидуллин, Сибгат Галиев һәм Әхмәтҗан Әхмәтов белән бергә Советка каршы «Идел-Урал» төркеме оештыруда гаеплиләр. Аңа якташы Шәвәли Мингалиев белән аралашуда гаепләрдәй берни дә булмавын исбатлау аеруча кыен була. Хәл Мингалиевнең туганы Борһан Шәйдуллинның Кытайда яшәве белән катлаулана. Ул анда революциягә кадәр үк Семипалатинскидан күчеп киткән була, революциядән соң шунда кала һәм Кытай гражданлыгын ала. 1938 елның 22 сентябрендә сорау алу вакытында Шиһап Шәрәф Борһанның Синцзян провинциясендә югары урында эшләвен, берничә тапкыр СССРга килеп китүен, соңгы тапкыр 1929 елда Германиягә барышлый Казанда абыйсы Зиннәт Гыйззәтуллинда туктaлуын, Аксу авылында Шәйдуллинның сеңлесе Тайфә Мингалиеваның яшәвен сөйли. Аннары ул 1925 елда СССРда яшерен рәвештә нindидер Хаҗи Миндубаевның булуын, аның Аксуда 5—6 көн яшәвен һәм Шәйдуллинның әнисе белән ике сеңлесен Кытайга алып китүен әйтә.

1939 елның январендагы сорау алулар Шиһап Шәрәфнең сәламәтлеген тәмам какшаталар. Тикшерүчеләрнең катгый

таләпләренә карамастан, ул Габдрахман Сәгыйровка һәм Әхмәтҗан Мостафинга кара яга торган документларга имзасын куюдан баш тарта. Тикшерүче Фәйзуллин аны Мостафин белән бергәләп Советка каршы эш алып барганын әйттерергә тырыша. «Сез алдашасыз,— ди тикшерүче аны кысрыклап,— кулга алынган көнегезгә кадәр сез Мостафин белән тыгыз элемтәдә торгансыз һәм Советка каршы актив милләтчелек эше алып баргансыз. Бездә ул мәгълүматлар бар. Тикшерү сездән дөрес күрсәтмәләр бирүегезне таләп итә»[97]. Шиһап Шәрәф хак-гадел күрсәтмәләр бирә, ул Мостафин белән бергәләп Советка каршы эш алып баруын катгый рәвештә кире кага. Кыйнау аркасында ирексездән икърар ителеп кул куелган документларның нәрсәгә китерәчәген яхшы белеп, Шиһап һәр очракта бар гаепне үз өстенә алырга тырыша. Архив документларыннан күренгәнчә, 1939 елның 31 октябрендә Шиһап Шәрәф төрмә шифаханәсендә вафат була. Шуңа нигезләнеп, 1939 елның 15 ноябрендә аның җинаять эше туктатыла.

1989 елның 11 августында ТАССР прокурорының өлкән ярдәмчесе Дмитриевский, архивтагы 2—5717 номерлы җинаять эше материалларын карагач, 1939 елның 15 ноябрендә чыгарылган «Шиһап Шәрәфнең үлүе сәбәпле эше туктатыла», дигән карарны нигезсез, Шиһап Шәрәфнең җинаять эшен анда бернинди җинаять тә булмаганга туктатырга, дип тапты.

Шулай итеп, тагын бер шәхес акланып, аңа керсез исеме кире кайтарылды. Тыйнак авыл хезмәткәре, әдәпле, намуслы, кешеләргә һәм Ходай тәгаләгә риясыз ышанган кеше арабызга кире кайтты. Ниһаять, гаделлек тантана итте.

БЕЗНЕ НИ ӨЧЕН ҮТЕРДЕЛӘР?

ТУКАЙНЫ САГЫНУ

Татар халкының күренекле улы, үзенчәлекле шәхес Шәһретдин Шәрәф мәдәният тарихында якты эз калдырган, халкыбызга аң-белем, әхлакый тәрбия бирүдә күп көч куйган зыялыларыбызның берсе. Аның яшьлек чоры бер-бер артлы булган инкыйлаблар дәверенә туры килә.

Шундый чорда татар зыялылары да, әлбәттә, милли бәйсезлек өчен актив көрәшкә тартылалар. Шәһретдин Шәрәф гасыр башында ачылган «Мәгариф» нәшриятын оештыруда актив катнаша. Шуның белән бергә, ул «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең матди базасын ныгыту, аны төпле кадрлар белән тәэмин итү эшеннән дә читтә калмый. Шәһретдин Шәрәф 1907 елда уздырылган Мөселман укытучылары съездын актив җитәкләүчеләр арасында була. 1918—1919 елларда ул «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең укытучылар шурасы рәисе булып тора, шунда ук шәкертләргә тарих укыта. Шунысын да әйтергә кирәк: Шәһретдин Шәрәф актив гыйльми-педагогик һәм җәмәгать эшчәнлеге белән генә шөгыльләнеп калмый, бәлки татар зыялылары, милләтнең алдынгы карашлы шәхесләре белән дә тыгыз бәйләнештә тора. Шагыйрь Габдулла Тукайның вафат булуына биш ел тулу уңаеннан, ул үзенең истәлекләрендә түбәндәге юлларны яза: «1907 елның ахырлары иде. Бервакыт борадәрем Борһан: «Уральск» газеталарында шигырьләр язучы Габдулла монда килгән, хәзердә «Болгар» номерларында, ул тырышырга ярый торган егет,— дип сөйләде. Соң ул егетне гомумән ничек таптың? — дигән соравыма каршы: «Һәрнәрсәгә өстен карап мөхакәмә итәргә ярата, акчага, байлыкка, хәяткә бер дә исе китми, һәммәсенең өстеннән карый ала...» — диде.

Беркөн «Казан мөхбире» газетасы идарәсендә беренче мәртәбә Тукай берлә очраштым...Беренче сүз Уральскийда дәвам иткән «Фикер», «Әл-гасрел Җәдит» хакында булды. Ул бу газета вә журналларның күбрәк эшләре үз кулыннан, үз планы буенча эшләнгәнен сөйләдектән соң, мин анда

күпме вазифа алганын сорадым. «Егерме-егерме биш сум кадәрле»,—диде. Буңар каршы: «Казанда шулкадәр эшләсәң, сиңа аның кадәрле ике-өч вазифа бирерләр иде»,— диде кемдер. «И тамак туярлык бер дәрәҗәдә мәгыйшәт итәрлек булгач, акчаның нигә кирәге бар, миңа шул акча җитә иде; газеталар яхшы барса, һаман да шунда хезмәт итүне уйлап тора идем»,—диде.

Тукай илә моннан соң да күп очраша идек. Ул вакытта аның гыйлем арттырырга тырышканы, һәртөрле китаплар мөталәгасенә ихласы күренеп тора иде. Миннән гарәп әдәбияты вә аның тарихы хакында күп нәрсә сораша, бу нәрсәләрне яратып тыңлый вә шуларны тәфсыйләте белән беләсе килә иде... Миннән төрек әдипләренең байтак китапларын алып укыды. «Госманлы әдәбияты нәмүнәләре» исемле китапны укыгач, «бу китапта миңа ярарлык нәрсәләр дә бар икән дигән иде»[98].

Билгеле булганча, Тукай Шәһретдиннең башка туганнары белән дә якыннан танышып, дус яши, аларның булышлыкларын соңгы көненә кадәр тоя. Сания Шәһер кызы Шәрәф-Акҗитованың әйтүенә караганда, Риза Шәрәф «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыганда абыйсы Гыйльметдин Шәрәф янына нәшриятка акча алырга килгәч, ул да Тукай белән очраша. Тукай белән Гыйльметдин нәрсәдәндер көлешә-көлешә сөйләшеп утыралар икән. Яшь егетнең кем икәнлеген белгәч, шагыйрь аны иркәләп сөеп: «монысына китаплар алырсың»,—дип көмеш акчалар да биргән.

ИНКЫЙЛАБКА ЮЛ

Татар дөньясы уяна башлау белән Шәрәфләр халыкны агарту, аңа аң-белем бирүнең кирәклеген күтәреп чыгалар. Бу алар тарафыннан нигез салынган «Мәгариф» нәшриятының эшеннән, Тукайга һәм башка зыялыларга булган мөнәсәбәттән генә дә бик яхшы күренә. Шул вакытта ук инде Шәрәфләр полиция тарафыннан «милләтчеләр», дөресрәге, панисламистлар исемлегенә кертелеп, бертуктаусыз эзәрлекләүләргә дучар булалар. Бу сәясәт Столыпин тарафыннан милләт мәсьәләсенә багышланган яшертен «Махсус киңәшмә»дән соң тагын да активлаша төшә. Мәгълүм булганча, бу киңәшмәдә, башка мәсьәләләр белән беррәттән, мөселман мәктәпләре эшләрен күзәтү астына алырга күрсәтмә бирелә. Бу сәясәт, билгеле, мәдрәсә укытучысы Ш. Шәрәфне читләтеп узмый. Нәкъ менә шушы вакыттан панисламистларны, ә Совет чорында милләтчеләрне эзәр-

лекләү юлга салына. Моңа бик үзенчәлекле бер дәлил дә бар. Без барыбыз да Столыпинның аграр сәясәте ничек җимерелгәнен беләбез. Әмма бу астыртын сәясәтнең Совет чорында да дәүләт идеологиясе итеп кулланылганын югары уку йортларында эшләүче галимнәр һәм белгечләр сизенделәрме икән? Чөнки бу сәясәт җитмеш ел буена турыдан-туры гамәлгә ашырылды. Нәтиҗәдә мәчетләр, мәдрәсәләр ябылды, милли белгечләр лагерьга озатылды, яисә атылды.

Аларны Совет чорында да шул ук махсус ябык киңәшмәләр хөкем итте. Аерма шунда гына иде: аларга Столыпин түгел, бәлки Сталин үзе, НКВД җитәкчелек итте. Ленин әйтмешли, милли мәсьәләләр, шовинизмның басымы аркасында, чебен сөткә баткан кебек батты, үлем хәленә җитте.

Столыпин җитәкләгән яшерен киңәшмәдән соң, фикер йөртүче зыялылар барысы да диярлек панисламистлар исемлегенә кертеләләр. Шушы исемлектә Шәһретдин Шәрәф тә була. Бу эшкә мөселман әһелләре дә өлеш кертә. Мәсәлән, Казанның 12 мулласы Эчке эшләр министрлыгына «Зариф Әмирханов һәм Шәһретдин Шәрәфләр дәүләткә каршы эш алып баралар»,—дип шикаять язалар. Шикаятькә нигезләнеп, яшерен полиция начальнигы 1910 елның 12 июнендә алар артыннан күзәтү оештыра.

1911 елның 27 гыйнварында Галиев мәчетендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көненә багышлап намаз укыла. Провокатор С. Зәбиров Эчке эшләр министрына язган хатында: «З. Әмирханов һәм тагын берничә кеше патшага карата ләгънәт намазы укыдылар»[99],—ди. Чынлыкта исә «ләгънәт намазы» провокаторларга багышланган булып чыга.

Менә шундый катлаулы чорда да каушап калмый Шәһретдин, җиң сызганып эшкә чума.

1913 ел аеруча истәлекле була. 3 августта Казан елга портында татар зыялыларыннан Мөхәммәд Кәримов, Салихҗан Галиев, «Кояш» мөхәррире Закир Садретдин һәм Шәһер Шәрәфләр очраша. Очрашуның сәбәбе — «Амур» пароходы белән килүче Әссад Мәхмүд әфәндене — төрек министрын каршы алу.

Әссад Мәхмүд Казанда ике көн булса да, шактый эшләр эшләп өлгерә. Ул башта татар зиратына барып, Габдулла Тукай каберенә баш ия, аннан соң Шәһер Шәрәф эшли торган «Мөхәммәдия»гә килә. «Кояш», «Йолдыз» идарәләренә кергәннән соң, бертуган Кәримовларның нәшриятларын карый, Кремльне, Сөембикә манарасын күрә.

Әлбәттә, Казан зыялылары өчен аның белән очрашып

сөйләшеп утыру, фикер алышу файдалы була. Бу очрашуларда Шәһер Шәрәф, Ибрахим Әмирхан, Һади Максуди, Фәхрислам Агиев, Тимерша Соловьев һәм башкалар була. Төрек министры Мәхмүд Әссад Казанның сәясәт өлкәсендә тоткан юлына һәм Йосыф Акчура, Исмәгыйль Гаспралы, Ризаэтдин бине Фәхретдин кебек зыялыларның хезмәтенә югары бәя бирә. Шул ук вакытта, Солтанов кебек мөфтиләрне тәнкыйтьли.

5 августта ул, пароходка утырып, Казаннан китеп тә бара[100].

Эзәрлекләүләргә дә карамастан, Шәһер Шәрәф аң-белем тарату эшен дәвам итә. 1914—1917 еллар эчендә генә дә ул өч зур китап яза. («Гасры Сәгадәт», 1914; «Мәрҗани», 1915; «Әсхабе Кирам», 1917 ел.) Шул ук вакытта аның күпсанлы мәкаләләре төрле газета-журналларда басыла. Мәсәлән, «Шура» журналында аның «Имамларның хокуклары бармы?» «Асаре гатика» дигән җитди мәкаләләре дөнья күрә. Әлбәттә, аның бу чорда язылган хезмәтләренең иң әһәмиятлесе һәм яратып, илһамланып язган хезмәте — «Мәрҗани»дер.

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ

Мәдрәсәдә яңача укыту, дәреслекләр язу, башка эшләр Шәһретдиннең күп вакытын ала иде, әмма бер намазны да калдырмады, вакытында мәчеткә дә, нәшриятына да өлгерде. Хатыны Фатыйма ханым да сабыр, өлгер. «Бәрәкалла, һаман шулай булса иде»,— ди торган иде Шәһретдин, өенә кайтып ашап-эчкәч, ял иткәч. Аның изге эше өйдә генә түгел, съездларда, думаларда да телгә алынды, макталды, ә кыерсытылган чагында яклаучылары да була иде.

Менә, мәсәлән, Садри Максудиның Дәүләт думасындагы чыгышы. Доклад «Хаклык өскә чыгачак» дип атала. Анда сүз мөселманнарны Русиядә кысу — җәберләүләр турында бара. Шәһер Шәрәф хакында турыдан-туры әйтелгән юллар да бар монда: «Казанда мәдрәсәи Мөхәммәдия» мөдәррисләреннән өч кеше — Мостафин, Шәрәф һәм Зәбиров мөдәррислектән мәнгы ителгәннәр...»[101].

Шулай булса да гомер уза: Тәтеш өязенең Аксу авылы (хәзер Буа районы — *Р. В.*) егете 1888 елда «Мөхәммәдия»не тәмамлаган, 1897 елда казах далаларында балалар укытып, казах халкының әдәбиятын, халык иҗатын өйрәнгән, ә 1904 елда Кырымга, Төркиягә сәфәр ясаган. Соңгысы турында соңрак 1917 елда «Заман календаре»нда язып калдырган.

Инде менә 1905 елның инкыйлабыннан соң узган гомер, аңа да бераз күз салыйк. Шәһретдин белән бүген очрашып сөйләшә алсак, нәрсәләр безгә мәгълүм булыр иде? Ни аяныч, аның үзен түгел, кабер ташын да таба алмаячакбыз. Әзне тирән калдырган очракта да күбесен тарих, дөресрәге, авыр тормыш югалта, яшерә. Бары тик туганнарының, дус-ишләренең һәм, әлбәттә, тарихчыларның зур тырышлыгы белән генә аның мәһабәт гәүдәсен, эшләрен, хәтта уйларын да, аз гына булса да күз алдына китереп була.

Кемдер тагын ишек шакый. Бу ишек шакуларны бер дә күңеленә якын ала алмаган Шәһретдин, уйларыннан арынып, кыю гына, ишетелерлек итеп:

— Узыгыз, кем бар, ишек ачык бит,—диде һәм үзе үк түземсезләнеп ишеккә таба атлады.

Ишекне киң итеп ачып, һәрвакыт җитез йөри торган студент Газиз Гобәйдуллин килеп керде.

— Карале шайтанны, күңелгә шик кертеп, тынгысыз, ару-талуны белмәс Газиз бала үзе килгән икән,—диде эчтән генә Шәһретдин, үзе ачык йөз белән:

— Әйдә, энем, уз әле! Бик вакытлы килдең, мә укы безнең Садретдинның думадагы нотыгын,—дип диванга ишарә ясап, Газизнең кулына Максудиның нотыгын тоттырды.—Курыкмаган, барысын да әйткән. Молодец Садретдин!

Бу «Вакыт» газетасы иде.

— Укыдым, укыдым, Шәһретдин абый,—диде Газиз газетаны алып, шулай да «Вакыт»ка күз салды. Анда түбәндәгеләр бар иде: «Әфәнделәр, панисламизм — бер хыял, ул сәясиләнеп маташкан миссионерларның уйлап чыгарган нәрсәләре; мөселманнарга дошман булган сәяси миссионерларның язган китап вә мәкаләләреннән башка һичбер җирдә панисламизмның булганы юк.

Бу сәясәт бигрәк тә Столыпин вакытында башланып, хәзергә кадәр дәвам итә. Шул ялгыш аркасында безне кысалар, мәктәпләребезне ябалар, муллаларны, мөгаллимнәрне куалар, газета вә матбугатларыбызны ябалар.

Бу эшкә битарафлык илә караган һәммә кешеләр ялганның урыс дәүләтенең ныклыгына бик зур зарар китерәчәгенә ышаначаклар. Шул панисламизм аркасында, яңа гына уянып килә торган мөселманнарның алга баруларына, тәрәккый мәдәният юлларына сәдд икәнен хәзер күп кеше белә. Күптән түгел миңа бер мулла бу хакта становой пристав илә сөйләшкән сүзләрен нәкыль итте. Пристав әйткән: «Никадәр тентүләр ясасак та сезнең арада панисламизм дигән нәрсә таба алмадык. Ләкин ул нәрсә безнең урыс

зыялылары арасында бик күп артык»[102]. Думаның рәисе Садрига башта сүз бирмәскә тырыша, ә доклад укыганда, тизрәк бетер, нәрсә фактлар саныйсың ди, ә урыннан Пуришкевичлар: «сез тегеләй, сез болай әйткән идегез бит»,— дип кычкырып утыралар. Бу, әлбәттә, дума эшлекләренең культура дәрәҗәсен, аларның явыз шәхесләр икәнен ачык күрсәтә. Садретдин Максудов аларга әһәмият бирмичә докладын дәвам итә...»

Газиз, гәзетаның калган юлларына күз йөртеп чыккач, Шәһергә карап:

— Әйбәт томалаган шовинист депутатларның бугазын,— дип, гәзетаны өстәлгә куйды.

Кай арададыр, өстәлдә чәй, шикәр, чәкчәкләр дә пәйда булган. Болары белән сүз дә икенчегә күчте.

— Я, сине нинди җилләр йөртә инде, энем Газиз?— дип Шәһер аның чәен кайнарлатты, сый-хөрмәтне дә аның алдынарак урнаштырды һәм шаяртып куйды:— Чәеңне эч, аша! Студент чагында сәламәтлегең сакла, профессор булгач соң булмасын.

Мондый җылы кабул итүдән һәм Садри Максуди докладыннан тәэсирләнгән Газиз, бераз уйланып:

— Шәһретдин абый, мин Сезгә киңәш белән килгән идем бит әле,— дип, чәен эчә-эчә Шәһретдин абыйсына карады.

— Йә, хуш, энем, сөйлә! Ни йомыш. Киңәш кенә бирә алырбыз мөгаен,— диде ул елмаеп.— Көмешләре кирәк булса, Гыйльметдингә җибәрермен үзеңне. Ничек булса да бер җаен табарбыз. Алла боерган булса.

— Минем белгәнемчә,— дип сүзен дәвам итте Газиз,— Мәрҗани хәзрәтләрен Сездән дә яхшы белүче юктыр. Шуңа күрә Сезгә тәкъдимем дә шул... дөресрәге, минем тәкъдимем генә түгел... Мәрҗанинең биографиясен китап итеп аның 100 еллык юбилеена чыгаруны оештыру һәм тиз арада бастыру. Менә шул,— диеп сүзен бетерде Газиз Гобәйдуллин.

Шәһретдин урыныннан торып, ашыкмыйча китап киштәсеннән бер кәгазь алды һәм Газизгә сузды:

— Хак сөйлисең, энем, ашыгырга кирәк. Менә бу исемлекне кара әле син.

Газиз бу исемлектә Гобәйдулла Гыйсмәти, Кәшшаф Тәрҗемани, Таһир Ильяси, Газиз Гобәйдуллиннарның исем-фамилияләрен күрде. Исемлекне карап чыкканнан соң:

— Бик һәйбәт булган бу, Шәһретдин абый, мин Мәрҗанинең тарихи хезмәтләре һәм фән, сәнгатькә карашлары хакында язармын,— диде.

Бары да Газиз уйлаганча булды. Күңеле тынычланды. «Рәхәт менә бу Шәһретдин Шәрәф эше кешеләр белән эшләү»,— дип уйлап куйды ул. Моннан соң тагын әлләниләр турында да сөйләшеп утырдылар: инкыйлаб, милләт, сәнгать, мәдәният, студентлар тормышы һәм башкалар.

Аның биографиясенә кагылышлы мәкаләләрне шулай ук Ризаэддин Фәхреддин, Галимҗан әл-Баруди, Йосыф Акчура, Борһанетдин һәм башкалар да язалар һәм «Мәрҗани» дип аталган шактый зур фәнни хезмәт 1915 елда дөнья күрә. Бу төрек-татар дөньясында зур вакыйга иде.

Шул вакытта нәшер ителгән рецензияләрдә дә бу турыда җылы сүзләр әйтелгән. Шуларның берсе Фатыйх Әмирхан тарафыннан язылган. Ул «Мәрҗани хәтирәсенә мәҗмуга» исемле рецензиясендә: «Мәрҗани хәзрәт турысында бөтен бер аң, бөтен бер күзаллау бирә аладыр»,— ди, һәм авторларның эшләрен дә бәяли. Ш. Шәрәфкә карата анда түбәндәге юллар бар: «Шәһер Шәрәф әфәнде тарафыннан тәртип ителгән бу тәрҗемәи хәл хәзергә кадәр шималь төрекләре матбугатында тәрҗемәи хәлләрнең иң мөкәммәле саналырлык дәрәҗәдә мөфассал (җентекле — *Р. В.*), кызыклы һәм әтрафлы тәртип ителгән. Бу мәкаләдә Мәрҗани хәзрәтләре балалык дәвереннән башлап, соңгы көннәренә кадәр булган хәяты белән күз алдыннан үтә. Шәһер Шәрәф әфәнденең бу «Тәрҗемәи хәл» өстендә бик күп иҗтиһад сарыф иткәнлеге һәрбер сәхифәдә генә түгел, бәлки һәрбер битендә күренеп торадыр. Бу «Тәрҗемәи хәлдә» Мәрҗанинең халык арасында сөйләнеп йөртелә торган әфгаль вә әтварлары мохакәмә ителеп дәреҗ ителү өстендә үзенең хәтерләреннән, китапханәсеннән, кардәш-ыруларыннан да тәрҗемәи хәлгә мөнәсәбәте бик күп мәгълүм табып чыгарылган»[103]. Ул җылы сүзләрен Габдулла Гыйсмәти, Таһир Ильяси, Газиз Гобәйдуллин, Галимҗан әл-Баруди, Йосыф Акчура, Хәбиб ән-Наҗар, Габдерахман Гомәров, Хәсән Габәши исемнәренә дә әйтеп уза. Мәрҗанинең тууына 100 ел тулу уңае белән дөнья күргән бу хезмәт, шул рәттән Әмирханның рецензиясе дә — татар тарихының бай хәзинәсе[104]. Бу хезмәт бүген дә, киләчәктә дә халкыбызга хезмәт итәчәк. Моңа шик юк. Тик аны яңадан нәшер итү генә кирәк. Аның белән бер татар галимнәре генә түгел, ә киң җәмәгатьчелек тә таныша тиеш.

Шәһретдин Шәрәфнең бу хезмәтләренә бәя биргәндә улы Шәһретдин турында әнисенең әйткән сүзләре дә искә төшә. Гайнелнәвәл ханым аның турында «бөтен солы арасында бер бодай»,— дип әйтә торган булган. Әлеге сүзләр Шәһернең фәнни хезмәтләренә дә бәя булып яңгырый.

АВЫР КӨРӘШ ЕЛЛАРЫ

Өч инкыйлабны башыннан кичергән Шәһретдиннең күңеле һич тә тынычлык таба алмады. Февраль революциясеннән соң чын ирекне татып карагач, 1913—1919 еллар аның өчен авыр көрәш елларына әверелде. Башта гражданнар сугышы башланды, ә 1919 елда аның бердәнбер өметен — «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен яптылар. Бу — Советларның ачык сәясәте. «Бу — нәрсә, панисламизмга каршы көрәшме?» — дигән сорауга ул: «Юк, бу татарга, исламга каршы ачык поход иде»,— диюдән дә курыкмады. Әмма дөнья шулай бара, кемнең кем икәнен белү җиңел түгел. Фикерләр чуалды, традицияләр онытылды, иске байраклар, лозунглар бетерелде — барысы да өр-яңадан кызыл байрак астына җыелды. Идеология дә, мәдәният та, тел дә марксизмга гына таянып үсәргә, ныгырга тиеш, чөнки без — коммунизмга барасы дәүләт, диделәр. Әле 1917 елда күпме кешеләр тарафыннан: «Без социализмга бара алмыйбыз, бездә аның өчен әзерлек юк, ә социализм сүзен быел гына ишеттек», кебек сүзләр сөйләнгән иде. Аларга колак салучы да булмады. Аларны йә милләтче, йә меньшевик, йә эсер дип атап, революция дошманы ясадылар. Күбесе туган илләрен ташлап китәргә мәҗбүр булды.

1922 елда Шәһретдинне сайлау хокукларыннан мәхрүм итәләр. Күпләр әлеге язмышка дучар була. 1928 елда бер гаепсез кешене кулга алып хөкем итәләр. Ул Коми АССРдагы лагерьларның ачысын татый. Шөкер, исән-сау әйләнеп кайта.

Кайткач та Шәһер Казан, Орел, Мәскәү һәм Харьков кебек шәһәрләрнең юлларын таптый. Орелда энесе Гыйльметдин сөргендә газаплана. Аның аны күрәсе, хәлен беләсе килә иде. Ул Мәскәүдә һәм Харьковта К. Тәрҗемани киңәше белән эш эзләп йөри. Абдулла Шәмсетдинов (Мәскәү мулласы) аның турында кайгыртып: «Харьковта мулла урыны буш, шунда барып кара әле»,— дигәч, шунда бара. Ниһаять, 1933 елда Уфага кайтып, Шәһер Шәрәф Үзәк Мөселман Диния Нәзарәтенә сыена: башта Нәзарәтнең көтепханәсендә эш кушып, соңрак туу турындагы таныклыклар биреп торучы булып эшли. Кулга алыныр алдыннан гына аны казначей итеп тә куйган булалар. Галимҗан әл-Барудиның талантлы укучысы, кияве булган Шәһер Нәзарәттә эшләргә лаеклы кеше иде. Дин әһелләре дә моны хуплап каршы алалар. Монда ул өч ел дәвамында эшли. Бу чор Шәһернең Совет хакимияте чорында аз гына хәл алган, эшкә кул-аягы белән ябышырга тырышкан вакыты була. Әмма...

Лагерьлар Шәһретдинне кызарта алмыйлар. Ул милләткә, исламга карашын үзгәртми, үзе булып кала. Үзәк Диния Нәзарәтендә эшли башлагач та Шәһер борчыла, «Без кая барабыз?» дигән сорауны үз алдына еш куя. Ш. Шәрәфнең яңа вәгазьләр җыентыгын төзи башлаган вакыты иде бу. Бу сорауга җавап итеп, вәгазьләрнең бер пунктында мондый юллар пәйда була: «Ата-бабаларыбыздан үрнәк алабызмы, әллә дуңгызлар кебек күрмәмешкә салышып, тагы да вәхшилеккә барабызмы? Кая баруыбызны абайламыйча алга ыргылабыз...»[105].

Каләм остасы һәм тарихчы яңа китап, вәгазьләр җыентыгы чыгару турында хыяллана, планын төзи, шактый фикерләр, материалларны үз кулы белән теркәп бара. Аларның кайберләре татарларның руслар белән мөнәсәбәте, милләтнең киләчәк язмышы, яшьләр мәсьәләләренә кагыла. Фикер өстенә фикер өстәлә. Югарыда күрсәтелгән юлларның дәвамы түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

«Без үзебезнең динебезне һәм милләтебезне саклап, үзләренең күкрәкләрен дошманга каршы куйган галимнәребезне һәм бабаларыбызны онытырга тиеш түгелбез.

Кадерле мөселманнар! Нигә соң безнең арабызда гаделсезлек хөкем сөрә? Нигә соң әле без бер-беребезне дошман күрә башладык?

Безнең арабызда кайберәүләр үзләренең ярлы булулары белән горурланалар һәм ярлылык турында җырлыйлар. Бу адәмнәр бозык кешеләр — алар артыннан бармагыз... Алар ярлылык турында җырлап кеше байлыгына кул сузалар.

Безнең шәһәр идарәләрендә татарлар бармы? Җитәкче урында сезнең татарны күргәнегез бармы?

Безнең татар халкының бер җитмәгән ягы бар, ул менә нәрсәдән тора: ул — барысына да юл бирә. Бик каты кыерсытылган милләт булуына карамастан, барысына да түзә. Татарлар үз хаклары өчен көрәшмиләр, әйтерсең лә мөселманнар башкалар өчен кол булып ясалганнар.

Хәзер инде, дин юк диләр. Бу — ялган... Ураза бәйрәмендә 99—100% авыл халкы бәйрәм итә. Авылда барысы да дингә ышана.

Хәзер төрле милләтләр арасында үзара көрәш бара, һәрберсе җитәкчелекне үз кулына алырга тели. Бу көрәштә үзләренең сүзен яшьләр әйтергә тиеш»[106].

Диния Нәзарәте тарафыннан бирелгән кечкенә генә, әмма җылы, уңайлы бүлмәдә лагерьлардан кайтып урнашып, яңадан аякка баса башлаган көннәр иде бу. Югыйсә картаеп бара торган тәнгә тагын ни кирәк. Анысы шулайдыр, ә бит әле сап-сау җан бар Шәһретдиндә, менә шул җан дигән

нәрсә лагерьларда, шушы тыныч, җылы бүлмәләрдә дә үзенә тынычлык таба алмады. Бернигә дә карамастан, халыкның ялгыш юлдан китеп барганлыгын күрсәтәсе, кешеләрнең күзләрен ачасы килде аның. Бар теләге шул иде.

Көтмәгәндә Шәһретдин бүлмәсенә Кәшшаф Тәрҗемани килеп керә. Бусагадан ук көр тавыш белән:

— Шәһретдин әфәнде, әссәламәгаләйкем,— дип сәламли һәм түргә узып, урын табып утыра.

Икәүләп дога кылалар. Берара бүлмә тынлыкка чума. Бары тик шуннан соң гына Кәшшаф Тәрҗемани:

— Йә, Шәһретдин, ни эшләр бетерәсең бу көннәрдә?— дип сорый.

— Үзең беләсең, безнең эш шул — халык белән очрашуга әзерләнү. Менә вәгазьләр җыентыгы кебек бер язма әзерләгән идем,— ди, Шәһер язманы Кәшшафка сузып.— Төрмәдән кайтканнан бирле нигәдер эчем поша, тынычлана алмыйм, зиһенем бутала кебек.

Вәгазьләргә тиз генә күз йөртеп алса да, Кәшшаф сүзне икенчегә бора:

— Менә бу хатны кара әле син,— дип, Шәһретдингә хат суза.

Ул ашыкмыйча гына укырга керешә: «Үзәк Мөселман Диния Нәзарәте рәисе мөфти хәзрәткә.

Берникадәр вакыт элек, ягъни мин ялда вакытта, кайчандыр мөхтәсиб булган һәм әле дә безнең белән элемтәне өзмәгән кеше: «Ялда булуыгызга карамастан, әңгәмә кору өчен мине кабул итүегезне үтенәм»,— дип мөрәҗәгать итте.

Утырдык, сөйләштек. Безнең әңгәмәнең эчтәлеге шуннан гыйбарәт: «Үзәк Мөселман Диния Нәзарәтенә эш өлкәсе калмады. ҮМДНнең мондый хәлдә яшәп килүеннән мөселманнар өчен бернинди файдасы юк. Әгәр хәзер ҮМДНне япсаң, моның нәтиҗәсе Совет властена йогынты ясар һәм аның дингә карата мөнәсәбәтен үзгәртергә мәҗбүр итәр иде. Менә шуңа күрә хәзерге вакытта ҮМДНне ябу максатка ярашлы. Бу — бер төркем кеше фикере. Миңа бу турыда Сезгә җиткерү йөкләнде».

— Менә ничек... Милләт арасында да фикер йөртүчеләр, көрәшчеләр бар икән әле. Бер уйласаң, безнең ҮМДНнән ни файда, ә аны бөтенләй бетереп ату ни бирә алыр икән? Совет власте бит бернинди кагыйдәләр белән дә санашмый. Хуҗа Насретдин әйтмешли, үзебез утырган ботакны кисү булмасмы бу? Минем кебек хокуксыз, йорт-җирсез, гаиләсез зыялылар кайда сыенырлар?— диде Шәһер Шәрәф.

— Ябу турында сүз дә булырга тиеш түгел. Әмма инде без дә синең белән монда кул кушырып утыра алмыйбыз.

Мин бу мәсьәлә хакында киңрәк аудиториядә җыелышып фикер алышуны хуп күрәм,— дип, казый тыныч кына сүзен тәмамлады.

— Әлбәттә, фикер алышу бик җитди эш, кирәк нәрсә, чөнки ислам, ҮМДН мәсьәләсе ул — идарә мәсьәләсе генә түгел, гомумән, ислам диненең язмышы, Русия мөселманнарының бүгенге хәле һәм киләчәге турындагы сүз дә булачак,— диде Ш. Шәрәф, ризалашып.

Шәһретдиннең соңгы сүзләре дә казыйның фикеренә хуп килде.

Барысын онытып, гадәттәгечә кайнар чәй эчтеләр. Тәнгә җылы керде. Тәрәзәдән кергән якты кояш нурлары да аларның фикерләрен хуплаган кебек булды. К. Тәрҗемани ашыга иде. Ул китеп барды, ә Шәһретдин китапханәгә кереп китте.

ТАГЫН ТӨРМӘ

Көтмәгәндә Казаннан Шәһретдиннең хатыны Фатыйма килеп төште. Алдан хәбәре булмады, Фатыйма ханым да беркадәр конспирациягә өйрәнеп киләдер, күрәсең, югыйсә телеграмма бирсә, Шәһретдин әзерләнеп каршы алган булыр иде. Әмма шуны да онытмаска кирәк, Шәһретдин инде күптән Фатыймасы белән аерылган булып санала, бу хактагы махсус документлар да кулда. Әмма бу Совет власте алдында, НКВД алдында шулай, ә Алла каршында алар — ир белән хатын. Фатыйма ханым килгән көнне бертуктаусыз Казан хәлләрен сөйләде, туганнарының, якын күршеләренең сәламнәрен тапшырды.

Ата кешене гаилә хәле, балаларның киләчәге, аларның исәнлеге борчый. Сания инде зур кыз — 16 яшь тулган, элемтә техникумына мең авырлыклар белән укырга кергән. Ул күңелдә өмет уята. Ә Әхмәт Бохарага киткәч нигәдер язмый, хаты-хәбәре сирәк килә. Бөтен ышаныч абыйсында:

— Балаларны сакла, Фатыйма,— диде Шәһретдин күз яшьләрен сөртә-сөртә.— Яңа режим безне аерса, без бергә — эшләрем дә, күңелем дә һәрвакыт сезнең белән, Фатыйма! Шулай дия-дия ул аны чәй белән кыстады, үзенчә, ирләрчә кунак итте. Күңелле апрель көннәре иде бу. Кулга алынып, гаиләдән аерылып яшәүнең тугыз елы тулып килә иде инде.

«Көн саен бәйрәм булмас»,— ди татар халкы. Шулай булса да, ни өчен көн саен адәм баласы өчен кыямәт булырга тиеш? Фатыйма ханым килүнең икенче көнендә үк Шәһ-

ретдин НКВД киеме кигән берәүнең ҮМДНгә—ул торган якка килгәнен шәйләп алды.

— Кара әле, Фатыйма, безгә килә түгелме соң бу бәдбәхет?—диде ул.—Кая бара икән?

Тәрәзәне ачасы урынга, ул аны янәдән шартлатып бикләп куйды да, бермәл кәтеп торды. Менә аяк тавышлары якынайды. Ишекне дә кактылар.

Шәһретдин шул утырган килеш:

— Узыгыз! Аллага шөкер, һәрвакыт ишегем ачык!—дип ишетелерлек итеп эндәште.

Өйгә уртача буйлы бер кеше керде, аңа Шәмсетдин Хөснетдинов та ияргән иде.

— Шәһер Шәрәфетдинов здесь проживает?—диде НКВД кешесе күзләрен аңа текәп.—Мин оперуполномоченный Ильясов булам.

Шәһернең кем икәнлеген «опер» күптән белсә дә, соравы форма өчен генә иде. Инструкция, иптәш, товарищ, инструкция. Иң яхшы әйбер шул. Инструкциядән тайпылмасаң, гомерең озын була, ди НКВД халкы. Менә шулай!

— Здесь, здесь, дип урысчалап җавап биргәч, Шәрәф Фатыймасы янынарак сыенды. Әйтерсең, Фатыймасы аны бу кеше кулыннан саклап кала ала.

«Нәрсә булыр икән инде тагын?»—дип уйлады ул, «опер» килүенең серенә төшәсе килеп.

— Менә сезне Башкортстан ГПУсы тарафыннан кулга алу турындагы ордер,—дип, Ильясов кечкенә генә кәгазь кисәген Ш. Шәрәфкә сузды.—Хәзер үк тентү ясаячакмын.

— Алыгыз, тентегез,—диде Шәһер тыныч кына.—Тентегез!!!

Тентүне Ильясов оста башкарды. Кечкенә бүлмәнең астын-өскә китерде. Шәһретдин тарафыннан төзелгән вәгазьләр кулъязмасын, берничә хатны, паспортны үзе белән алды. Бу 1936 елның 16 апреле иде.

— Җыеныгыз,—диде Ильясов кырыс кына.

Фатыйма Шәһретдиннең күкрәгенә капланып үксеп елады. Әмма Ильясов кызу тотты.

Әйтәсе сүзләрен Шәһретдин дә әйтә алмады, тамагына төер тыгылды. Күз яшьләре Фатыйманың чәчләренә тамды.

— Ярар, Фатыйма. Язмыштан узмыш юктыр, күрәсең... Сине күреп, сөйләшеп калдым, Аллага шөкер. Исән булсак, тагын бер әйләнеп кайтырбыз әле, Алла боерган булса.

Икәүләшеп тиз генә сөлге, эчке күлмәк, җылырак күлмәк-свитерларын җыеп бер төргәк ясадылар. Шәһретдин соңгы тапкыр бүлмәсенә күз йөртеп чыкты да: «Хушыгыз!» дип, урамга атлады. Фатыйма үкси-үкси аның артыннан

омтылды. Ильясов янына килеп җиткәч, Шәһретдин артка борылып, Фатыймага:

— Балаларны саклый күр, гаебем юк бит,—дип эндәште.

Ике ир урам чатыннан кереп югалганчы карап калды Фатыйма. Шул төнне үк ул Казанга кайтып китте, чөнки аңа монда артык күренергә ярамый иде. «Аерылган хатын монда ни эшләп йөри, ни кирәк?»—диярләр. ГПУга бу өстәмә дәлил булуы мөмкин, аптыратырлар. Фатыйма балалары янына ашыкты.

Казан да, Уфа да кызыл шәүлә астында: акрын гына асыл мөселман ирләре, җәмәгатьләрен ташлап, яраткан эшләреннән аерылып, төрмә ишекләрен ачып керәләр дә юкка чыгалар... «Бу нинди, кайда булган хәл, әллә ахырзаман җитә микән?»—дип уйлады Фатыйма, салкын Уфа—Казан поездында кайта-кайта.

Шәһретдиннән беренче сорау алу 19 апрельдә булды. Аны оперуполномоченный Рыбаков алып барды.

Бу җирән адәм холыклы булып күренә. Ул озак кына итеп портфеленнән папирос алып кабыза, ләззәт белән тарта, дәшми. Әйтерсең лә аның да Шәһретдин белән сөйләшәсе килми, әмма акрын гына, җай белән беренче сорау да бирелә:

— Сез кайчаннан бирле Уфада яшисез?

— Уфада мин 1933 елның июненнән бирле яшим. Уфага кызым Асия янына килдем. Ул предприятиедә машинистка булып эшли.

— Сез кайчан ҮМДНгә эшкә кердегез?

— ҮМДНгә мин 1933 елның июнь аенда, Уфага килгәннән соң берничә көн узгач урнаштым. Анда архивта тузу турында таныклыклар бирә идем. 1935 ел башында казначей итеп куйдылар. ҮМДНдә эшли башлау белән кечкенә генә бүлмә дә биргәннәр иде, шунда тора идем.

— Казыйлардан һәм ҮМДН хезмәткәрләреннән кайсылары белән якын мөгамәләдә идегез?

— Барыннан да бигрәк, Тәрҗеманов Кәшшаф белән. Чөнки мин аңа беренче хатыным аркылы кияү була идем.

Шуңа ук охшашлы сорау алу 23 апрельдә дәвам итте. Бу юлы да шул ук Рыбаков:

— Сез ҮМДН тарафыннан командировкага җибәрелгән Сафинга халык белән очрашканда сөйләр өчен тезислар әзерләп бирдегезме?—дип сорады.

Беркадәр сүзсез Шәһернең күзенә карап торгач, тикшерүче кулдан язылган текстны сузды:

— Мә, укып карагыз вәгазегезне,—дип, тәмәкесен кабызып ләззәт белән суыра башлады.

Вәгазь урыс теленә тәрҗемә ителгән иде. Таныш, күңелгә дәрт һәм ышаныч өсти торган юллар күз алдында. Әйтерсең лә төрмә капкалары ачылып, Шәһретдин иректә, гадәттәгечә вәгазь укый:

«Дорогие родные мусульмане! Я приехал к вам как представитель ЦДУМ. Прежде чем говорить, приведу вам краткую цитату из нашего Корана, где богом сказано: «Клянусь от имени периода, что настоящим, истинным мусульманином считается тот, который истинно убежден в верности Ислама, делает добро другим и призывает их быть истинными и выдержанными — все остальные заблудшие и погибшие».

Мы клянемся от имени бога, потому что оно самое великое и доброе в мире.

Мы с вами не довольствуемся отсутствием доброго периода, говоря, что период испортился, стал плохим, это не верно. Это не период испортился, а мы с вами разложились, мы стали плохими, разложились, и период для нас стал плохим.

Есть ли у нас сейчас истинные мусульмане, которые не заблудились, не погибли, если есть, то где они?

Для ответа прочту Вам цитату из Корана, где богом сказано: «Стоящие за добро, не довольствующиеся от вреда, истинно верующие богу люди, ведущие разъяснительную работу среди заблудшихся людей о верности шариату и Исламу — вот эти люди считаются истинными мусульманами.

Быть истинно-верным мусульманином означает своевременно проводить все моления, оказывать всегда братьям по религии мусульманам материальную помощь, никогда их не обижать, наоборот, надо болеть за других мусульман, приводить их к истинно верному мусульманскому пути, агитируя за добро, за выдержанность.

Противники, отступившие от мусульманского пути, не в почете. Поэтому каждый мусульманин должен агитировать друг друга за истинный путь мусульман, учить быть выдержанными и неторопливыми. Это есть мать (золото) успеха в делах всех добрых людей.

В г. Уфе осуществует ЦДУМ, который, обеспечив меня своим удостоверением, откомандировал меня к вам для того, чтобы я исполнил указания о том, чтобы вы агитировали друг друга за истинно добрую и выдержанную мусульманскую религию»[107].

Числосыз, елсыз, имзасыз иде бу документ. Шәһер Шәрәф елмаеп, эчтән генә: «Юкка яшәмәгәнбез икән» — дип

уйлап куйды. Җанга, тәнгә рәхәт булып китте. Һибәтулла өчен, ҮМДН һәм үзе өчен дә шатланды Шәһер. «Афәрин, афәрин Һибәтулла»,— диде ул эчтән генә. Кара әле син аны, нәрсә сөйли бит ә, кыюлык кирәк: хак сөйләгез, сүзегездә нык торыгыз, дип, Мөхәммәд галәйһис-сәламнең кушканнарын төгәл үтәп, башкалар өчен үрнәк булырга чакыра. Тоталитар режим тантана иткәндә халык алдында мондый вәгазь белән чыгу ул, энем, ут белән уйнау белән бер... Һибәтулла — чын мөселман. Соңгы сүзләре дә гыйбрәтле: «Бөек Аллабыз безгә яхшы тормыш бирсен, авылларыбыз, шәһәрләребезне бәхетсезлекләрдән сакласын. Безнең вәгазьләребезне кабул итсен, гөнаһларыбызны гафу итсен».

— Ну, булдымы, нәрсә әйтерсез, гражданин Шәрәф,— диде Рыбаков, Шәһретдинне уятып җибәргән сыман.

«Опер» бу юлы ялгышты, ахрысы. Бу юллар Шәһернең күңелен, рухын ныгытты гына, ул үзендә ниндидер бер җиңелмәс көч хасил булганын тойды: «Алла безнең белән... шөкер»,— дигәнен сизми дә калды.

— Нәрсә, нәрсә понимаете,— дия-дия Рыбаков тоткын кулыннан вәгазьне тартып алды, тәмәке төпчеген идәнгә ыргытып котырына, җикеренә, куркыта башлады, зур йодрыкларын Шәһернең борыны төбендә уйнатты.

«Менә иблис... Шайтан шушыдыр инде»,— диде Шәһер эчтән генә, ә үзе ишетелерлек итеп:

— Ни менә... гражданин начальник, нәрсә дисезме?.. Мин тезислар язмадым... Үзем Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көненә багышлап язган вәгаземне аңа биреп торган идем. Ул 1923, 1927 елларда Казанда вәгазен укыды, әмма минем вәгаземне кайтарып бирә алмаган иде, шул,— диде һәм тикшерүченең яңа соравын көтте.

Тикшерүче башта кызып киткән булса да, ничектер тынды, артык төпченмәде. Башка сорауга күчте:

— Сез соңгы мәртәбә Казанда кайчан булдыгыз?

Шәһретдин өчен бусы да хикмәтле сорау иде. Һибәтулла вәгазеннән соң Казан искә төшә. Сөргеннән кайтып, ил буенча каңгырап йөреп тә үзенә урын таба алмаган Шәһер, ниһаять, Тәрҗеманов Кәшшаф булышлыгы белән ҮМДНдә төпләнгәч, аз гына хәл дә алгач, Казанга гаиләсе, туганнары янына юл тоткан иде...

Рыбаков, гадәттәгечә, сабыр итте, әмма астыртын гына тоткынны күзәтте. Тәҗрибәле тикшерүче иде Рыбаков. Табигать биргән сабырлык, урыста гына була торган дуамаллык — икесе бергә ярыйсы гына нәтиҗәләр бирә иде кебек. Соңгы елларда мулла, мөәзин халкы белән дә шактый очрашырга туры килде — саф, нечкә күңелләләр, күп сөй-

ләмиләр, хак сөйлиләр, рухларын сындыру бик авыр. Менә бусының да әлләни җинаяте юк. Әмма җинаятьче дип табарга кирәк. Шулай кушылган, служба — служба инде ул...

Кызык, тоткын белән тикшерүче икесе ике фикергә биреләп, әллә кайларга кереп киттеләр...

Шәһәрнең күз алдында Казан... вокзал. Нигәдер Уфа поезды шәһәр алды (пригородный) вокзалына килеп туктаган. Хәер, барыбер, моннан шәһәргә узу уңайлырак. Урамда ук зур-зур эскәмияләр, матур гына чәчәкле газоннар... Нәкъ мәйдан уртасында толып кигән кызылармеец белән эт сыны басып тора. Карап торырга мәһабәт, матур, әмма яшәү өчен башка нәрсә кирәклеге һәркемгә дә мәгълүм, ә ни эшлисең? Поездда төшкәч тә менә шунда эскәмиягә утырып, азрак өс-башын тәртипкә китереп, чәчен тарады, янчыкларын барлады. Якында гына үзбәкләр өрек, карбыз саталар, алардан арырак — мичкәдәге селедка. Халык авылга капчык-капчык икмәк ташый. «Заманалар»,— дип куйды Шәһер һәм китәргә әзерләнеп урыныннан торган гына иде:

— Шәһретдин, Шәһретдин, син түгелме соң? — дип, кулына таяк тоткан берәү чатанлап, аңа таба якыная башлады.

Яхшылабрак караса, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә бергә эшләгән, бергә куылган Әхмәтҗан икән. Кочаклашып, исәнләшеп, ә аннан утырып дога да кылгач, Әхмәтҗан:

— Карап торам. Сиңа охшаган да, охшамаган да кебек, үзгәргәнсең Шәһер,— диде.— Шулай да, Шәһер — Шәһер инде. Биттәге җыерчыклар, чал чәч, сакал-мыек сине остазыбыз Галимҗан әл-Барудига тартым ясый.

— Үзгәртәләр агай-эне, үзгәртәләр мөселманны,— диде Шәһер агарып килә торган чәчләрен сыйпап, ә үзе Әхмәтҗанны күзәтте.— Син дә бит яшәрмәгәнсең, әфәндем!

— Мин бит синнән олырак, мин пенсионер инде,— диде Әхмәтҗан.

— Эшләгән булыр идең әле дә, әгәр элекке замандагы кебек «Мөхәммәдия»дә ректор булып эшләсәм. Күргәнегезчә, бу илдә безнең кадерне белмәделәр. Бар җирдә кысу, җәберләү, талау хөкем сөрә.— Боларны Шәһер ишетелеришетелмәс кенә әйтте. Ул Әхмәтҗанга ышанырга ярагангын яхшы белә иде.

Казаннан киткәнче тагын бер очрашып, чәйләп-сөйләшеп утырырга вәгъдә куешып, Әхмәтҗан колхоз базарына юнәлде, ә Шәһер трамвайга утырып, шәһәр үзгенә китте. Соңгы очрашу булган икән. Шәһер вәгъдәсен тота алмады, аңа яшерен рәвештә Казаннан чыгып китәргә туры килде.

Галимҗаннарга бик тиз барып җитте. Дворяннар йорты

яныннан Жуковский урамына җәяү генә килде. Галимҗанның өч бүлмәле яңа фатиры шунда иде.

Ишекне Әсма ханым ачты. Ул бик шатланып, Шәһерне өйгә алып керде. Утырып дога кылганнан соң, Әсма ханым:

— Галимҗан соңрак кайтырмын, бүген партактив диген иде,— диде.

— Нәрсә, Галимҗан да партиягә кердеме әллә?— дип сорады Шәһер беркадәр шикләнеп.— Алла сакласын, безгә — Шәрәфләргә бу килешми. Чукындыра алмаганны, коммунист ясый алмаслар.

— Юк ла... Шулай да соңгы вакытта йөртәләр үзен: йә ачык җыелыш дигән булып, йә партиясезләр белән дигән булып... Беләсезме, укытучы булгач, чакырылгач ни эшлисең, барасың, утырасың инде коммунист иптәшләрне җәлләп, вакыт уздырып, юк-бар тыңлап. Алар белән булгач, аңа да эләгеп тора инде. Көн саен диярлек бер нәрсә чыга, соң кайта. Ә иртән 8 тулганчы лекцияләргә китә. Аннан бит әле ул ИМЛда, технология институтында һәм башка җирләрдә дә эшли.

Менә шулай сөйләшә-сөйләшә алар ашап-эчтеләр. Соң булса да, Әсма ханым Фатыйма янына сөенче хәбәре әйтергә йөгерде. «Ярый, Щапов урамы ерак түгел, ә Зифаларга иртәгә хәбәр салырбыз, боерган булса,— дип уйлады Жуковский урамы буйлап йөгерүче Әсма.— Төнлә күрешүләре хәерлерәк, күз-колак азрак булыр». Бу чыннан да шулай иде. Төнлә очрашулар гадәткә кергән иде ул елларда.

Әсма чыгып киткәч, Шәһер Галимҗанның язу өстәле артына утырып, газета-журналлар карый башлады. Менә кулга «Красная Татария» газетасы килеп эләкте. Елын, көнен карады: 1934 ел, 5 апрель. Иске газета икән, дигән уй узды аның башыннан. Газетаны актара торгач, ул кара белән сызылган юлларга игътибар итте, ә анда ТАТЦИКның партячейкасы турында сүз бара икән: «Партячейка һәм аның җитәкчесе иптәш Каганов Татар Үзәк Башкарма Комитеты аппаратында солтангалиевчы Шәрәфнең консультант булып эшләвен яхшы белделәр, ләкин моңа тыныч кына түзеп килделәр. Ә инде администрация бу хакта белеп, Шәрәфне эштән кугач, иптәш Каганов һәр җирдә Шәрәфне бары ул гына кудыруын расларга тырышты. Сүз уңаеннан, Хәмидуллин Шәрәфне аерым бер үҗәтлек белән яклады һәм аны бик булдыклы хезмәткәр итеп күрсәтергә тырышты...»

Ишек шакыдылар. Шәһер тиз генә фатир ишеген ачты. Каршында кулына портфель тоткан, пөхтә итеп киенгән, ак күлмәк өстеннән кара галстук таккан Галимҗан тора иде.

Ул, шатланып:

— Абый,— дип эндәште һәм Шәһерне үз кочагына алды.— Молодец, әйбәт иткәнсең. Ничек килеп чыга алдың? Кайчан килдең?

Залга узып, диван, урындыкларга утырышкач, Шәһер:

— Әйдә, энем, бер дога кылыйк,— диде. Бермәл һәркайсы тын гына белгәнен укыды.

Шуннан соң Шәһер сүзен дәвам итте:

— Амин, Галимҗан энем, хәлләрегез ни чама, түзәрлекме әле сезләрдә?

Галимҗан кичке аш турында да онытты. Ишек бикләнми калган: Әсма ханым белән Фатыйма килеп керделәр. Тагын бер оныта алмаслык очрашу. Артык тавышсыз гына хәл-әхвәл сөйләшенде, аннан — кичке аш, чәй. Төне буе залда һәм аш-су бүлмәсендә ут янды. Әсма белән Фатыйма бәйрәмчә киенеп ике арада йөрделәр. Ә инде икәүдән-икәү генә калганда, нидер серләштеләр. Шатлыклы, бәхетле сәгатьләр шулай узды.

Икәүдән-икәү генә калгач:

— Энем, Казанда «шәрәфчелеккә» каршы тагын һөҗүм башландымы әллә?— дип сорап куйды Шәһер, өстәлдәге әле генә укып чыккан газетаны энесенә сузып.

Галимҗан бермәл дәшми торды. Әйтерсең лә абыйсын артык борчыйсы килмәде. Нигә дип әле кыска гына очрашу вакытында да бер-береңне борчырга. Ә шулай да... Ул җавап көткән абыйсына карап:

— Хәтерлисеңдер, 1932 елның 25 маенда Борһанетдин абый Ташкентта кулга алынган иде. 1934 елның ахырында иреккә чыкты. Эш эзли, Алма-Атада булса кирәк. Гыйльметдин абый Оренбургдан Ленинградка китәргә мәҗбүр булган иде. Казанга кайтармады НКВД, Казанга гына түгел, Башкортстанга кайтырга да рөхсәт бирмәделәр.

— Эшләре җайланып килә иде Гыйльметдиннең, үзем аларда булып килгән идем бит,— диде Шәһер Галимҗан сөйләгәннәргә кушып.— Анда алар Кәрим әфәнде Сәгыйтов, Даут Еникеев, Вәли Зәбиров, Фатыйх Гыйззәтуллиннар белән аралашып көн итәләр. Соңгы хатында Гыйльметдин бухгалтер булып урнаштым дигән иде.

Бераз торгач, ул Галимҗаннан:

— Ә Шиһабетдин абый ни хәлдә соң?— дип сорады.— Хаты да, хәбәре дә юк аның. Адресын да белмим.

— Төрле җирдә яши, аз гына Фатыймаларда да торды, бездә дә кунгалый. Урнашыр, бер вариант бар әле,— диде Галимҗан абыйсын тынычландырып.— Үзе килеп чыкмасмы әле. Ул да 1934 елның ахырында гына кайтты һәм бераз ветеринария институтында каравылчы булып эшләгән иде,

төрле сәбәпләр табып эштән кудылар... Әлегә эшсез. «Шәрәфчелек» дигән мәсьәлә менә шулай тора, абый.

— Барыбызны да кайгыртасың, үзеңнең дә эшләрең шәп түгел бит.

— Абый, менә мин сиңа бер мәзәк сөйлим, тыңлап кара, бәлки бераз кызык булыр үзеңә, юкса гел авыр, авыр дибез. Берәү шулай үлеп киткән икән. Сорашалар икән икенче берәүдән: «Берәр сүз әйттеме соң бу кеше үләр алдыннан?»—дип. Теге кеше әйтә ди: «Әйе, мин шунда идем. Сөйләшеп тордык: авыр дип утырган иде ул, ә мин уйлыйм—кемгә җиңел икән хәзер?—дип. Карасам, үлеп тә киткән икән».

— Интеллигент халкына бигрәк тә авыр инде ул,—диде Шәһер аны бүлеп.—Мәзәгең әйбәт кенә түгел, ә тирән эчтәлекле дә. Халык әйтсә хак әйтә—бу да безгә мәгълүм. Ә шулай да...—ул Галимҗанга сораулы йөз белән борылды.

Галимҗан әтисе Шәрәфетдин алдында җавап биргән кыяфәт белән:

— Абый, беләсең бит инде син безнең татарны. Көнләшү, уңай эшкә таяк тыгу—болар барысы да безнең халыкны артка тартканнарның берсе,—диде.—Әле менә фәнни мәкаләләр чыгарып, Мәскәү, Ленинград галимнәре белән берлектә телнең кешелек дөньясындагы әһәмиятенә бәйләнешле мәсьәләләр өстендә уңышлы гына эшли башлаган идем, үземә, эшемә каршылыклар сизә башладым. Әлегә ул кадәр үк куркынычлы булмаса да, кем белә... Бигрәк тә кафедра мөдире борчыла, юньле эше булмаса да, профессор булырга теләге бик зур. Миннән аз гына алда профессор званиесенә документлар җыя башлады. Шәһәрдә төрле сүзләр йөри: имеш, Казанда, бигрәк тә педагогия институтында яшертен милли контрреволюционерлар оясы бар, астыртын эш алып баралар икән. Имеш, алар Троцкий, Солтангалиев идеяләре белән яшиләр, имеш... Белеп тор, син яхшы ук белгән, теге татар фәнни институтының директор урынбасары булып эшләгән тарихчы Корбутны да алдылар һәм өч елга сөргенгә җибәрделәр. Гали Кудояровны да. Син аны яхшы ук беләсең, бездә булганы бар. Бик уңган егет, Башкортстан ягыннан.

— Аңа тагын ни булган?—диде Шәһер.

— Ул бит теге 1931 елдагы икмәк реквизицияләү чорында икмәк реквизицияләү кампаниясен, шул вакыт халыкның икмәген талаган Разумовларны да тәнкыйтькә алган, крестьян халкын яклап чыккан иде... Нәтиҗәдә аны ике мәртәбә тәүбә иттерделәр инде. Шулай булуга карамастан,

«Гали Кудояров эше» бетмәде, киресенчә, 1932 елның декабрендә аны кулга алдылар, партиядән чыгардылар[108]. Менә шуларны кара әле,— дип, Галимҗан абыйсына 1935 елның гыйнвар аенда чыккан «Красная Татария» газеталарын тоттырды. Үзе кухняга кереп китте.

Газеталарның икесендә дә студентлар конференциясе, оппортунистлар, троцкистлар, уң оппозиционерлар, буржуаз белгечләр турында язылган иде. Имеш, алар пединститутта контрреволюцион эш алып баралар икән.

Галимҗан Шәһерне кухняга чакырды:

— Әйдә, тагын бер-ике чынаяк чәйне өстик, абый,— диде ул хуш исле кытай чәен чынаякларга сала-сала. Хәмердән баш тарттылар. Доцент Галимҗан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең элеккеге укытучысы булган абыйсы Шәһретдиннең хәмергә булган мөнәсәбәтен яхшы белә иде.

— Күргәнеңчә, эшләр бездә шәптән түгел. Тынычлык юк. Каршылыклар, аңлашылмаучылыклар укытучылар, студентлар арасында да киң таралган. Менә әлеге конференцияне алыйк. Аның төп бурычы — троцкист-зиновьевчы оппозицияне тәнкыйть итү. Конференция башлангач та шәһәр комитеты вәкиле Шикаев, коммунист Григорьев конференцияне җанландырып җибәрү өчен уку отличнигы, рәсеме күренекле кешеләр тактасында эленеп тора торган студент Рафиковтан чыгыш ясауны сорыйлар, әлбәттә, чыгыш ясаганда аңа оппозицияне, троцкист-зиновьевчы блокны тәнкыйть итәргә кушалар. Рафиков килешә һәм чыгыш ясый. Менә шунда башлана инде әкәмәт! «Әгәр дә Зиновьев контрреволюционер булган булса, аны Коминтернның председателе итеп сайламаган булырлар иде»,— ди ул. Конференцияне оештыручылар моны провокация дип кабул итәләр.

Студент Әмиров утка май сибә: «Сталин хәзер генә юлбашчы булды, ә гражданнар сугышы чорында күбрәк Троцкий эшләде. Бер елдан Совет властеннан «йон һәм көл» (пух и прах) генә калачак»,— ди. Бу факт Казанны гына түгел, коммунистик Мәскәүне дә бик каты борчый. Күрәсең бит, «Правда»да безгә урын табылган. Казанда тиз арада чаралар да күрелә башлый. Партҗыелышлар уза, ачыктан-ачык гаеп ташлаулар башлана, ә конференцияне оештыручылардан Шикаев, Медведев, Григорьев партиядән куылалар. Бүгенге көндә бу эш дәвам итә.— Шушы вакыйгалардан соң миңа каршы да һөҗүм көчәйде. Күп сөйләп торасы түгел, юк-барына да язма документлар бар. Мә, үзең укы, абый,— дип, Галимҗан Шәһергә тагын бер кәгазь сузды.

Бу Галимҗанның үз кулы белән язылган, зур булмаган

кулъязма иде. Анда: «Бездә, институтта, кайчандыр тупас сәяси хатлары булган, мәсәлән, профессор Эльвов кебек кешеләр эшли. Андый хаталар безнең хезмәткәрләребез Сәйфидә, Еналиевта, уң-оппортунистик ялгышулар А. Григорьев, Г. Нигъмәтуллин тәҗрибәләрендә, буржуаз күрсәтмәләр Сенгалиевич, Лисцер һәм башка фәнни хезмәткәрләрнең дә эшләрендә, хезмәтләрендә бар» — дип язылган иде. Тиздән Шәрәф фамилиясе дә күзгә чалынды: «Ип. Назаров, аңа Шәрәфнең иҗтимагый йөзен (оригиналда — общественная физиономия.— *Р. В.*) тикшерүне оештырырга кушылса да... берни дә эшләмәгән... партия әгъзасы, фәнни хезмәткәр Курмаевка Еналиев—Даутов эшен тикшерергә кушылган иде, бернәрсә дә башкарылмаган. Сыйнфый уяулыкның зәгыйфьләнүе...»[109].

— Менә ничек икән, энем Галимҗан. Күрәсең, мин Дения Нәзарәтендә (Мөселманнарның Үзәк Диния Нәзарәте.— *Р. В.*) «җәннәттә» яшәгән кебек яшим. Сездә эшләр хөрти, хөрти,— диде Шәһер, үз-үзе белән сөйләшкәндәй.

— Сездә ничегрәк соң? — дип, Галимҗан сүзне Уфа якларына борды.

— Уфада да дошман эзлиләр. Безнең Мөфтият үзе бер бәләкәй утрау кебек: җәберләнгән, куылган, мәсхәрәләнгән мөселман безгә килеп сыена, җаен таба Кәшшаф абыең. Менә үзем дә бит шул хәлдә идем, алар ярдәм кулы сузмаса, кая бармак кирәк? Кечкенә генә бүлмәм бар — уңайлы, җылы. Хәлдән килгәнчә эшлим, китап язу турында хыялланам, Галимҗан энем,— дип җаваплады Шәһер.

Фатыйма кухня ягыннан чыгып, Шәһергә карап:

— Әйдә, сиңа әйтәм, балаларны күреп кит! — дигәч, караңгы төн булуына карамастан, тиз генә җыенып чыгып киттеләр. Кеше-кара күрмәде кебек. Җәйнең җылы, матур вакытлары. Төннең таңга әйләнгән чагы. Офыкта кояшның алсу нурлары чагыла, бакчаларда сандугачлар сайрый. Юлда күбрәк сүзсез генә бардылар, сөйләшкәндә дә бер-беренә акрын гына, кеше ишетмәслек итеп эндәштеләр. Хәер, урамда кеше юк диярлек иде: каршыга берничә исерек, берничә машина гына очрады. Шәһергә ян-яктан гына берәү күзәтә кебек тоелган иде, ләкин Фатыймага аны-моны белгертмәде.

Тиз кайтып җиттеләр. Өйдә ут юк. Балалар йоклыйлар. Төнне хәл-әхвәл сорашып, туганнарны, белгәннәрне искә алып утырдылар. Икесенең дә күзенә йокы кермәде. Бу балалар ничек аякка басарлар... (Кечкенә Нәвар төш күрә ахры, нидер сөйләнә, көлгәләп тә куя. Шәһернең үзенә дә бу төштә генә кебек тоела.) Эх, менә шулай тыныч кына,

бала-чагаң белән бергә гөрләп яшәсәң икән. Эх, заманалар... Без патша һәм аның жандармнары белән шундый тормыш өчен көрәштекме? Белгән булсакмы?..

Таң атты. Берәм-берәм балалар да уянды. Сания белән Нәвар әтиләрен икесе ике яктан сарып алдылар. Сания инде зур кыз булган, аңа 15 яшь. Ул әтисе белән кайгысын уртаклашты:

— Әти, мине техникумга алырга теләмиләр, мулла кызы син, диләр,—дип, елар дәрәҗәгә җитеп сөйләнде...— Әти, дим, әти!

Ата кеше дәшми торды, аннан соң кырт кисеп:

— Төкер, кызым, техникумнарына!—диде.

Ә Нәварга шаярырга, уйнарга булсын.

— Абый Бохарадан хат язмыймы?! Абый сагындыра,— ди.

— Язмышлар йөртә—атаны да, баланы да... Язар әле, кызым, уңайсызрактыр чит җирләрдә,—ди Шәһер, кызының чәчләрен сыйпап.

Менә бүген тикшерүче аннан сорау ала. Казанны рәхәтләнеп исенә төшерде Шәһер, әмма гаиләсе турында ләм-мим. Әйтерсең лә хатыны да, өч баласы да аныкы түгелләр. Шулай кирәк. Рыбаков та гаҗәп кеше—бу турыда ләм-мим. Балаларны җәлләгәндер, ә бәлки артык тирәнгә китеп эшен арттырасы килмәгәндер—анысы бер Ходайга мәгълүм. Шөкер, ул бу турыда сорашмады. Соловки лагерьларында да шулай бер рус очраган иде. Ул Шәһерне очраткан саен: «Почему не молишься, бабай? Скорее домой поедешь»,—дисә дә, намаз укыганны күрсә, шунда ук күрмәмешкә салышып, борылып китәдер иде.

— Казандамы?—дип кабатлап сорады Шәһер, уйларыннан арынып, һәм рәхәтләнеп:—1935 елның августында булдым.

Рыбаков җаваптан канәгать калды булса кирәк, башка сорауларга күчте. Ул Шәһернең Мөселманнарның Үзәк Дини Нәзарәтен ябуга ничек караганлыгы белән кызыксынды, аннан соң:

— Панисламизм идеяләрен уртаклашасызмы?—дип сорады.

— Нәрсә соң ул, панисламизм, мин андый нәрсәне белмим бит, гражданин начальник?

— Ә сез мөселманнар өчен бүген ни теләр идегез?— диде «опер» моңа каршы тыныч кына.

— Минме? Беренче булып, мөселман халкының барысын да белемле итеп күрәсем килә, ә икенчедән, инде ул техниканы яхшылап өйрәнсен. Менә минем теләк шул.

— Ә сәяси хокуклар турында нинди фикердә торасыз, бу турыда үзегезнең уйлаганыгыз бармы? — диде Рыбаков, балыкны кармакка эләктерергә теләгән балыкчы кебек.

— Белем белән техниканы кирәк кадәр алганнан соң, бу мәсьәлә үзеннән-үзе алга басачак, әмма минем бу турыда уйлаганым юк әле,— дип җаваплады тоткын, мөлаем гына елмаеп.

Рыбаков та елмая һәм эчтән генә: «Ай-һай акыллы да инде бу мулла халкы, әллә бөтен татар халкы шулаймы икән бу?» — дип уйлап куя һәм уйларыннан арынып, сорау алуны дәвам итә:

— Сез мөселманнарның артта калуын, изелеп яшәвен, ярлы икәнлекләрен кайдан белдегез һәм монда кем гаепле?

— Лагерьда,— ди бер сүз белән Шәһер.— Барына да патша хөкүмәте гаепле, патша хөкүмәте!

Тагын берничә сорау биргәч, сорау алу тәмам була. Бүлмәдә тынлык урнаша. Рыбаков:

— Увести! — дип кычкыра.

Ничек кенә булса да, бүген Шәһер үзен җиңүче итеп күз алдына китерде.

Камерада да аның үзен генә тоталар иде. Шулай да ул бүген тиз йоклап китте. Төшендә әлеге дә баягы Рыбаков, әмма кулына зур кара күсәк тоткан, җикеренә: «Сознавайся, фашист татарин, японский шпион»,— дип өскә килә. Ул сугам дигәндә генә, Шәһер кырыйга тайпыла. Шуннан соң Шәһер йөгереп китәргә тели, әмма аяклары алга атламый. Ниһаять, Рыбаков аның башына күсәк белән суга... Уянып, күзләрен ачса, үз камерасында нарда ята икән.

Бу 1936 елның 14 май иртәсе иде. Шәһер бу төшне дә үзе өчен начарга юрады. Юраганнары юш килә иде аның. Беренче мәртәбә кулга алыр алдыннан да ул төшендә бер атка атланып йөрде, ә иртән торгач Фатыймага: «Мине шушы арада алып китәчәкләр»,— дигән иде. Чыннан да шулай булды.

Ул көннәрдә Рыбаков, чыннан да, Шәһергә зур «күсәк» әзерләү өстендә эшли башлаган иде. Ул Шәһерне яхшы белгән кайберәүләрне көчләп кирәкле материалларга кул куйдыра алды. Мәсәлән, Габдрахман Рәсүловка ул, допрос ала башлагач ук: «Очрашу вакытында Шәһер Шәрәф нәрсә сөйләде?» — дигән сорау бирде һәм Рәсүловтан: «Шәрәф тиздән Совет власте бәреп төшереләчәк: Япония һәм Германия аңа каршы сугыш башлаячак, илдә восстание булыр, чөнки халык дәүләттән канәгать түгел. Мөселманнарның Үзәк Диния Нәзарәте безгә җитәкче орган сыйфатында кирәк булыр. Шуңа күрә без бу үзгәрешләргә алдан әзер

булырга тиешбез. Шәрәф Шәһер үзе китап яза һәм, хакимият үзгәрүгә, ул китапларны халыкка таратырга уйлый. Аннан соң аның китабын милли мәктәпләрдә дәреслек итеп муллалар үз эшләрендә файдаланачаклар. Бу китапның барлыгын бары тик бер генә кеше — Тәрҗеманов кына белә,— дип әйтте»,— дигән җавап алды. Һәм нәкъ менә 14 май көнне Рәсүлов бу сүзләргә өстәп: «Шәһер Шәрәф Япония белән Германиягә ышана: «ул алар мөселман дәүләтен төзергә рөхсәт бирәчәкләр, чөнки эмиграциядәге Гаяз Исхакый, Идрисов Галимҗан, Ибраһимов Рәшитләр бу турыда алдан ук килешеп куйганнар, диде. ... Чыннан да, Тәрҗеманов Мөселманнарның Үзәк Диния Нәзарәтендә контрреволюцион оешманы җитәкләгән. Аның иң якын булышчылары — Шәрәф һәм Мозаффаров Хәнәфиләр. Шул ук фикердә булучылардан Камалетдинов, Магкуловларны күрсәтергә мөмкин, әмма соңгы вакытта болары уйлана башладылар»,— дигән күрсәтмә бирде. Шуннан соң тикшерүче Рәсүловка Тәрҗемановка гына кагылышлы сораулар яудыра башлады:

— Сез үзегез чыннан да нинди дә булса яшерен оешма Тәрҗемановны Совет властена каршы көрәшергә мәҗбүр итә дип уйлыйсызмы?

— Әйе, мин чыннан да Тәрҗеманов ниндидер яшертен күрсәтмәләргә таянып җитәкчелек иткәндер дим, чөнки ул бик ышанып эш итә иде. Мин моны чит илдән булышлык булу белән аңлатам.

— Тәрҗемановка кайдан андый ышаныч килергә мөмкин. Ни өчен заграница аңа шулай карый?

— Тәрҗеманов бертуктаусыз чит ил белән, чит илдәге дуслары белән бәйләнештә торды. Ул дуслары белән 1925—1926 елларда Мәккәдә булып узган конгресска барганда очрашты. Гаяз Исхакый, Галимҗан Идрис, Садрый Максудов, Фуад Туктаров, улы Идрис һәм башкалар белән очрашты. Алар, ак эмигрантларның башлыклары буларак, Тәрҗеманов белән хәбәрләшеп торуны килешкәннәр. Моннан ары Тәрҗеманов соңгы көннәргә кадәр Мәскәү мулласы Габдулла Шәмсетдинов белән хәбәрләшеп торды, ә ул Финляндия ак эмигрантлары белән тыгыз бәйләнгән. Аны шуның өчен кулга да алдылар.

— Сез ни өчен Шәмсетдинов чит ил белән бәйләнешен Тәрҗемановтан яшергән дип уйлыйсыз?

— Мин аларның нәрсә уйлаганнарын яхшы беләм. Шәмсетдинов, төрек-татар милләте Совет власте вакытында харап булачак, ди. Ул үзенең канәгатьсезлеген ачыктан-ачык әйтеп килде. Латин шрифтын кабул итүне Шәмсетдинов

үсеп килә торган төрек-татар яшьләрен үз әдәбиятыннан аеруда иң көчле чара дип санады. Ул Совет властен икейөзлелектә, алдакчылыкта гаепләде. Мәсәлән: «Мәккәгә бара торган Кытай мөселманнарын Мәскәүдә мәчетләр күрсәтеп алдадылар. Алар, Мәскәү мәчетләренә карап, бөтен илдә шулай диеп уйлыйлар, ә чынбарлыкта илдә мәчетләр бөтен җирдә ябылалар»,—диде. Шәмсетдинов фикере буенча, Мөселманнарның Үзәк Диния Нәзарәтен бары тик Тәрҗемановкына җитәкли алачак, чөнки ул беркайчан да Совет власте белән дингә зыян китерерлек килешүгә бармаячак.

1936 елның 19 июнендә булган сорау алу вакытында сүз Тәрҗемановның мөфтигә язган һәм Мөселманнарның Үзәк Диния Нәзарәтенең язмышына кагылышлы хаты турында бара. Монда да күсәкнең юан башы Шәһер Шәрәфкә төшә. Рәсүлов: «Шәрәф һәм Мозаффаров Хәнәфи, һичшиксез, бу турыда белгәннәр, чөнки Абзгильдин Тәрҗеманов каршында зур ышаныч белән файдаланды» дигән бик кирәкле күрсәтмә бирә.

Моннан тыш, Шәһергә карата кайбер материаллар Зыя Камалидан, Абзгильдин, Фәхретдинов Мөхәммәтгаталардан да алына. Аларда Шәрәфләрнең бергәләшеп милли дәүләт төзергә хыялланып йөрүләре, «Мәгариф» нәшрияты ачып, анда чыгарылган китапларны халыкка җиткерүләре әйтелә. Алардан тыш та куркытып, кыйнап, алдап җыелган беркетмәләргә нигезләнеп, тикшерүче Рыбаков 1936 елның 23 июнендә Шәһер Шәрәфнең җинаять эшен тәмамлый һәм аның тарафыннан төзелгән «Карар» нигезендә 24 июньдә 2244 номерлы эш буенча Шәһер Шәрәф һәм Хәнәфи Мозаффаров РСФСР Җинаять Кодексының 58 һәм 10-11 маддәләре буенча гаепләнеп җавапка тартылалар. Әлеге документта түбәндәге юллар бар:

«1933 елда МҮДН (Мөселманнарның Үзәк Диния Нәзарәте) мөфтиенең элекеге урынбасары Тәрҗеманов үзе кебек үк панисламистик карашлы һәм сөргеннән кайткан Шәһер Шәрәфне һәм Мозаффаров Хәнәфине эшкә кабул иткән. Шул вакыттан башлап МҮДН эчендә Тәрҗеманов җитәкчелегендәге төркем оешкан. Аның максаты—мәчетләрне саклау өчен көрәшкән булып, Советка каршы булган руханиларны берләштерү һәм аларны Совет хакимиятенә каршы активлаштыру, чит дәүләтләр белән сугышта Совет хакимиятенең тиз арада һәм котылгысыз рәвештә һәлак булачагы хакында имеш-мимешләр таратып, җиңелү коткысы тудыру булган.

Әлеге эш яшерен күрсәтмәләр белән махсус вәкилләр

җибәрү рәвешендә башкарылган. 1935 елда мондый эшчәнлектә фаш ителеп, 5 елга сөргенгә җибәрергә хөкем чыгарылган Сафин — моның бер мисалы. Алар, дини эш башкарган булып, төрле җирләрдән үзләренең тарафдарларын чакырганнар, һәркайсына контрреволюцион эш буенча күрсәтмә биргәннәр.

СССР эчендәге эшчәнлек белән генә чикләнмичә, Исхаков Гаяз, Идрисов Галимҗан, Ибраһимов Рәшит һәм башкалар йөзендәге төрки-татар ак эмиграциясе белән элемтәләр урнаштыру өчен, бу төркем барлык мөмкинлекләрне һәм каналларны файдаланган, Германия һәм Япония ярдәменә исәп тоткан. Бу элемтәнең тамырлары революциягә кадәр һәм революциянең беренче чорында ук туган.

Германия һәм Япония белән сугыш нәтиҗәсендә Совет хакимиятенең тар-мар ителүенә ышанган хәлдә, СССРның эчендә баш күтәрергә ниятләп, әлеге контрреволюцион төркем аерым бер мөселман дәүләте оештырырга, үзенең милләтчелек идеяләрен тормышка ашырырга өметләнгән. Бу инанудан чыгып, контрреволюцион төркем Совет хакимияте бәреп төшерелгәннән соң бастырылачак дип уйланылган китапларның кулъязмаларын әзерләгән. Әлеге эшкә Шәһәр Шәрәф һәм Мозаффаров Хәнәфи җитәкчелек иткән. Әлеге китапларның Шәрәфтән табып алынган кулъязмалары ачыктан-ачык аның (Шәрәфнең — *Р. В.*) Советка каршы булган панисламистик карашларын чагылдыра. Мәсәлән, вәгазьләр җыентыгы кулъязмасында Шәрәф мөселманнарны берләштерү, аларның милләт һәм дин мәнфәгатьләре хакына көрәшү зарурлыгы хакындагы фикер үткәрә, Совет чынбарлыгын кире кага һәм башкалар.

...Мәдрәсә тарихы кулъязмасында Шәрәф русларны иң тупас, башка халыкларга карата иң рәхимсез халык буларак бәяли.

Югарыда күрсәтелгәннәр нигезендә гаепләнәләр:

Шәрәф Ш. Ш. 1887 елда туган, СССР гражданы, чыгышы белән ТАССРның Буа районы Аксу авылыннан, татар, 1896—1920 елларда Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең дин укытучысы, шул ук вакытта китаплар һәм журналлар нәшер итүдә аркадаш (компаньон) булган. 1920—1928 елларда Казанда яшәгән. 1933 елда, кулга алынганчы, Уфада МҮДНдә казначей булып эшләгән. Партиясез. Панисламистик карашларда тора. Югары дини белемле. Армияләрдә хезмәт итмәгән. 1928 елда Советка каршы эшчәнлек җәелдергән һәм яшерен дини курслар оештырган өчен ОГПУ коллегиясе тарафыннан 3 елга концлагерьга хөкем ителгән. Җәза срогын тутырган. Аерылган.

Контрреволюцион милләтчелек төркеме әгъзасы буларак, контрреволюцион мөселман руханиларын Совет хакимиятенә каршы көрәшкә туплауда актив катнашуы өчен гаепләнә.

Үзенең фикердәшләре аркылы һәм хезмәтләренең кульязмаларында Совет строен кире кагучы контрреволюцион милләтчелек идеяләрен тараткан, ягъни РСФСР Җинаять Кодексының 58 маддәсе 10-11 пунктларында каралган җинаятьләрдә гаепләнә.

Мозаффаров Хәнәфи Мөхәммәтҗан улы, 1881 елда туган, СССР гражданы, чыгышы белән ТАССРның Саба районы Кеше Шинар авылыннан, татар, мулла улы, 1926 елга кадәр үзе дә мулла булган, 1930 елдан МҮДН каравылчысы булып эшли. Партиясез, панисламистик карашларда тора. Югары дини белемле. Армияләрдә хезмәт итмәгән. 1926 елда Советка каршы эшчәнлеге өчен ОГПУ коллегиясе тарафыннан сөргенгә хөкем ителгән. Сөргендә Костромада булган, 12 һәм 22 яшьлек кызлары бар. Контрреволюцион милләтчелек оешмасы әгъзасы буларак гаепләнүе түбәндәгедән гыйбарәт:

1. Контрреволюцион мөселман руханиларын Совет хакимиятенә каршы көрәшү өчен туплау.

2. Милли һәм дини хорафатларны файдаланып, Совет хакимияте чараларына каршы агитация җәелдерү, ягъни РСФСР Җинаять Кодексының 58 маддәсе 10-11 пунктларында каралган җинаятьләр.

Эш буенча тикшерү тәмамланган дип исәпләнә һәм СССР Эчке эшләр халык комиссариаты каршындагы Махсус Киңәшмәгә (ОС НКВД СССР.— *Р. В.*) тапшырыла. Уфа төрмәсендә тотылучы гаепләнүчеләр — Шәһер Шәрәф һәм Мозаффаров Хәнәфи СССР Эчке эшләр халык комиссариаты каршындагы Махсус Киңәшмә карамагында исәпләнәләр.

СПОУГБның 4 бүлеге оперуполномоченные, Дәүләт куркынычсызлыгы өлкән лейтенанты *Рыбаков*

СПОУГБның 4 бүлеге начальнигы лейтенант *Г. Б. Михайлов*

«Килешәм» УНКВДның СПОУГБ начальнигы ярдәмчесе лейтенант *Г. Б. Катков.*

Белешмә: 1) Матди дәлилләр: Шәһер Шәрәфнең вәгазьләр җыентыгы, көндәлеге, мәдрәсәләр тарихы буенча кульязмасы;

2) гаепләнүчеләр Шәһер Ш. һәм Мозаффаров Х. Уфа төрмәсендә 1936 елның 19 апреленнән тотылалар.

Дөрес: БАССР УНКВДсы СПОУГБсының 4 бүлеге оперуполномоченные өлкән лейтенант Рыбаков»[110].

1936 елның 27 июнендә бу карар прокурор Коробов тарафыннан да раслана.

Махсус киңәшмә аларның икесен дә бишәр елга ИТЛларга (хезмәт белән төзәтү лагерьлары.— *Р. В.*) җибәрергә карар чыгара. Шәһер Шәрәфкә Омск лагерьларын билгеләр, әмма бу карар тормышка ашырылмый кала: 1936 елның 21 июнендә К. Тәрҗеманов һәм тагын шактый кеше кулга алынгач, МҮДН белән бәйле зур бер яңа процесс әзерләнә башлый. Ул милләтчеләр, панисламистлар, Советка каршы көрәшүчеләр, шпион-диверсантларны фаш итү эше кебек зур итеп әзерләнә.

Дүрт ай дәвамында Шәһер Шәрәф үзенең һәм якын хезмәттәшләренең баш очында кара болытлар җыелганын һәм куерганын белми утыра. Ниһаять, 1936 елның 20 октябрендә аны яңа карар белән таныштыралар. Карарда болай диелә: «Япония разведкасы оештырган контрреволюцион милләтчелек оешмасына җитәкчелек итүен таныган Мәскәү мулласы Абдулла Шәмсетдинов белән тыгыз элемтәдә торуы һәм аның белән бергә контрреволюцион эшчәнлекне киңәйтү максатында МҮДН оешмасын яптыруның кулайлыгы күрсәтелгән Тәрҗеманов хатын укуда катнашуының тикшерү нәтиҗәсендә ачыклануы һәм гаепләнүче Ш. Шәрәфнең үзенең боларны тануы сәбәпле, РСФСР Җинаять Кодексының 91 маддәсе буенча

КАРАР КЫЛЫНДЫ:

Ш. Шәрәф эшен тикшерү материалларын 2301 номерлы тикшерү эшенә кушарга, Ш. Шәрәфнең МҮДН эчендәге диверсион контрреволюцион оешмада катнашуы хакында яңа җинаять эше ачарга һәм шул сәбәпле, аны концентрацион лагерьга җибәрмичә, 1 категория буенча Уфа төрмәсендә калдырырга».

22 октябрьдә Шәһер Шәрәф бу документка кул куя.

БАССР НКВДсы хезмәткәрләре Нуретдинов, Шляпников һәм Карпов яңа җинаять эше оештырып, аны 2301 нче номер белән билгеләр. Барлыгы 21 кеше кулга алынып, шуларның 11 е әлеге 2301 нче номерлы эш буенча җинаять җаваплылыгына тартыла. Шәһер Шәрәф, Д. Абзгильдин, Г. Хәбиров, М. Камалетдинов, Х. Әхтәмов, А. Маннанов, З. Мөҗәвиров, М. Усманов, Г. Ханисламов, Т. Мостафин, Х. Абдрахманов — барысы да РСФСР Җинаять Кодексының 68 маддәсе 4-11 параграфы буенча хөкем ителеп, шпионлык, диверсантлык эше алып баруда, Япония, Герма-

ния разведкалары тарафыннан оештырылган яшерен контрреволюцион милли оешма төзүдә гаепләнәләр. Бөтен контрреволюцион эш мөселманнар үзәге җитәкчесе Тәрҗеманов Кәшшаф тарафыннан эшләнгән, имеш.

Сакчылар бу юлы Шәһерне Зыя Мөҗәвиров белән япон, герман шпионнары, диверсантлар сыйфатында йөртәләр. Шуңа күрә саклау да бик каты иде. Хәлнең көннән-көн авырая һәм куркыныч төс ала барганын яхшы аңлаган Ш. Шәрәф Зыя Мөҗәвировка шакката: бу уңган, матур башкорт егете тоткыннар арасында ак күгәрчен кебек аерылып тора. Барыннан да бигрәк Зыя әфәнде мөселман җырларын, татар-башкорт музыкасын ярата. Каяндыр җыр, музыка тавышы ишетелсә, ул үзен-үзе онытып, бирелеп тыңлый иде.

1938 елның 1 гыйнварында БАССР Югары судының махсус коллегиясе утырышында Мөҗәвиров З. Ф. үзен җинаятьче дип танымый.

Шулвакыт шаһит булып килгән Зариф Бәширов:

— Сез, Зыя Фатыхович, ни өчен Америкадан кайттыгыз? — дип сорый.

Тоткын:

— Мин мөселман музыкасын яратам, ә бу нәрсә Америкада юк, — дип җавап кайтара.

Мөҗәвиров Зыя Фатыйх улы 1889 елда туган, милләте — башкорт, партиясез. Башкортстанның Учалы районыннан, Җиде ел Кыргызстанның Зайсан шәһәрендә, 1920—1923 елларда Америкада яши, Төркия белән Болгариядә дә бераз яшәп ала. СССРга 1923 елның 30 апрелендә кайтып төшә. Америкада югары техник белем ала, СССРга техник булышлык оештыру җәмгыяте әгъзасы булып тора. СССРга илгә авыр чорда булышлык күрсәтү теләге белән техник хезмәткәрләр группасы составында инженер буларак килә. СССРга килгәндә, узып барышлый Германиядә була һәм анда Галимҗан Идриси, Гаяз Исхаки, Абдулла Сунишев, Бәдри Сәйфельмөлеков, Галия Буби һәм Билал Буби белән очрашып сөйләшә. Бу очрашу бәхетенә ул Америкадагы татарлар җәмгыяте әгъзасы Фатыйма Агишева тырышлыгы белән ирешә. Германиягә, дөресрәге, Берлинга килеп урнашкач та, ул Фатыйма ханым юлламасы белән Сунишевка мөрәҗәгать итә. Соңгысы Зыя әфәндене мәшһүр татарлар белән очраштыра. Зыя Мөҗәвиров үзе бу турыда түбәндәгеләрне сөйли: «Сунишев белән икенче көнне үк Гаяз Исхакый фатирына килдек. Ул өйдә иде һәм безне чәй һәм хәмер белән сыйлады. Гаяз Исхакый татар интеллигенциясенең һәм үзенең Русиядән качып китү сәбәпләрен сөйләде.

Ул шулай ук большевикларга, СССРга мин каршы, чөнки большевиклар бары тик таларга гына сәләтле, алар белән бергә булу — талаучы булу дигән сүз, диде. Аннан соң ул миңа Казанда чыккан татарча газета күрсәтте. Анда контрреволюционер Г. Исхаковның СССРга каршы булган роле турында язылган иде. Исхаков СССРга баруымнан баш тартуымны теләде».

Гаяз Исхакый Зыя Мөҗәвировның Кузнецк бассейнына сәяхәте белән кызыксынып, кайткач аның хатлар язуын, бигрәк тә әдәбият, мәгариф эшләре, татарларның совет органнарында катнашулары һәм халыкның Совет хөкүмәтенә мөнәсәбәте турында хәбәрләшүен үтенә.

Менә шундый кисәтүләргә карамастан, Мөҗәвиров Америка инженерлары Фальмор, Кенгриләр белән берлектә СССРга кайта.

СССРга кайтканнан соң Зыя Мөҗәвиров төрле урыннарда эшли. Ул башта Башзолотода, ә аннан Башнефтьтә хезмәт итә. 1936 елның 3 августында кулга алына. Аны милли контрреволюцион һәм шпионнар оешмасы әгъзасы дип табалар. Сорау алулар вакытында ул тикшерүчеләр Нуретдиновка һәм Андреевка: «Мин Казанга килгәч Фатыйх Әмирхан һәм Камил Вәлидов белән очрашып, алардан яшерен мәгълүматлар алырга һәм шушы ук мәсьәләләр буенча Гаяз Исхакыйның күрсәтмәләрен үтәргә тиеш идем», — ди.

Усманов Мулланурны язмыш Әгерҗедән Маньчжурия, Кытай, Япониягә илтеп яңадан туган иленә кайтара. Аны да туган җир үзенә тарта, ул тикшерү барышында: «Нигә СССРга кайттыгыз?» — дип сорагач: «Бары тик туган илдә яшәргә теләгәнгә күрә», — дип җавап бирә. Харбиннан, Кытай, Маньчжурия ягыннан бик күп милләттәшләребез туган якларына, бигрәк тә 1921 елда Совет дәүләте Яңа икътисади сәясәткә юл алгач, яңа өметләр белән кире кайталар. Әмма аларны монда тоталитар режимның хөкеме, лагерьлары, төрмәләре көтә. Шулай булса да туган ил, туган җир тарта.

Мулланурның башкалардан аерылып торган ягы шунда ки, ул революциягә кадәр шактый бай кеше була, бәләкәй генә булса да кибет тота. Әмма Гражданнар сугышы вакытында ул, күпләр кебек, акгвардиячеләр белән Себер якларына китеп, Харбинга барып җитә. Анда Гыйниятулла Сәлиәхмәтов җитәкчелегендә мөселман җәмгыяте эшли. Ул әлеге оешмага әгъза булып керә, аның белән килгәннәрдән тагын берничә кеше бу җәмгыятьтә әгъза булып торалар. Әлбәттә, чит җирләрдә милләттәшләргә болай яшәве җиңелрәк һәм күңеллерәк була. Бергә җыелып мәктәп эшләре,

мәчет мәсьәләләре хакында сөйләшүләр гадәткә керә. Әлеге мәҗлесләр вакытында Татарстанның киләчәге, аның дәүләтчелеге мәсьәләләре дә күтәрелә. М. Усманов, Амрулла Агеев, Ибраһим Акчурин, Муллагали Яушев, А. Даутов, М. Камаев, Ибраһим Ильясовлар бу оешманың әгъзалары булалар. Хәер, СССРга кайтмасалар, алар шунда ук, яисә Япония, Америка һәм башка илләрдә дә тормыш корып җибәргән булырлар иде, чөнки тормышны башлап җибәрү өчен, барысының да булмаса да, милкәтләре булган. Мәсәлән, Муллануp Усманов СССРга кайтканда Дальвосток банкына 19 мең сумлап алтын акчасын дәүләт файдасына тапшыра. Шулай итеп, СССРга ул, барлык якташлары кебек, ярлы Мулланур булып кайтып төшә. Шулай да Әгерҗедә үзенә өй җиткереп, эшне яңадан башлап җибәрмәкче була.

Харбиндагы мөселман җәмгыятенә килгәндә, аны тарихын әле махсус өйрәнү таләп ителә[111]. Әлегә безгә шунысы мәгълүм: бу җәмгыять Идел буендагы һәм гомумән СССРдагы ачлыкның куркыныч алганын белгәннән соң, кардәшләренә кулдан килгән кадәр булышу юлларын эзли. Аның әгъзалары тиз арада СССРга посылкалар җибәрүне оештыралар. Монда алар Центрсоюз, АРА оешмалары аркылы эш итәләр.

Башкалар белән беррәттән «җинаятьче» дип табылган Мулланур Усмановтан да июль аенда авыр һәм газаплы сорау алулар башлана. Ул, Харбин мөселманнары җәмгыятенең эшләре хакында сөйләүдән башка, 1922 елда СССРга яшерен рәвештә килгән Рәшит Ибраһимовның Харбинда доклад ясавын әйтә. Янәсе, Ибраһимов үзенең докладында Мөселман җәмгыятендәге барлык татарны, барча мөселманны мөстәкыйль мөселман дәүләте төзергә чакыра: «Тиз арада Совет дәүләте алып ташланачак. 1917 елда Казанда хакимият мөселманнар кулында иде, аны саклап калып булмады, чөнки оешканлык җитмәде. Совет дәүләтен бәреп төшергәч, йоклап ятарга ярамый»,— ди.

Усмановның әйтүенә караганда, комитет әгъзалары барысы да 30 миллион кешелек мөселман халкының үз дәүләтен булдыру идеясен хуплыйлар. Ул вакытта үзе дә шул фикердә була.

Августта булып узган сорау алуларда ул туган илләренә кайткан М. Яушев, М. Камаев, М. Ильясов һәм А. Даутов исемнәрен дә атый. Усманов: «Алар барысы да СССРга бары тик туган илләрендә яшисе килгәнгә генә кайттылар»,— ди. НКВД, киресенчә, аларны диверсант итеп күрсәтә, янәсе, алар — япон шпионнары.

Мөфтияткә килгәч, ул очраклы рәвештә Зыя Камали белән очраша.

— Сез кем буласыз?—дип сорый Зыя туу таныклыгы бирүче Шәһәрне көтеп торучы Мулланур Усмановтан.

— Мулланур Усманов,—ди ул.

— Усманов? Теге японча сөйләшә белә торган Усмановмы?—ди Зыя Камали.

— Әйе,—дигән җавап ишетелгәч, алар азрак сөйләшеп тә утыралар. Әлбәттә, бу очраклы вакыйгага да сорау алулар вакытында файдаланыла.

1936 елның 17 ноябрендә Усмановтан сорау алганда, тикшерүче: «СССРга кайтучы татарлар мөселман җәмгыятендә махсус инструкцияне Гыйниятулла Сәлиәхмәтовтан алалармы? Сезгә инструкцияне Сәлиәхмәтов бирдеме?—дип сорый.

— Юк,—ди Мулланур катгый рәвештә. Бу шулкадәр табигый чыга, ихтимал, тикшерүчеләр шуның белән әлегә канәгать булып, сорау алуны туктатып торалар.

Планнары барып чыкмагач, алар Абдулла (Габдулла) Газизов-Сакмарый күрсәтмәләре белән таныштыралар. Габдулла да Мулланур кебек, беркадәр Харбинда яши, ул да әлеге мөселман җәмгыятенең әгъзасы булып тора, шулай ук вакыты җиткәч СССРга чыга, хәтта Владивостокта диңгез мәктәбендә инглиз теле укыта. Соңрак, Идел буйларын сагынып кайткач, шулай ук НКВД тозагына эләгә. Аның күрсәтмәсендә Мулланур түбәндәге юлларны укый: «...мөселман общинасы Маньчжуриядә ак эмигрантлар туплау белән шөгыльләнде, 1923 елда әлеге җәмгыятьнең идарәсе СССРда яшәүче татарлар белән элемтәләр урнаштыру хакындагы мәсьәләләрне тикшерә башлады. Ул әлеге максатта СССРда эшләү өчен ватаннарына кайтучыларны файдаланырга карар кылды. Мин шуны да искәртергә тиешмен, паспортларга виза салганчы, кытай хакимиятләре китүчегә карата җәмгыятьнең җаваплылыгын таләп иткәннәр. Җәмгыять (община) җаваплы кеше итеп үзенең составыннан Салиәхмәтовны тәкъдим иткән. Сәлиәхмәтов китүче татарларны (СССРда эшләү өчен дә) өйрәнергә тиеш булган». «Ничек инде?.. Гыйниятулла мулла 1926 елда ук вафат[112],—Мулланурның күз аллары караңгыланып китә.—Инде нишләргә? Ни әйтергә бу әзмәверләргә? Бу әшәке документларны кем әзерләгән?»

— Юк, мин монда язганнарны кабул итмим,—ди ул.

Ике тикшерүче, бәхәсне куертмакчы булып, сорау артыннан сорау яудыралар. Ихтимал, алар Мулланурны куркытып үзләренә кулайрак документ әзерләргә уйлаганнардыр.

Берсе янә сорау бирә:

— Сез дөресен сөйләмисез, тикшерүгә бары да билгеле. Сез — контрреволюцион яшерен оешманың вәкиле. Дөрес итеп җавап бирегез! — ди.

Моңа каршы Мулланур:

— Мин бернинди дә контрреволюцион оешмада тормыйм, — дип җавап бирә.

Үзләренә кирәкле мәгълүматны ала алмагач, янә Габдулла Газизов күрсәтмәләрен бирәләр. Анда: «Миңа агентураны Хәбиров Салих тапшырды. Территориаль агентура түбәндәге шәһәрләрне били... Татарстанда Даутов Әхмәтҗан, Әгерҗе районында бугай, Усманов Мулланур эшләргә тиеш иде. Аларның эшчәнлеге японнарга якынаю, теләктәшлек карашларын җәелдерү рухында башкарылырга тиеш иде», — дип язылган була.

— Сез үзегезне гаепле саныйсызмы?! — дип җикерәләр Нуратдинов һәм Шляпников.

— Юк, санамыйм! — ди Мулланур үзе дә сизмәстән катгый итеп.

Сорау алу дәвам итә.

Аның белән эш иткәннәрдән — Башкировтан, Исхаковтан, Туктамышевтан һәм башкалардан да сорау алалар. 1936 елның 16 августында Башкировтан көч кулланып сорау алулар дәвам ителә. Ниһаять, ул үзен гаепле дип әйтергә мәҗбүр була. Башкиров: «Мин Харбинда чакта Русия татарларының ак эмигрантлар мөселман оешмасының әгъзасы булып тордым, ә бу оешмага Мулланур Усманов аркасында кердем. Аннан соң без Усманов белән бу оешмага тагын Галиев Нурәхмәтне, Усманов Исмаилны, Ханихузяны, Усманов Ибраһимны һәм башкаларны тарттык», — ди.

Эшләр бик җитди төс ала. Усмановка, аның якташларына, шул исәптән Ш. Шәрәфкә, К. Тәрҗемановка, З. Мөҗәвировка яла ягыла, аларны Япония, Германия шпионнары, контрреволюцион оешманың агентлары сыйфатында каты режимда тоталар.

Яз да килеп җитә. Кулга алынганга ел туларга ун көн генә кала, ә тикшерүнең әле ахыры күренми. 1937 елның 9 апреле. Бу көнне Югары Советның махсус коллегиясендә 11 кешенең, шул исәптән Абызгильдин, Камалетдинов, Усманов, Әхтәмов, Мөҗәвиров, Ханисламов, Мостафин, Габдрәхимов, Хәбиров, Шәһер Шәрәф һәм башкаларның эше карала. Судка шаһитлар сыйфатында Ф. Хәкимов, З. Бәширов, З. Тупиев, А. Максутов чакырыла. Бу юлы Шәһерне 1905, 1906 елларда булып узган мөселман съездларында катнашуда һәм аларның протоколларын алып баруда гаеп-

лиләр. Шәһер Шәрәф һәм башкалар тикшерү материаллары белән алдан таныштырылмаганлыклары турында судта ачыктан-ачык әйтәләр. Нәтиҗәдә суд икенче көнгә сәгать 10 га күчерелә. 1937 елның 5—16 апрелендә бер төркем кеше хөкемгә тартыла. З. Мөҗәвировны гаепләргә материаллар җитмәгәнлектән, суд тарафыннан «ул азат ителергә тиеш» дигән карар раслана. Шәһер Шәрәфне Җинаять Кодексының 58-10, 58-11 маддәләре буенча алты елга ирегеннән мәхрүм итәргә, ә 58-4 маддәсенә таянып сигез елга ирегеннән мәхрүм итәргә, өч елга хокукларыннан мәхрүм итәргә, дигән карар чыгарыла. Башкалар төрле срокларга хөкем ителә. Әмма прокурор Мещанкин суд карарын бик йомшак дип таба һәм аны юкка чыгаруга ирешә. Суд хөкемен юкка чыгару карарында түбәндәге юллар бар: «Эш буенча гаепләнүчеләрнең БАССР территориясендәге мөселман руханилары җитәкчелек иткән һәм мөселман ак эмиграция үзәкләре белән элемтәдә торган, максаты — сугыш вакытында баш күтәрү булган контрреволюцион милләтче оешма әгъзалары булуы ачыкланды.

Контрреволюцион оешма җитәкчеләре Абызгильдин, Мөҗәвиров, Шәрәф һәм башкалар ак эмиграциянең мөселман җитәкчеләре белән шәхси элемтәдә торганнар, аларга СССРдагы сәяси хәл, дин һәм руханиларның тормышы хакында даими рәвештә хәбәр иткәннәр.

Контрреволюцион оешма әгъзалары, массаларның дини хорафатын файдаланып, советка каршы агитация алып барганнар, халыкта ризасызлыкны үстерү өчен МҮДНне демонстратив рәвештә ябуны әзерләгәннәр.

Гаепләнүчеләрнең контрреволюцион эшчәнлеге аларның үзләре тарафыннан танылды, тикшерү, шаһитлар һәм матди дәлилләр белән расланды.

Җәза чарасының гаепләнүчеләр өчен йомшак булуын, Хәбировка карата судның нигезсез рәвештә Җинаять Кодексының 58-4 һәм 58-11 маддәләрен кулланмавын, Манновка карата 48-10 маддәсенең 1 нче кисәген һәм 58-11 маддәсен кире кагуын, Ханисламовның һәм Габдрахмановның 58-11 маддәсе буенча гаепләнүен билгеләп үтәргә.

Мөҗәвировның 1923 елда Берлинда булуы вакытында ак эмигрантлар Исхаков һәм Идриси белән элемтәгә керүе һәм аларга мәгълүматлар җибәреп тору хакында ризалык бирүе тикшерү вакытында ачыкланды. 1935 елда Мөҗәвиров чит илдән килгән ак эмигрант агент Газиз, контрреволюцион оешма әгъзалары Камалетдинов һәм башкалар белән тыгыз элемтәдә торган.

Югарыда искә алынганнардан судның Мөҗәвировка ка-

рата аклау хөкеменең нигезсез булуы күренә. Суд хөкемен юкка чыгарып, эшне шул ук судка яңадан карауга бирергә. Рәис: Рожков, әгъзалар: Озолин, Колтун, сәркатип: Коба». Шуннан соң яшерен рәвештә аерым нәтиҗә чыгарыла, анда: «Судка җиткерергә... әлеге эш буенча чыгарылган хөкем Верховный суд директиваларына туры килми»,— диелә[113].

Яңартылган суд — 7—11 гыйнварда Д. Абызгильдин, Ш. Шәрәф, З Мөҗәвиров, М. Усманов, Мостафин, Х. Әхмәтов, Г. Ханисламов, М. Камалетдинов, Маннанов, Х. Абдрахманов, Г. Хәбировның эшләрен кабат карый.

Шаһитлар сыйфатында З. Тупиев, З. Бәширов, Ф. Хәкимов, М. Мәгъкулов, Х. Имангулов, И. Исмәгыйлов чакырыла. Аларның соңгы өчесе килә алмый, чөнки алар этап белән лагерьларга озатылган булалар.

Гаепләнүчеләрнең берсе дә үз гаепләрен танымый. Шәһер Шәрәф тә: «Мин чит ил белән бернинди дә бәйләнештә тормадым, контрреволюцион характердагы тезисларны беркем өчен дә төземәдем, ә бары тик үземә вәгазь уку өчен әзерләдем. ҮМДНне ябу мәсьәләсе буенча киңәшмәдә катнашмадым һәм Совет властена каршы агитация эше алып бармадым. Мин инде бер мәртәбә куылган идем — сөргендә булдым. Судтан мине аклауны сорыйм»[114],— дип, сүзен тәмамлый.

СОҢГЫ СҮЗ

Гомер шулай уза торды, түза торды
Килеп җитте кеше булып калыр көн...

Рәшит Әхмәтҗан

Югары Советның махсус суд коллегиясе 1938 елның 7—11 гыйнварында катгый рәвештә, чынбарлык белән санашмыйча, аны гаепле дип таба. Суд аның гаепләре турында түбәндәгеләрне күрсәтә: «Баштагы һәм суд тикшерүләре мәгълүматлары нигезендә, чит дәүләтләр разведкалары күрсәтмәсе буенча СССРда, сугыш чорында баш күтәреп, совет хакимиятенә каршы көрәшергә тиешле булган мөселман контрреволюцион оешмасы булдырылуын ачыклады. Әлеге контрреволюцион оешманың башында Диния Нәзарәте җитәкчелеге — мөфти Фәхретдинов (вафат) һәм аның урынбасары Тәрҗеманов (СССР Югары судының Хәрби коллегиясе тарафыннан хөкем ителде) торган.

Контрреволюцион үзәк әгъзалары — гаепләнүчеләр Абызгылдин, Камалетдинов, Шәрәф, Әхтәмов, Ханисламов, Усманов, Хәбиров һәм башкалар. Шәрәф, контррево-

люцион оешманың әгъзасы буларак, әлеге Үзәк кушуы буенча, эшчәнлек җәелдерү өчен Харьковка, Одесса һәм Дон өлкәләренә җибәрелгән.

Шәрәфнең контрреволюцион эше аның китабында ачык күренә. Әлеге китапта урын алган фикерләр Шәрәф карашларының ак эмиграция лидерларының берсенең нотыгы белән аваздашлыгын күрсәтә...»[115] Нәтиҗәдә БАССР Югары Советының махсус суд коллегиясе 11 кешенең эшен карап, аларның өчесенә 5 елдан 10 елга кадәр төрмә билгели, ә калган тугызы — Д. Абызгильдин, Ш. Шәрәф, Камалетдинов, Х. Әхтәмов, Г. Ханисламов, З. Мөҗәвиров, М. Усманов, Г. Хәбиров иң югары җәзага — атарга хөкем ителә.

1938 елның 16 гыйнварында 12 сәгатьтә Шәһер Шәрәфне махсус коллегиянең 7—11 гыйнварда чыгарган карары белән таныштыралар һәм кул куйдыралар.

Инде атылу көнен көтәргә генә кала. Х. Әхтәмов үлеп котыла, соңрак Г. Хәбировка әлеге карарны 10 еллык төрмә белән алыштыралар, ә калганнарының сораулары, гаризалары искә алынмый.

